1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 12 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

Нәфкать Нигъмәтуллин АЧЫКТАН-АЧЫК

«СӨЕМБИКӘ» *сәяхәттә сагыну сагышы*

бәйрәм сые КОЙКАЛЫ БАЛЫК

Альбина НАСЫЙРОВА:

«Бала-Сити»ның көче – укытучыларда».

PRESSA





ГЫЙНВАР

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

ФЕВРАЛЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	
П	2	9	16	23	
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

МАРТ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	31
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

АПРЕЛЬ

Д		3	10	17	24
С		4	11	18	25
Ч		5	12	19	26
П		6	13	20	27
Җ		7	14	21	28
Ш	1	8	15	22	29
Я	2	9	16	23	30

МАЙ

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	31
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	

ИЮНЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	
Я	4	11	18	25	

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина

Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Альбина Насыйрова
әнисе Резеда Мөхәммәтшина
һәм кызы Сара белән
Фото: Аида Сафина

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 28.11.2022 ел.
Чыгу көне: 6.12.2022 ел.
Заказ О-3563
Тираж 8283

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Синең кулда – бәйрәм саныбыз. Редакция аны гадәттәгечә ноябрь аена аяк басуга ук әзерли башлады. Урамда әле кара көз иде, ә без инде кар бөртекләрен, бураннарны, төрле утлар белән җемелдәгән чыршыны күз алдына китереп, язмаларыбыз, фотосурәтләребез аша укучыларыбыз күңелендә бәйрәм рухы тудырырга тырыштык...

Узып баручы ел беребез өчен дә җиңел булмады... Шәхсән минем өчен ул коточкыч зур югалтудан башланды – гомер буе ышанычлы терәгем булган бердәнбер абыемның гомерен өзделәр. Безнең журнал герое Мөслим егете Рүзәл Минһаҗев әйтмешли: «Җирләрне умырып ярсынсаң да, башка булмый күрешеп...» Күрешеп булмый, әмма абыем белән сөйләшмичә, киңәшләшмичә бер көнем дә узмый...

Фидельнең чынга ашарга өлгермәгән хыяллары, эшләп бетермәгән эшләре калды... Теләге зур булгандыр: ул эшләрнең кайберләре барыбер чынбарлыкка әйләнә. Туган шәһәребез – Менделеевскида Рөстәм Миңнегәрәев оештырган «Арена добра» фонды бар. Ул мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм итә. Беренче көннән үк абыем да фондның эшендә катнашкан – үз өлешен керткән икән. Без бу хакта ул арабыздан киткәч кенә белдек... Быелдан башлап Менделеевскида мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ел саен уздырыла торган ярышлар абый исемен йөртәчәк. Шәһәребезнең балалар приютында тәрбияләнүчеләрне исә бүген аның бизнесын дәвам итүче кызы да кайгырта...

Югалтулар кешене үзгәртә: күп нәрсәгә башкача карый башлыйсың. Бу Яңа ел бәйрәмендә туганнарымның, якыннарымның һәрберсенә аерым рәхмәт әйтермен. Тормышта бер-береңә рәхмәтле булган очраклар бик күп, әмма арада аерылып торганнары бар. Ниндидер бер кечкенә генә яхшылык (җылы сүз, якты караш...) өчен җаныңда рәхмәт хисе яши дә яши. Соңгы көннәрдә күңелемнән рәхмәтемне кабат әйтергә теләгән кешеләрне барлыйм. Кемгәдер яңадан рәхмәт әйтү теләге синдә дә бардыр... Иртәгәгә калдырмыйк, бүген әйтик!


Бәйрәмгә әле иртәрәк, әмма бер рәхмәтемне мин инде бүген үк җиткерәм. Ул рәхмәтем сиңа, кадерле укучым! Безнең журналны сайлаган өчен рәхмәт... Безнең белән бергә булган өчен! 2023 елда «Сөембикә»безгә 110 яшь тула. Шул уңайдан журналыбызга язылучылар арасында тиздән бүләкләр уйнатачакбыз. Төрле-төрле сюрпризлар сезне ел дәвамында көтәчәк – бер-беребезгә рәхмәтләр әйтергә сәбәпләр булачак!

Имин еллар килсен! Барлык теләкләребез кабул булсын!

Яратып, Лариса МАЛИКОВА

Фото: Анна Арахамия

Безнен тышлыкта



«Казандагы бер генә мәктәпкә дә охшамасын, укучылар анда дүрт-биш телдә сөйләшсен, дөнья күләмендә конкурентлылыкка сәләтле булып үссеннәр. Мин шуңа омтылдым. Әгәр нәрсәне дә булса бик-бик теләсәң, бар җиһан аны тормышка ашыруда булыша икән.»




10
Без – бер дөнья, бер планета!
Эльмира Закирова



14
«Мәрхәмәтле балалар үстерсәк иде»
Чулпан Галиәхмәтова



16
«Мин – тырыш кырмыска...»
Гөлнур Сафиуллина



26
Бай күл белән кушылган без...
Алсу Шакирова

Заман һәм без

Могҗиза 6
Чулпан Галиәхмәтова

Яңа елга яхшы кәеф белән! 20

Татар дөньясы

Бурятия. Фоторепортаж 24
Анна Арахамия

Мәдәни тормыш

Кар бураны... Чиксез аклык... 34
Оксана Ильюп, Әлфирә Низамова, Равилә Мөбарәкшина, Вәзилә Чинаева, Галия Гайнетдинова

Китап уку — ул традиция 39
Гөлназ Сәфәрова

Яшәеш

«Моң чишмәләрем сез...» 42
Чулпан Галиәхмәтова

«Төшләремдә ак күлмәктән син...» 46
Алсу Шакирова

Мәңгелек туң илендә 50
Лариса Маликова

«Ул миңа үзе тәкъдим ясады...» 54
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

Йомшак һәм ягымлы бул, Куян елы! 58

Йолдызнамә-2023 60


Дулкын-дулкын чәчләрең 61

30



Ә авылда хәзер каз өмәсе...
Лилия Гәрәева

36



Бияләй
Гөлүсә Закирова

62



Бәйрәм сые – койкалы балык
Илдар Галәветдинов тәкъдим итә

»



МОГҖИЗА

– Чүлләрнең нилектән яхшы икәнен беләсеңме? – диде ул.
– Чөнки анда чишмәләр яшеренгән... Шуңа күрә...

Антуан де Сент-Экзюпери «Нәни принц»

Нәкъ Казан уртасында Могҗиза йорты бар. Анда нәни принцлар кайнаша. Әйе-әйе, барыбыз да укып үскән Экзюпериның нәни принцлары. Алтын чәчле малай кебек үк җирдә тормыш мәгънәсен өйрәнергә, дуслык серенә төшенергә, кешеләрнең мөнәсәбәтен аңларга тырышалар. Алар талантлы да. Менә шул талантларын үстерү өчен, үз-үзләрен җиңә-җиңә алга баралар. Алар – сәхнәдә, залда – тамашачылар... Алкышлар... Әти-әниләренең горурлык хисе белән тулган карашлары, укытучыларының канәгать елмаюлары... Театр гына әнә шундый куаныч, серле дөнья тудыра аладыр, мөгаен. Могҗизалар туа торган урын шул ул. Бигрәк тә әлеге нәни принцлар өчен. Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында мөмкинлекләре чикләнгән һәм Даун синдромлы балалар өчен менә инде биш ел «Могҗиза» татар театр студиясе эшли. Гади генә студия түгел ул, үзе бер Галәм...



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА







Фото: Анна Арахамия

«Алтын» укытучылар

Якшәмбе. Көн уртасы. Театрдагы тынлыкны бозып, «Исәнмесез», – дигән тавыш яңгырый. «Могҗиза» студиясенең кечкенә артистлары килә! «Исәнмесез! Килеп җиттегезме? Әйдәгез, чишенегез». Аларны Зөлфия апалары елмаеп каршы ала. Гардероб каршындагы зур фойеда ярымтүгәрәкләп урындыклар тезеп куелган. Балалар шунда барып утыра, йә утырган коляскаларының тәгәрмәчләрен шул таба әйләндерә. Хәния, Карина, Ралина, бер тирәгә җыелып, сөйләшә дә башлый. Сагынышканнар. Үсмер кызларның серләре килешкән, ахры. «Мин инде монда дүрт ел шөгыльләнәм. Дуслар, фикердәшләр таптым. Без бер мәктәптә, әмма төрле сыйныфларда укыйбыз. Менә монда табыштык», – ди Хәния Гыйбадуллина. «Мин әле яңарак кына килдем. Инде яңа якларымны, мөмкинлекләремне ачтым. Сәхнәдән курыкмаска өйрәнәсем килә, мин бит әле җырлыйм да. Рольдә уйнап карау бик нык тәэсирләндерә. Элек бу хакта хыялланмый да идем. Бу минем өчен бәһасез тәҗрибә», – ди Ралина Гатауллина. Карина Кайданова студия ачылганнан бирле йөри икән. Актриса, сценарист йә режиссер булу теләге бар. «Монда йөри башлагач, театр дөньясы минеке булуын аңладым, тормышымны шуның белән бәйлисем килә», – ди ул. Борын астында мыек төртә башлаган Әмир җитди генә исәнләшеп килеп керде. Журналист булырга теләсә дә, театр студиясенә дә яратып йөри икән. Сүзе, егетләрчә, кыска булды аның: «Безнең коллектив бердәм, ә укытучылар – алтын!» Ягымлы елмаеп, Айрат, Әлфия, Эльза үз урыннарына барып утырды. «Кояш кызы» Лиза Зөлфия апасын кочаклап ук алды. Барысы да җыелышып беткәч, укытучылары Зөфәр абый Харисов, Гөлназ Нәүмәтова, Салават Хәбибуллин килде. Укытучыларны күргәч, укучыларның йөзләре яктырып китте. Йөри алганнары сикереп торып күрештеләр. Салават абыйларының туган көне икән. Лиза, йөгереп барып, алып килгән бүләген бирде. Салават абыйсы чын күңелдән рәхмәт әйтеп, Лизаны кочаклап алды. Дәрес Татарстан гимны белән башланып китте. Шөгыльләнә башладылар. Лиза, йөгереп барып, алып килгән бүләген тагын бер кат тапшырды. Салават абыйсы кабат куанып алды. Дәрес барышында ул бүләк өч-дүрт тапкыр тапшырылды әле. Укытучысы, һәрвакыттагыча – беренче тапкыр алгандай, сөенеп, Лизаны кочаклап алды. Белә: күңелләре пыяладай уалырга торган, дөньяга башкача карап яшәгән балалар белән эшли бит алар. Аларның һәрберсе – Экзюпериның «Нәни принц»ы!



Зөфәр ХАРИСОВ, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты

Үземне бу балалардан башка күз алдына да китерә алмыйм дисәм, артык пафослы булыр. «Нәни принц»тагы Төлкенең «үзебезгә ияләштергән кешеләр өчен җаваплы без» дигән сүзләре миңа бик тәңгәл килә. Аларның өметләрен акларга тиешмен. Балалардан бигрәк, әти-әниләрнең күңелләрен үстерә алуым өчен куанам. Аларның сабырлыкларына, түземлекләренә әз генә булса да ярдәмем тигәнгә сөенәм. Студиягә килгән бер баланы да кире борып җибәрмибез. Сайлап алу юк бездә. Менә безнең Лизабыз үзе бер көч, үзе бер Планета. Аның кәефе үз дөньясына бәйләнгән. Үзе генә белгән дөньяга... Лизабыз да спектакльләрдә катнаша. Бу балалар чын күңелдән шатлана белә. Минем күңелем тагын тула инде. Төрле бәйгеләрдә мәртәбәле урыннар алгач, аларның куануларын күрсәгез иде сез!.. Ничек шуннан соң рухланмый кала аласың инде?! Кемнедер күпмедер вакытка бәхетле итә алсаң, сөендерә алсаң, киңәшең беләнме, эшең беләнме, елмаю, мөнәсәбәтең, җылылыгың беләнме яшәргә өмет бирсәң, бу могҗиза бит. Димәк, безнең студия – могҗиза тудыручы.

Уңыш сере

Студиягә исемне балалар үзләре уйлап тапкан. Театр – серле дөнья, дигән алар. Зөфәр абыйлары матур итеп могҗизага әйләндергән. Хәзер балалар шул серле дөнья эчендә кайный. Сәгать ярым барган дәрес өч өлешкә бүленгән. Гөлназ – сәхнә телен, Салават сәхнә хәрәкәтен өйрәтә. Күнегүләр ясап, телне ачкач, гәүдәне уятып җибәргәч, спектакльләргә әзерлек башлана. Зөфәр абыйлары махсус спектакльләр яза, балаларны актерлык осталыгына, режиссура серләренә төшендерә. Укытучылары күрсәткән һәр хәрәкәтне отып калып, артларыннан кабатларга тырыша кечкенә артистлар. Минем барып чыкмый дип елап утырмыйлар. Гомумән, бу уй башларына да килми кебек. Нәкъ менә анык барып чыгачак! Тормышка ике куллап тотынган балалар бит алар. Җитмәсә, үзләре әйткәнчә, алтын укытучылары янәшәдә. Шуңа күрә уңышларга да ирешәләр.

– Инде безнең бик күп җиңүләребез бар, – ди студия кураторы, театрның баш администраторы Зөлфия Бәшәрова. – Зөфәр абый шушы балалар өчен махсус язган беренче спектаклебез «Булмас димә, була шул» – «Я могу! Творчество без границ» Бөтенроссия бәйгесендә призер булды. Икенче елны инде икенче дәрәҗәдәге лауреат исеме алдык. Узган ел «Миһербанлык» спектакле белән «Театр – All Inclusive» республика бәйгесендә җиңдек. Спектакльләребездә бар бала да катнашсын өчен,



Салават ХӘБИБУЛЛИН, театр артисты

Студиядә эшләргә тәкъдим иткәч, зур теләк булмаса да, алынып карыйм дип кенә кергән идем. Тәҗрибә булмау куркыткандыр, мөгаен. Әмма, ялгышмасам, өченче дәрестә белгән белемнәремне бирә башлагач, аларның миңа мөнәсәбәтләре, башка яшьтәшләренә караганда, тыңлый белүләре белән үзләренә җәлеп итте. Бер-беребезне аңлый башладык. Сәламәтлекләре чикле булуга карамастан, алар бик нык тырыш, хәтта бездән тырышрак дип әйтер идем. Һәр әйткән сүзне тыңлап, өйгә бирелгәнне эшләп килергә тырышалар. Хәзер инде мин аларның үз кешеләре, аларның да тормышымда үз урыннары бар. Дөньяга карашымны үзгәрттеләр. Нинди генә халәттә булсаң да, кеше булып калырга тиешсең. Балалар белән аралашудан күп нәрсә алам.

Төрле яшьтәге балалар белән эшлим, әмма иң яратканнарым – «Могҗиза»га йөрүчеләр. Теләкләре бик зур, булдыралармы, юкмы, бөтен көчләрен куеп эшлиләр, авызыңа гына карап торалар. «Бу балалар белән башкачарак шөгыльләнергә кирәк бит инде», – дип, куркыбрак кына кергән идем беренче дәрескә. Әмир дигән малаебыз мине кул чабып каршы алды да, бөтен куркуларым таралды. Рәхәтләнеп шөгыльләнәбез. Күбрәк сөйләм теленә игътибар бирергә тырышам. Дүрт ел дәвамында үзгәрешләр күрәм. Каринабызны килгән мәлдә сәхнәгә чыгарып сүз әйттереп булмый иде, хәзер ачылды әнә. Башта балалар белән концертлар оештырдык, аннан әкиятләр куя башладык, хәзер менә тулы бер спектакльләр чыгарабыз. Без инде хәзер бер гаилә. Мин – аларны, алар мине үзгәртә. Мөмкинлекләре чикле балаларга башкача карый башладым. Аларның әниләре алдында баш иям һәм ул сүзләрне әйтүдән туктамаячакмын. Элек бу балаларга җәлләп кенә каралса, хәзер эчке дөньяларын аңлап карыйсың. Яшәү көчләре зур булуына сокланам. Күп вакыт үсмер улыма үрнәк итеп куям аларны. Иң мөһиме: киләчәкләре якты булсын, өмет-ышанычлары сүнмәсен...



Гөлназ НӘҮМӘТОВА, Татарстанның атказанган артисты

Зөфәр абый махсус инсценировкалар яза. Студия эшен башлап җибәргәндә мондый уңышларга ирешербез дип күз алдына китермәдек. Театр директоры Фәнис Мөсәгыйтов идеясе, Альбина Сәлимгәрәева җитәкләгән «Во благо вместе» инициатива төркеме ярдәме белән берлектә башланган эш иде ул. Зөфәр абый – тәҗрибәле, күпне күргән, театрыбызның аксакалы дисәк тә була аны. Башта аның белән утырып сөйләштек. Озак кына уйланып йөргәннән соң, ул алынды. Тернәкләндерү үзәкләреннән балалар җыеп алып килделәр. Зөфәр абый һәм Салават алар белән шөгыльләнә башлады. Бөтен артист та бу балалар белән эшли алмый. Аларның күбесе йөри алмый, Даун синдромлы «кояш кызы»быз Лиза да бар бит әле. Кызларыбыз да үсеп килә бит, төрле вакытлар була, серләшер-киңәшер кеше дә кирәк: Гөлназ апаларын чакырдык. Ул инде кызларның сер төенчеге. Хәзер менә бер гаилә алар. 6 яшьтән 19 яшькә кадәрле 15 бала йөри безгә. Алар үзара дуслаштылар. Күбесе студия ачылганнан бирле монда. Балаларын көтеп торган арада, әниләре буфетта чәй эчә-эчә үз хәлләрен сөйләшә. Уртак темалары күп бит. Алар өчен үзенә күрә бер психологик ярдәм дә әле мондый очрашулар.

«Безнең балалар – аерым бер дөнья»

Әниләр белән сөйләшергә чыгабыз. Кызык, берсенең кулында да телефон юк. Әкрен генә үзара сөйләшеп утыралар. Битарафлык юк бу хатын-кызларда! Әнә Әмир белән Айратның әниләре янәшә утырган. Егетләр үстерәләр бит, уртак сүзләре күп. «Без инде «Могҗиза»ның чишмә башында торабыз, – ди Әмирнең әнисе Гөлсинә Нуриева. – Монда йөрергә тәкъдим иткәч, шундук: «Барабыз», – диде улым. Бергә дусты Анель да йөри. Сөйләшергә, уйнарга бик яратабыз шул. Кечкенә вакытта этюдлар куя иделәр, хәзер җитдирәк спектакльләрдә уйныйсылары килә. Зөфәр абый алар өчен махсус «Беренче театр» пьесасын да әзерләде. Балаларны сәхнәдә танып

та булмый! Күзләре яна! Бик горурланып карап утырабыз инде. Әле бит бу студиядә дәресләр татарча алып барыла. Нәтиҗәсе дә бар: элек Әмир татарча аңласа да, сөйләшми иде, хәзер менә туган телендә сөйләшергә тырыша».

Айратны Teләчедән үк йөртәләр икән. Бу студияне аларга шагыйрә Люция Әблиева табып биргән. Менә инде өч ел ял саен Teләче–Казан юлын таптыйлар. «Айратка бик ошый. Шуңа гаилә белән җыенабыз да чыгып китәбез. Көнебез шушында үтә үтүен, әмма бик бәхетле булып кайтабыз. Студиягә йөргәнче нәфис сүз буенча бәйгеләрдә катнаша иде. Сәхнәгә чыккач бик дулкынлана, янында кулын тотып басып тора идем. Хәзер: «Кереп кит», – ди. Әле үзе сәхнәгә чыгарга тырыша. Бу бит инде шушы студия уңышы. Сөенеп туя алмыйм. Хәзер улыбыз театр белән җенләнә. Артист буласым килә, ди. Театр атмосферасы белән сугарылган студиядә шөгыльләнү тәэсир итми калмады», – ди әнисе Люзия Якупова.

– Безнең хакта тернәкләндерү үзәгенә кереп йөргән әниләр сөйләгән дә, театрдан чакырып шалтыраттылар, – ди Люция Емекова. – Шаккаттык. «Шундый театрдан дәшкәч, ничек риза булмыйсың инде. Барабыз, әмма ничек булдыра алырбыз», – дип, куркып кына килдек. Ә монда күбесе үзебезнекеләр икән – дәваланырга бергә йөрибез. Укытучыларыбыз да яратып, үз коллективларына алды. Эльзабыз үзгәрде. Бик оялчан иде. Дөрес, тормыш әкрен-әкрен генә кыю булырга өйрәтте, әмма һаман да оялчанлыгы бетми иде. Кимеде бит тәки! Монда йөрү хәтер өчен дә яхшы. Шигырьләр, рольләр ятларга бирәләр. Үзеңне ничек тотарга өйрәтәләр. Теле дә яхшырды. Сүзен йотып сөйли иде. Гөлназ апасына рәхмәт, дөрес сулыш алырга, каушамаска, сәнгатьле итеп сөйләшергә өйрәтә. Бу үзенә күрә бер дәвалану курсы да. Мәктәпне тәмамлап, сәүдә техникумына флорист булырга укырга кердек. Ул һөнәрдә клиентлар белән аралаша белү дә мөһим. Биредәге дәресләр практика үткәндә нык ярдәм итә. Ә никадәр шатлык! Сәхнәләргә чыгу шатлык икән ул. Бәйгеләргә бардык, сәхнәләрдә уйнаттылар. Бала шатлыгын берничек тә сүз белән аңлатып бетереп булмый. Тамашачының алкышлавы да аларга энергия бирә икән. Балаң сәхнәдә булганда бик күңелле. Әтисе белән килеп карап утырабыз. Горурлык инде безнең өчен. Бик зур горурлык! Аллага шөкер, театрыбызга, җитәкчеләребезгә, укытучыларыбызга мең рәхмәт.

Бу – чын-чынлап могҗиза, диләр театр студиясе турында әниләр. Балалар күзгә күренеп үзгәрә. Шуңа да килергә теләк белдерүчеләр өзелми. Дөрес, дәваланырга еш йөргәннәргә китәргә туры килә. Әмма алар киткәндә, әйләнеп кайтырга вәгъдә итә. Җанга якын урынга гына кайтасы килә бит ул! «Могҗиза» – минем кызыма сүзсез генә үзен, эмоцияләрен күрсәтү мәйданы, – ди «кояш кызы»ның әнисе Елена Джаффарова. – Бирегә куркып кына килгән идем, рус телле кешеләр бит без. Ә минем бала өчен милләт төшенчәсе юк. Ул эмпатик дәрәҗәдә аңлаша. Аңа нинди телдә сөйләшүләре түгел, кешедән килгән энергия мөһим. Күргәнсездер инде, ул укытучыларын гел кочаклап тора. Ә безнең Лиза теләсә кемне кочакламый ул, бары тик яхшы күңелле кешеләрне генә».

«Арагызда эшләгән әниләр дә бар. Ял көннәрендә – өй мәшәкатьләренә чумасың, ничек җыенып чыгып китә аласыз?» – дип сорыйбыз әниләрдән. «Бала шатлыгы, баланың үсеше өчен теләсә нәрсәгә барасың инде. Җитмәсә, шундый мәртәбәле артистлар балаларыбыз белән бушлай шөгыльләнә. Балаларны бик яраталар. Бала күңеле сизгер бит ул, безнекеләрнеке аеруча. Укытучыларын телевизордан күрсәләр, ничек шатлануларын белсәгез иде сез! Шуңа күрә тиз-тиз генә өй эшләрен башкарасың да чыгып китәсең», – диләр. Әйе, бу әниләрнең берсе дә сузылып йөрүчеләрдән түгел. Аларның һәр минуты санаулы. Монда йөргән һәр бала талантлы. Алар тагын кайда гына йөрмиләр: спортка да, вокалга да җитешәләр. Театр студиясендә могҗиза турында күп сөйләштек без. Һәм шуны аңладык: бу балалар



Фәнис МӨСӘГЫЙТОВ, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры

Сәламәтлеге чикле балаларны тернәкләндерүдә мәдәниятнең, иҗатның көче аеруча зур. Шуларны күздә тотып башланган проект ул «Могҗиза». Аннан соң мондый балалар өчен татар телендә эшләгән театр студиясе, түгәрәкләр юк. Студияне ачканда татар мәдәниятенә яңа кадрлар тәрбияләү бурычы да куелды. Сәламәтлеге чикле балалар арасында зур талантлар бик күп. Артистларыбыз шөгыльләнә башлагач, аларның иҗади мөмкинлекләре чиксез икәнлеге күренде. Аллага шөкер, без көтелгәннән дә зуррак уңышларга ирештек. Студиягә йөрүче балаларга һәр яктан ярдәм күрсәтүләре өчен Альбина Сәлимгәраева җитәкләгән «Во благо вместе» инициатив төркеменә зур рәхмәтебезне белдерәбез. Бу проект сәламәтлеге чикле балаларга ярдәм итеп кенә калмыйча, татар мәдәнияте үсешенә дә зур өлеш кертә. «Могҗиза» студиясе татар театры тарихында, чыннан да, бер могҗиза булды.

үзләре үк могҗиза бит. Хәтта укытучыларының дөньяга карашларын үзгәрткәннәр. «Беренче спектакльне чыгарганнан соң, балаларны үстерергә, башкаларга күрсәтергә кирәклеген аңладым. Безнең зур бурыч ул хәзер. Бу балалар үзләре бер дөнья», – ди Салават абыйлары. «Аларның яратып йөрүләре, көчле теләкләре безне бик рухландыра», – ди Гөлназ апалары. Ә Зөфәр абыйлары – балаларның Кыш бабайлары. Хыялларын тормышка ашыра бит. Балалар хакында сөйләгәндә Зөфәр абыйның күзләре яшьләнде. «Башлаганмын, өмет биргәнмен икән, артка юл юк. Аларның бит күзләре янып тора. Спектакльне чыгаргач, балаларның шатлануын күрүдән, хезмәтебезнең әти-әниләргә күпме куаныч, җылылык өләшүен тоюдан канатлар үсеп китә», – ди ул. Хәзер «Нәни принц»ны куярга әзерләнәләр икән. Димәк, озакламый «Могҗиза»да чираттагы могҗиза туачак.

БЕЗ – БЕР ДӨНЬЯ, БЕР ПЛАНЕТА!



Эльмира ЗАКИРОВА

Альбинаның ун ел элек уйлап тапкан идеяләре тормышка аша бара. Әле кайчан гына кечерәк бер гаилә балалар бакчасы ачып карарга тәвәккәлләгән иде. Анысы да үз баласына бакча эзләүдән башлана. Кайда яхшырак? Хыялындагы бакчага туры килердәйләре бармы? Юк икән... Баласын йөртәсе килгән бакча исә бөтенләй башкача күз алдында калка! Массачусетс технология институты тәҗрибәсе күңеленә аеруча хуш килә. Әнә аның галимнәре телләр өйрәнүнең интеллектуаль үсешкә уңай йогынтысын исбатлаган. Андый балалар математикага сәләтле, аларда креатив фикер йөртү, логика көчле ди. Һәм яшь әни илһамланып шул проектка тотына. Казандагы бер генә бакчага да охшамасын! Балалар дүрт-биш телдә сөйләшсен! Дөнья күләмендә конкурентлылыкка сәләтле булып үссеннәр!



Фото: Аида Сафина

Әгәр нәрсәне дә булса бик-бик теләсәң, бар җиһан аны тормышка ашыруда булыша икән. Бүген Альбина Насыйрова – Татарстанда бердәнбер булган Кембридж халыкара мәктәбенең һәм шәхси «Бала-Сити» полилингваль балалар бакчасы челтәренең генераль директоры.

Шәһәр үзәгендәге бу кызыл бинаның хәтта тәрәзәләре дә шунда укучы балалар күзләре булып карый сыман дөньяга! Заманча уку лабораторияләре, IT-кабинетлар, иҗат бүлмәләре, уңайлы класслар, мәктәп яны паркы... Кайнап торган мәктәп тормышы көзге-диварларда чагыла. Пыяла ишек-стеналар аркылы кайсы класста нинди дәрес барганын күреп узасың. Күрешкәндә укытучың сине кочаклап исәнләшә, үз тиңе күреп сөйләшә. Ә ял зоналарының кызыл, сары, зәңгәр төсләре кәефне күтәреп җибәрә. Монда фитнес-зал, медиаклуб... Робототехника, тирәнтен биология, кием дизайны, эстетик гимнастика, көрәш, кулинария осталыгы... Нинди генә түгәрәкләр эшләми! Яңа идеяң булса, туп-туры «Бала-Сити» директоры Альбина Мөнир кызы кабинетына керәсең. Колач җәеп каршылап, рәхәтләнеп тыңлаячак... һәм һичшиксез конфет белән дә сыйлаячак! «Креатив балалар укыган мәктәп үзе дә креатив булырга тиеш», – ди директор.

«Бала-Сити» белән бергә, аның генераль директоры Альбина Насыйрова да үсә. Шушы яшьтә үк баш әйләнерлек биеклекләр яуларга өлгергән. Бүген ул – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының иң яшь депутаты, Дәүләт Советында Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты әгъзасы, «Бердәм Россия» фракциясе әгъзасы, хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт» иҗтимагый оешмасы вәкиле. Ир хатыны, өч бала әнисе.

Уңышларның сере нидә? Язмышка ышанамы ул? Остазлары кемнәр? Бизнес-лединың үз балалары ничек үсә? Депутат булуны ничек кабул иткән? «Бала-Сити» тагын нинди яңа проектлар белән шатландырачак? Миңа барысы да кызык.

«Бала-Сити» кампусы. Генераль директор кабинетында рәхәт бер мохит. Затлы ак пәрдәләрдә, стенадагы картиналар, хәтта матур чынаякларда да хуҗасының нечкә

зәвыгы тоемлана. «Алдагы Яңа елның Россия күләмендә Укытучылар һәм остазлар елы дип игълан ителүен шатланып кабул иттек без, әйеме, әнием», – ди Альбина чәй хәстәрләгән арада. Каршымда – күренекле галимә Резеда ханым Мөхәммәтшина утыра. Педагогика фәннәре докторы, КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры, гомумән, студентларның бик якын кешесе. Аның тагын бер җаваплы вазыйфасы бар: ул «Бала-Сити»да фәнни җитәкче. Һәм алар әниле-кызлы сөйләшүебезне җай гына укытучылар, мәктәп, балалар дөньясына алып кереп китәләр.

Альбина Насыйрова. Генетика барыбер үзенекен итә: мәгариф өлкәсен якын итүем әнидәндер. Укытучыларның да укытучысы ул! Кечкенәдән үк әнигә ияреп мәктәпкә, педколледжга бара, аның укучылары, студентлары белән аралаша идем. Шул дөньяны күңелгә сыйдырып, укытучы эшенең уңай якларын да, кыенлыкларын да күреп үстем. Артист балалары сәхнә артында үсә, диләр. Укытучы балалары исә парта артында үсә, дияр идем. Әни университетта студентлардан зачетлар алганда да янында утыра идем әле. Миңа ошый иде ул мохит. Хәзер төрле илләрдә, төрле кыйтгаларда аның шәкертләре! *(Горурланып.)* «Мин Резеда Фаилевна укучысы», дисәләр, беләсезме, ничек рәхәт булып китә! Бу проектка алынгач та, әни хуплады: «Әлбәттә, булдырачаксың! Мин сиңа ярдәм итәм!» – диде. Һәм ул ун ел инде безнең дөньяда кайный. Эш вакыты 24/7 дигәнне еш кулланалар хәзер. Бары шулай эшләгәндә генә уңышка ирешеп буладыр.

Резеда Мөхәммәтшина. Әйе, укытучылар – ихтирамга лаек шәхесләр алар. Минем әнием Гөлчирә дә әнә шундыйлардан иде. Гомер буе остаз, укытучы булды ул. Безне китаплар, театр белән тәрбияләргә тырышты. Үзе көчле математик, алты урынлы саннарны күңелдән генә куша, ала, тапкырлый. Укытучы һөнәрен сайлавымда әнинең роле зур булды. Казан дәүләт педагогика институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кереп, аны кызыл диплом белән тәмамладым. Кияүгә чыктым, Альбина туды... Эшкә чыгарга атлыгып тора идем! Яшь ярымлык баланы әти белән әнигә калдырып, Казандагы 2 нче педагогика колледжына урнаштым. 15–16 яшьлек кызларның группа җитәкчесе, 28 сәгать дәресләр, класстан тыш эшләр, тикшереләсе дәфтәрләр... Ниләр генә эшләмибез! Әдәби викториналар, конкурслар, кичәләр... Толстой, Достоевский, Тургенев әсәрләрен укыйбыз, бәхәсләшәбез... Аларны әле Мәскәүгә, әле Пушкин йөргән җирләргә, Кировка «Алые паруса»ны язган Александр Грин музеена экскурсияләргә алып барам... Фестиваль уздырабыз. Класста «до, ре, ми...»лар яңгырап тора, репетицияләр ясыйбыз. Бииләр, җырлыйлар, мандолинада уйныйлар, рольләр башкаралар... «Дәрестән тыш вакытта балалар белән эшли белмәгән укытучы – укытучы түгел инде ул», – дип әйтә иде директорыбыз. Әгәр мәгариф министры булсам, педколледж тәмамлаганнарны гына педагогика институтына укырга алу тәртибен кертер идем. Анда чын укытучылар әзерләнә!

Сез фанат укытучы булгансыз инде, Резеда Фаилевна. Ә гаиләгезгә вакытыгыз кала идеме соң?

Р. М. Кич соң гына дәфтәрләр тикшерәм, ә үземнең күз яшьләрем дәфтәр битенә тама. Чөнки күрше бүлмәдән Альбинаның: «Әни-и-и!» – дип еламсыраганы ишетелә. Өстәлдә пыяла астындагы фотолардан утыз кызым, бер егетем елмая. Көннәрдән бер көнне институт кафедрасына эшкә чакырдылар. Бу хәбәрне группама әйттем. Минем иң бәхетле мизгелем: 31 е дә елады! Шушы минутларны тояр өчен генә дә яшәсәң була, минемчә! Үзем дә өйдә дә елыйм, институтта да. Миңа калса, укытучы һөнәре – иң кирәкле, иң мәртәбәле һөнәр! Башка бер профессиядә дә шушындый рәхәт мизгелләр юк! Инженерның да, юристның да, министрның да... Галимнәр тикшергәннәр – киләчәктә роботлар кереп, кайбер профессияләр юкка чыгачак икән. Ә укытучы, тәрбиячеләр – калачак! Бернинди робот та аларны алыштыра, яратуны, җылылыкны бирә алмаячак! Шунысы да бар әле: укытучының хезмәтләре, белемнәре, мәхәббәте кире әйләнеп кайта, эшенең нәтиҗәсе күренә, укучыларың синең юлны дәвам итә еш кына. Минем укучылар да соңрак пединститутка укырга керделәр. Балаларны минем кебек музейларга йөрттеләр... Укытучыдагы сыйфатлар укучыларга да күчә икән.

А. Н. Әнине куәтләп, минем дә бер фикер әйтәсем килә. Педагог Януш Корчакның шундый сүзләре бар: «Чит



■ Туган телне өйрәтү өчен кызыклы методикалардан файдаланып, яңа проектлар уйлап табабыз. Татарстан Президенты каршындагы Туган телне саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов исә бу башлангычларыбызны хуплап алды.

■ Бирелә Россия һәм халыкара укыту программалары буенча укыталар. Татар, рус, инглиз, кытай, испан телләренә өйрәтәләр. АКШ, Англия, Австралия, ЮАР, Канададан килгән укытучылар эшли.



кеше баласын да үзеңнеке кебек ярат», – ди ул. Менә шуны кечкенәдән күреп үстем мин. Укучыларын үз балалары кебек яратып, алар өчен атыла-бәрелә чаба иде әни. «Бала-Сити»да да шул җылылык, кайгырту сизелә. «Биредә гаиләдәге кебек рәхәт атмосфера», – диләр. Бездә һәр бала ратуга коенган. Замана психологлары исә: «Укытучыга яратырга кирәкми. Иң мөһиме – ихтирам, бала шәхесенә хөрмәт белән карау», – ди. Шулкадәр баланы ярату мөмкин дә түгел, дип тә әйтәләр әле. Мин килешмим.

Р. М. «Бала-Сити»да идеаль укытучылар дияр идем мин: предметны да беләләр, балаларны да яраталар! Баланың бакчага, мәктәпкә барасы килми, дигәннәрен ишеткән бар. Ә «Бала-Сити»да баланы бакчадан чыгара алмыйлар. Китмәс өчен елый балалар. Мәктәптә дә шул ук хәл. Бакча да, мәктәп тә җидегә кадәр эшли! Минем өчен бу зур күрсәткеч! Баланың өйгә кайтасы килми – димәк, аны яраталар, аңа кызык!

Альбина, син Ш. Мәрҗани исемендәге татар гимназиясендә укыганда ук остазларың күп иде бит...

Р. М. (*Елмая.*) Хәтердә, «Әни, Камәрия Зиннуровна кабинетына чәй эчәргә чакырды», – дип кайта иде Альбина.

А. Н. (*Сөенеп.*) Әйе! Ул хәтта: «Минем креслода утырып карыйсың киләме, Альбина?» – дип тә сорады әле. Килмәгән кая! Шулай итеп, директор кәнәфиендә дә утырып караганым булды. Хәзер дә аралашам Камәрия Зиннуровна белән. Аның һәр сүзе, фикере минем өчен кыйммәт! Безнең гимназиядә һәр баланы шәхес итеп күрә, үстерә белделәр шулай. Мин бик бәхетле ул яктан. Укытучыларым да күп булды. Телевидениедә Рамилә апа Сәхабетдинова мәктәбен уздым; җырчы Гөлзадә апа Сафиуллина сәхнә дәресләре буенча остазым иде; татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Флёра Рәисовна әдәбият, мәдәният дөньясына якынайтты. Мәктәп, белем бирүдән тыш, тормышка да әзерләргә тиеш баланы.

Р. М. Ягъни тормыш компетенцияләрен – Soft Skillsны бирергә тиеш ул. Бала креатив фикер йөртә, командада эшләргә өйрәнә, коммуникацияләре югары дәрәҗәдә була, үзгәрешләргә җайлаша...

А. Н. Ә боларга ирешү өчен кызыклы проектларны бергә алып барырга кирәк. Мин телевидениедә эшләгән еллар чын мәгънәсендә Soft Skills булган икән бит! Мәсәлән, миңа сюжет төшерергә кирәк иде. Үзем бала гына булсам да, төрле кешеләргә шалтыратып, информация җыеп, тәки тапшыру әзерләп кайта идем! Кем ТВ мәктәбе аша узган, аларга кайсы профессиядә дә бүген бик рәхәт, алар югалып калмый. Гимназиядә исә татар теленә, татар әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләп укыттылар безне. Күпме кызыклы очрашулар була, галимнәр, язучылар, артистлар килә. Флёра Рәисовна безне шагыйрь Фәнис Яруллинның өенә алып бара иде хәтта! Язучының кулъязмаларын алып килеп безгә укый. «Фәнис абыегыз өр-яңа әсәр язган. Ул әле китап булып та чыкмаган. Фикерләрегезне көтә. Сез рецензия языгыз, балалар», – дигәч, тырышып язганнарыбыз хәтердә. Безнең балаларга да шундый очрашулар кирәк. (*Истәлекләргә бирелеп.*) Ул курай дәресләре тагын. Шул кечкенә генә курай, ә никадәр көчкә ия! Милли тәрбия шул була инде. Моң нәрсә икәнен аңлап үсәсең. «Бала-Сити»да курай ансамбле эшләп килә. 15 бала зур ансамбль булып чыгыш ясый, татар көйләре үзенә бер аһәң белән яңгырый. Үземдә булганны кемгәдер калдыра алам бит дип сөенәм. Татар гимназиясе, телевидение, театр училищесы... Мәктәп елларында нәрсә ошаган, барысы да «Бала-Сити»га күчә бара.

Татар телен укытуга шулай ук зур игътибар бирәсез дип беләм.

А. Н. Әйе, зур проектларга тотындык: «Акыллы өстәл уеннары» уйлап чыгардык. Бөтен дөньядан җыелган өстәл уеннары системасы ул. Россиянең бер генә белем бирү учреждениесендә дә аңа тиңнәр юк. Тупланмага мәктәпкәчә яштәге балалар өчен ун өстәл уены керә. Татар теленә тәрҗемә ителгән һәм яраклаштырылган уеннар балаларны һәрьяклап үстерергә генә түгел, ә уен аша татар телен өйрәтергә дә ярдәм итә. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та танышты аның белән. Өстәл уенын уйнаганда бала тел өйрәнәм дип тә уйламый, ул мавыгып, кызыксынып уйный. Игътибар, фикерләү, хәтер, күзаллауны үстерә бу уен, үз-үзеңә бәяне арттырырга ярдәм итә, командада эшләргә өйрәтә. Балалар бакчаларында татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр бердәмлеген булдыру, аларны алдынгы педагогик кейслар белән таныштыру, татар те-



■ Кайнатам белән кайнанам шулай ук милли җанлы кешеләр. «Бала-Сити» беренче көннәреннән үк Динарның әнисе Зөбәйдә Хәсәновна, әтисе Назил Ярулловичның зур ярдәме белән яши башлады.

■ Гаиләдә «Бер көн – бер тел» дигән традицияне дә Динар уйлап тапты. Балалар белән дүшәмбе – татарча, сишәмбе – русча, чәршәмбе инглизчә сөйләшәбез өйдә.

Фотолар: гаилә архивыннан.



ләндә укытуның сыйфатын үстерү барышында туган проблемаларны чишү максатыннан оештырылды ул. Укытучылар үз методикалары белән бүлешә: балалар бакчасында келәмгә тезелешеп утырып, тәҗрибә уртаклашалар. «Мин менә бу курчакларны кулланам», «Мин шушындый җырлар өйрәтәм», – дип аңлаталар. Конференция рәвешендә чыгыш ясап уздырылса, тәэсире алай ук булмас иде. Ә фестиваль формасы бик үтемле булып чыкты. 1 яшьлекләр белән эшли торган программалар бар. «Әниләр һәм бәбиләр» проекты да бик кызыклы. Без аларны дөньякүләм проектлардан алып, үзебезгә яраклаштырдык. Дөньяда нинди көчле мәктәпләр, бакчалар бар, шушы ун елда барысын да карап чыктык. Аларны башкалар белән бүлешергә дә әзер без. Менә болар – милләт өчен, Татарстан өчен социаль проектлар, авторлык программаларым.

«Бала-Сити»ның уңышы нәрсәдә, Альбина?

А. Н. «Бала-Сити» – зур мәхәббәт белән тудырылган проект ул. Уңыш нәтиҗәләре кешеләрдән, командадан тора. «Бала-Сити» – ул мин генә түгел, 250 кеше эшли бездә. Меңләгән бала, биш балалар бакчасы, ике мәктәп. Төрле шәһәрләрдән, илләрдән җыйгач, укытучыларыбыз бик кадерле минем өчен. Чит илләрдән килгән укытучыларга без бик игътибарлы! Театрларга йөртәбез, милли ризыклар белән сыйлыйбыз. Кайгырту, гаилә җылысын тоеп яши алар. Үзебезнең бер дөнья, бер планета монда! Без сәясәт турында сөйләшмибез, безнең төп тема – балалар. Укытучыларыбыз балалар дөньясында яши. Әйтәләр бит, балалы өйдә гайбәт булмас, дип. Сәясәт тә юк, гайбәт тә юк, бала гына. «Бала-Сити»ның көче – укытучыларда. Ачыклар, янып торалар! Казан федераль университетының партнеры да без: иң әйбәт студентлар безгә практикага килә.

Мондый зур эшләргә алынып өчен янәшәңдә сине аңлаучылар, һәрчак ярдәм итәргә әзер торучылар да кирәк бит әле.

А. Н. Мин бик бәхетле кеше, бәхетле гаиләдә үстем. «Син булдырасың!» – дип үсендереп, дөрес тәрбияләделәр мине. «Бала-Сити»га да инде ун ел. Шул вакыт эчендә ниләр генә булмады! Әти үлде... Әле дә хәтерлим: ачыласы беренче бакча янында басып торам. Кулымда – бер тартма уенчык. Булышырга дип килгән энем Булат: «Апа, әти үлде», – диде. Бөтен уенчыклар кулымнан төшеп китте. Елый-елый йөгерүләребез истә... Югалтулар да, табышлар да күп булды. Хәзер инде минем Динар бар, аның әти-әнисе бар. Динарларның гаиләсе белән кушылгач, бу хуплаулар икеләтә көчәйде. «Ничек булышыйк? Нәрсә кирәк?» – дип кенә торалар. Проблемалар килеп чыга икән, төн йокламыйлар иде инде! Динар, аның әти-әнисе, минекеләр – һәр ике як та булышып, җан атып яши. Ирең ягыннан да таяныч зур булу кирәк. Ирләрнең, гадәттә, хатын-кызны бик күтәрәсе, үстерәсе килми бит. Ә Динар, киресенчә, «Бала-Сити»ны таныт, депутатлыкка бар, диде.

Дәүләт Советы депутаты Альбина Насыйрова нindирәк икән? Бу бит инде бик югары дәрәҗә!

А. Н. Монысы да – тормыш мәктәбе. Үзенә күрә яңа роль, яңа белем, яңа сыйфатлар. Күп балалы, авыру балалы хатыннар, ялгыз аналар килә миңа. Тыңлап, аларны тынычландыра белергә, психолог булырга кирәк. Булдыра алганча булышырга тырышам. «Бала-Сити» әти-әниләренә рәхмәт, һәрчак аларның ярдәмен тоям. (*Уйланып.*) Язмышка ышанам мин. Димәк, шулай язылган. Депутатлык эше дә тиктомалдан гына килеп чыкмаган. Хәйриячелек проектлары, хатын-кыз депутатлар белән ялгыз аналарга, авыру балаларга булышулар... Хәйриячелек турында еш уйлана идем. Ләкин депутат булганчы моның кадәр зур масштабларда эшләгән юк иде әле. Кемнәргәдер булыша алуым белән бәхетле мин, язмышыма, мине хуплаган кешеләргә рәхмәтле. Депутат булып сайлангач, башта әле күзләремне зур ачып, шаккатып йөрдем. Бик күп законнар, документлар белән танышып чыгарга кирәк. Юрист та, сәясәтче дә түгел, мин – филолог. Аннары депутатлыкка заявка биргәндә өченче баланы алып кайтырга әзерләнә идем инде. Җәй буе авырлы килеш сайлау алды кампаниясендә төрле очрашуларда катнашырга туры килде. Коллегаларым миңа һәрчак беренче итеп сүз бирәләр иде. «Ул тиздән әни булачак. Әйдәгез, аны тыңлыйк башта. Менә хәзер елмаеп сөйләячәк, һәм бар да әйбәт килеп чыгачак», – дип, рәхәт дулкынга көйлиләр иде. Монда команда шундый көчле! Күп нәрсәгә өйрәндем! Остазларым да җитәрлек. Фәрит Хәйрулловичтан башлап... (*Көлә.*)

Сине сайлау алды реклама щитларыннан да таныйлар иде!

А. Н. (*Елмая.*) Без анда өчәү идек. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, «КАМАЗ-мастер» командасы җитәкчесе Владимир Чагин һәм мин. Фәрит Хәйруллович: «Сез монда өч кеше дип уйлыйсызмы? Юк, без дүртәү! Сара да бар әле!» – дип шаярта икән. (*Көлешәбез.*) Кызыма Сара дип исем кушасыбызны беләләр иде инде. Үзем шул исемне теләдем. Сара апа Садыйкова көйләрен курайда уйнап үстем. Композитор җырларыннан төзелгән концертларны конферансье булып Мәскәүдә, Питерда, Финляндиядә алып барырга туры килгәне бар. Миңа бик якын ул исем.

Син кыз баланы тәрбияләүче әни дә бит әле, Альбина. Аны киләчәктә кем итеп күрәсез?

А. Н. «Кызым, син нинди?» – дип сорыйм Сарадан. «Мин батыр!», «Мин көчле!» – ди ул. (*Көлә.*) Әллә абыйлары белән үскәнгә инде, әллә заманасы шундыймы? Сизәсезме, хатын-кызлар заманы хәзер. Алар бөтен җирдә эшли, бөтен нәрсәне булдыра. Һәм бу дөнья күләмендә күзәтелә бит. Феминизм дип уйламагыз, ләкин моны бакчада да, мәктәптә дә күрәм мин! Кызлар үзләрен көчле дип санап йөриләр. Алар лидерлар.

Р. М. (*Җанланып.*) Әнә безнең Сара Аяз абыйсының боксер перчаткаларын киеп йөри. Азим абыйсы – хоккейчы! Сара да кәшәкә таягы тотып, «гол!» дип кычкыра. Абау, кызым, бераз назлырак булырга кирәк, дим. (*Көлә.*) Үсеп җиткәч, Сара укытучы булса, мин бик бәхетле булыр идем.

А. Н. 3 яшьлек Сара инде көязләнә дә белә. Киемнәр сайлый. Бизәнергә ярата! Хыялларым нинди булган булса, шуларга коенып үсә Сарабыз. Кызыма матур күлмәкләр кидереп, чәчләрен үреп рәхәтләнәм инде! Шулай яратып үстерәбез. Курчак кебек ул безнең! Бу көннәрдә Яңа елга әзерләнеп йөрибез. Һаман хатлар язабыз, бүләкләр көтәбез. Кыш бабай бар ул! Без могҗизага, якты киләчәккә, яхшылык тантанасына ышанабыз!

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



«Мәрхәмәтле балалар үстерсәк иде»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – шагыйрә Гөлүсә ШАҺБАН һәм аның кызы АЛИСӘ.

Алисә, кечкенә чагыңда Кыш бабайга ышана идеңме?

– Әйе, ышана идем. Әле сигезенче сыйныфларда гына Кыш бабайның юклыгын чамалый башладым. Мантыйк буенча, бүләкне әти-әни әзерләгәнне аңладым. Кыш бабай «бүләк иткән» иң зур бүләгем – ачылмалы телефон. Авылда урамга алып чыгып, күрше малайлары алдында да мактандым. Хәзер дә искә төшереп көлешәләр. «Без белгән идек инде әти-әниең бүләге икәнен, сиңа әйтмәдек кенә», – диләр. Мине могҗизаларга ышандырып үстергәннәре өчен әти-әниемә бик рәхмәтлемен. Балаларга бик кирәк ул. Үскәч, болай да дөнья мәшәкатьләренә чумасың. Шуңа күрә балачактан ләззәт алырга мөмкинлек бирергә кирәк дип саныйм. Ә балачакны әкиятләр, могҗизаларга ышану яшәтә.

Ә үсмерлек чорында могҗизага ышануны нәрсә алыштыра?

– Төрле кызыксынулар, шөгыльләр барлыкка килә башлый дип уйлыйм. Һәр үсмернең үз кызыксынуы бардыр, мөгаен. Кемдер компьютер уеннары белән мавыга, кемдер – спортта, кемдер китаплар укый, ә мин менә тортлар пешерә башладым. Бу шөгылем барлыкка килүе дә юкка гына түгел. Бала-чага тортка, бигрәк тә матур итеп бизәлгәненә мөкиббән бит. Торт алар өчен һәрвакыт бәйрәм, ә бәйрәм ул – серлелек. Менә шул бәйрәм рухын тормышымда дәвам итәсем килгәндер, мөгаен. Торт пешерүнең процессы кызык, тынычландыра ул. Мин аны эшкә дә санамыйм. Кызыксынуым хәзер инде хоббига әйләнде. Профессиональ кондитерлардан курслар сатып алып, бу өлкәдә белемемне камилләштерәм. Хоббием акча китерә инде хәзер.

Димәк, син хәзер әти-әниеңнән кесә чыгымнары өчен акча сорамыйсың?

– 14 яшьтә беренче акчамны эшләдем. Әмма мин аны туздырырга түгел, җыярга яратам. Дөрес, бәйрәмнәрдә әти-әниемә бүләкләр алып, аларны куандырырга тырышам. Әнидән акча сорамагач та рәхәт. Үсә башлагач, һаман акча сорап йөрү оялта бит инде. Бу хоббием миндә күпмедер күләмдә мөстәкыйльлек, үземә ышаныч булдырды.

Син – гаиләдә бер генә бала. Берүзеңә күңелсез түгелме?

– Кечкенә вакытта күңелсез булгандыр, әти-әнидән сеңелкәш, энекәш алып кайтыгыз дип һаман сорый идем. «Ярар, кибеттән сатып алып кайтырбыз», – диләр иде. Хәзер ялгызлык тоймыйм. Туганнан туганнарым күп, дусларым бар. Аралашып яшибез. Әни белән без бик якын. Дуслар, егетләр белән аңлашылмаучылыклар туса, гел әнидән киңәш сорыйм. Миңа әби дә киңәшләр бирә. Авылга кайткач, гел тормышка өйрәтеп йөри. Мин аны тыңларга бик яратам. Әбинең яраткан сүзе бар: «Укыганнан сорама, яшәгәннән сора».

Син үзеңне әти кызы дип әйтә аласыңмы?

– Әйе, әйтә алам. Әти белән безнең холыклар да охшаш. Беренче сыйныфтан башлап әти миңа дәресләр әзерләшергә ярдәм итте. Теманы аңлап җиткермәсәм, һәрвакыт әтидән сорый идем. Ул бик гыйлемле кеше. Математиканы, рус телен бик яхшы белә. Әти белән иншалар яза идек. Унберенче сыйныфны аның белән бергә укып чыктык инде.

Алисә, синең егетләр белән йөри торган чагың хәзер. Ничек уйлыйсың, очрашып йөргән егетне әти-әни белән таныштыру кирәкме?

– Мин әле таныштырмадым. Әмма таныштырырга кирәк дип саныйм. Бу иң элек әти белән әнинең күңелләре тыныч булсын өчен кирәктер. Аннан соң, алар күбрәк яшәгән, күбрәк белә, күбрәк күрә дә бит әле. Әнидән серләрем бөтенләй юк. Әтидән бар әле. Ул кырысрак безнең.

Әти-әниеңне калдырып, читкә укырга китү турында уйлаганың бармы?

– Укырга китү планда бар иде. Әни белән ике арадагы иң авыр проблема булды инде ул. Аның бер дә җибәрәсе килмәде. Аннары инде үземнең дә теләк бетте. Минем өчен Казан уңайлы, рәхәт шәһәр.

Күңелең белән син кайда ял итәсең?

– Өйдән дә рәхәтрәк урын юк. Китаплар укыйм, файдалы видеолар карыйм. Музыка тыңлый-тыңлый рәсем ясарга да, музыканы кычкыртып куеп биергә дә яратам. Мин яратуда үскән бала. Өйдәге рәхәт атмосфера башка беркайда юк.

Гөлүсә, син нинди үсмер идең?

– Мин елак идем. Мактасалар да, ачулансалар да елый идем. «Кызым, синең түбәндә чишмәң бардыр, бер туктамый гел агып кына тора», – дип әйтә иде әни. «Син бик бәхетле, Гөлүсә. Рәхәтләнеп, күз яшьләреңне агызып елыйсың. Елый алган кеше бик бәхетле ул», – дия иде укытучы апам. Закирга (җырчы Закир Шаһбан – *Ч. Г.*) кияүгә чыккач кына ныгыдым, тормыш еламаска өйрәтте. Кечкенәдән үк үземә генә хас үҗәтлек бар. Без инде эшләп үскән буын. Бик изге күңелле, «юк» дип әйтә белми торган бер бала идем.

Кызың үзеңә охшаганмы?

– Охшашлык бар. Бик йомшак, мәрхәмәтле бала ул. Минем өчен хәзерге балаларда иң мөһиме – күңелләрендә мәрхәмәтлелек булу. Балалар бик усал бит. Алисә кешене жәлли, борчыла белә.
Шул сыйфаты бик ошый. Миңа караганда, эчке рухы көчлерәк. «Юк» дип әйтә белә, үз фикере бар.

Мәрхәмәтлелек, дип әйттең. Җәмгыять бик кырыс бит ул. Көндәшлеккә сәләтле, әрсезләр заманы...

– Кеше башына басып, кемнәрдер бәрабәренә яулап алынган дан нәтиҗәле булмый ул. Мәрхәмәтлелекнең беркайчан да көн кадагыннан, кешене кеше иткән сыйфатлар исемлегеннән төшеп калганы юк әле. Мин ярдәм иткән кеше, бәлки, кирәк чакта ярдәм итмәс, аның ярдәменә ышанып яшәү дә дөрес булмас, әмма Аллаһы Тәгалә бар бит әле. Изгелек җирдә ятмый дип, тикмәгә генә әйтмиләр. Иң кирәк вакытта ул барыбер әйләнеп кайтачак сиңа. Мин балама кечкенәдән шуны сеңдереп үстердем.

Алисә сигезенче сыйныфка кадәр Кыш бабайга ышанып үстем, ди. Бу могҗизаны шулай озакка сузу тормыштагы кечкенә бер самимилекне саклап калырга тырышу идеме?

– Ниндидер максатлар тотып эшләнмәде ул. Мин үзем бала күңелле. Балалар белән бала булып чана шуып йөрүләр, алар белән бергәләп бәйрәм көтү, могҗизага ышанулар үзе бер рәхәтлек бит ул. Икәү утырып Кыш бабайга хатлар яздык. Ул матур бер традиция иде. Безнең балалар да үз балаларына шундый могҗиза тудырыр. Могҗиза көтеп яшәү үзе бәхет бит инде ул. Белгечләр әйтүенчә, балага әйбәт эмоцияләр бирү сәламәтлеге өчен дә файдалы. Андый балаларның иммунитеты нык була.

Хәзер балаларны балалыктан бик тиз алып чыгарга тырышалар. Аларның, дөресен генә әйткәндә, уйнарга да вакытлары юк. Күп вакыт үсмерләр генә түгел, балалар да әти белән әни арасында арадашчы ролен дә үти...

– Әти белән әни арасындагы аңлашылмаучылыкларда баланың берннди катнашы да булырга тиеш түгел. Бала – бала булып үссен инде ул. Аның тормышы үзе гаилә коргач кына башлана. Алар әле әти-әни мөнәсәбәте арасындагы конфликтларга, тормыш проблемаларына психологик яктан әзер түгел. Нигә психикаларын яраларга?! Һәрнәрсәнең үз вакыты. Балаларны гаилә мөнәсәбәтләрен ачыклауда катнаштыру – аларның балачагын урлау ул.

Күпчелек хатын-кызларның бер хатасы бар. Алар ирләре белән ачуланышалар да, балаларга әтиләрен хурлап сөйли башлыйлар.

– Андый очраклар бар, әйе. Тормыш булгач, төрле вакыт була; никадәр генә мактанып, үзебезне идеаль итеп күрсәтергә тырышсак та, табак-савыт шалтырамыйча гына тормый, хәтта соңгы чиккә җиткән вакытлар була. Һәрвакыт Алисәгә әйтәм: «Мин әтиеңә бер көн ашарга пешермәскә мөмкинмен, ләкин син әтиеңә теләсә кайсы вакытта җавап биреп, ашарына пешереп, ашатырга тиешсең. Әтиең белән мөнәсәбәтләребез нинди генә булса да, ул синең әтиең!» Кайвакыт Алисә әтисе эндәшкәч җавап бирми торса, шундук шелтәләп алам. «Ул синең әтиең. Сине үстергән, синең өчен тырышкан, нишләп әтиең эндәшүе белән йөгереп килмисең», – дип әйтәм. Безне әниләр дә шулай дип үстерде. Нинди генә булмасын, әти – әти инде ул! Баланың әтисенә карата хөрмәте бетә икән, әнинең бала каршында абруе югала.

Алисә – синең бердәнбер кызың. Элеккеләр, ике бала – бер бала, бер бала – юк бала, дигәннәр. Бу фикергә мөнәсәбәтең.

– Бер баламы гаиләдә, биш баламы – һич тә мөһим түгел. Бары Аллаһы Тәгаләдән сорарга кирәк: тәүфыйклы булып, әти-әнине хөрмәт итеп, яратып яшәсеннәр. Әти-әниләренә бурычлы булуларын тойсыннар. Дөрес, психологлар хәзер, балалар безгә берни тиеш түгел, диган фикерне алга сөрә. Мин аны ялгыш фикер дип саныйм. Баланың әти-әнисен тәрбияләве, аңа кадәр әби белән бабайның онықларын карашуы татар гаиләсенең зур бер традициясе, буыннан-буынга шулай килгән инде ул. Юк, ул алышбиреш мөнәсәбәтендә булырга тиеш түгел, балаларны ике арада җылылык, гармония булсын дип тәрбияләргә тырышырга кирәктер. Безнең халыкның тәрбиясе бик дөрес булган.

Мөстәкыйль тормышка чыгарып җибәрергә әзерме инде син кызыңны?

– Апа кияүгә киткәч, елаганымны хәтерлим. Әйтерсең лә башка аралашмаячакбыз. Ә бит ул тормышның бер этабы гына. Бала үз гаиләсе белән яши башлагач та аралар өзелми инде ул.
Үз илебездән читкә генә китмәсеннәр. Чит илләргә бәхет эзләп китүчеләр бар. Бәхет бит ул синең үзең белән. Яшәгән җиреңдә дә бәхетле була аласың. Балалар чит илләргә китеп, тамырлар өзелмәсен иде. Бөтен теләгем шул.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна Арахамия

«МИН – ТЫРЫШ КЫРМЫСКА...»



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Берсендә Мәскәүгә командировкага барганда, вагонда аның урыны башкаладан Казанны күрергә килгән өч ханым белән янәшә туры килә. Поездга утырыр алдыннан гына китап кибетендә булганнар икән – барысының да кулында балалар китаплары. Ул бизәгән китаплар! Түзми: «Гафу итегез, татарча укый алмыйсыз бит, бу китаплар сезгә нәрсәгә?» – дип сорый. «Монда бит рәсемнәр барысын да үзләре сөйли!» – ди Мәскәү ханымнары.

– Соңрак: «Мин ясаган рәсемнәр», – дип әйттем әйтүен, әмма ышанмадылар бугай, – дип елмая ул.

Әңгәмәдәшем – Татарстанның халык рәссамы Фәридә Шаһимәрдан кызы ХӘСЬЯНОВА. Бакый Урманче исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларының иң беренчеләреннән, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе... Хәер, алган мактаулы исемнәрен, дипломнарын, катнашкан күргәзмәләренең барысын санап чыга алмам. Бизәгән китапларын да! (Кызык: ул китапларны укып үскән балаларның саны күпме икән?!) Кемдер өчен иң беренче чиратта ул – фольклор һәм концерт милли костюмы иҗат итүче, ә кемдер өчен – натюрморт остасы... Күпкырлы талант!



ТАМЫРЛАР Әтием – Арча ягыннан минем. Нәсел тамырларым – шуннан, ул минем өчен туганнарым яшәгән җир, кайтып көч алып килә торган урыным... Бабамнар, ерак бабамнар – барысы да тегүчеләр булган. Революциягә кадәр Фатыйх бабам Санкт-Петербург салоннарында фракларга кадәр теккән. Тегү машиналарын алып, зимагурлар кебек кышын читкә чыгып китеп, кешегә туннар тегеп йөргән алар. Ә язын өчәр пар ат җигеп кире кайтканнар. Рәсем ясаганда вак детальләр белән мавыгуыма күпләр шакката миңа. Ә мин яратып, бирелеп, тәмләп эшлим – геннарда ул минем. Бабаларым һәр җөйне шулай салгандыр... Роберт Миңнуллинның «Күчтәнәч» китабы форзацында персонажларым әнә 58 әү!

Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» китабын күз яшьләре белән укыдым. Кайбер урыннарында үксеп елыйелый... Минем бабамнар турында язылган кебек тоелды. Алар да – репрессия корбаннары... Әбием вагонда – бала тапкан вакытта үлә. Ә бабай аннары вагоннан кача. Китапны укыганда бабайның болар хакында миңа сөйләгәннәре кинәт искә төште. «Безнең әби кайда, ул кая китте?» – дип аңардан соравым... Кечкенә идем әле.

Әнием ягыннан тамырларым турында күп белмим. Алар да репрессиягә эләккән. Аның исән калуы исә үзе бер могҗиза! Әтисеме, әллә әнисеме, башка кешеме, Мәскәүнең «Казан» вокзалына килә дә: «Кем Казанга кайта?» – дип сорый һәм... 2 яшьлек әнине берәүләр артыннан биреп җибәрә. Качырып алып кайтып, Яңа бистәдә яшәүче әбисе кулына төнге сәгать өчтә ишек шакып калдырып китәләр... 5 яше тулганчы әнине бөтен кешедән яшерәләр. Әнисенең ирләре сугышта үлгән апалары үстерә аны. Язмыш аларны аерган вакытта 9 яшьлек булган абыйсын соңыннан әни бик озак эзләде, тапмады.

Безнең әти әнине бик яратты – ул дип кенә яшәде. Ишегалдында «Таһир белән Зөһрә» дип йөрттеләр аларны... Әни хәтта үләсе көнне дә: «Мин бик бәхетле булдым. Әтиең белән бер-беребезне яратышып өйләнештек, матур гомер иттек», – дигән сүзләрне әйтте. Әтидән калып, сигез ел ярым яшәде ул. Аны югалту хәсрәте шулкадәр зур булды – бер-бер артлы биш инсульт кына кичерде. Чибәр иде безнең әти! Кара чәч, зәңгәр күз, җемелдәп торган тешләр... Үзе гел елмая! Шигырьләр яза, бик матур рәсем ясый. Укырга туры килми аңа – 17 яшендә фронтка чыгып китә. Сугыш тәмамлангач та биш ел хезмәт итә әле. Бөтен күкрәге тулы орден иде. Танкист булган, биш контузия алган, яраланган – аксап йөри иде. Үземне белә башлаганнан бирле без һәр төнне әтинең кычкырган тавышына уяндык: «Ура-а-а!.. Вперед!... Бей его!..» Гомер буе – бер көн калмыйча төшендә сугыш күрде ул... «Сугыштан соң биш кенә ел яшәсәм дә, иң бәхетле кеше булам», – дип әйткән булган. Шөкер, 75 кә җитте!

Әти белән әни «Радиоприбор» заводында эшләделәр. Бик тыйнак яшәдек. Икесенә 180 сум хезмәт хакы иде аларның. Әнинең гел: «Кызым, акча юк бит», – дигәнен ишетеп үстем. Мин эшли башлагач кына, ни теләсәләр, шуны ала алдылар. Әмма байлыклары булмаса да, алар, әйткәнемчә, үзләрен бик бәхетле санады... Бөтен балачагым әтинең иңбашында үтте – яраткан кызы идем. Әнигә охшаганга күрә дә ярата



Фото: Алсу Шакирова

иде ул мине... Әти кая барса да, муенындагы шарф кебек аңа тагылам. Еллар узгач аңладым: әни моны махсус эшләгән – әтинең нинди чибәр икәнен белгәнгә аны беркая да үзен генә җибәрмәгән. Әтине күргәч, каршыга очраган хатын-кызлар тигез генә барган җирдән абыналар иде бит. Сугыштан соңгы чор: ир-атларның болай да кадерле чагы.



БАЛАЧАК Мин Шамил абыем белән бергә үстем. Ул бер яшь тә өч айга гына зуррак – без яшьтәшләр диярлек. Аңардан бернәрсәдә дә калышырга теләмәдем. Абый уйнарга кая бара – мин дә шунда. Ә ул, әлбәттә, үзе кебек малайлар янында. Бездән ерак түгел иске бер йортның сүтелеп бетмәгән өлеше – бер стенасы бар иде. Ун метр биеклектәге шул стена башына менеп йөгерә идек. Шактый олы яшькә җиткәч, берсендә шул стена буйлап йөгергәнемне төшемдә күрдем. Шундый куркып, шабыр тиргә батып уяндым... Берсендә койма башыннан карга сикереп төшәргә теләдем һәм... пальто итәгем белән коймада эленеп калдым. Ярты сәгать эленеп торганмындыр. Пальтомны ертмыйча ала алмадылар. Елап кайтып кердем. Ә әти... кире ишек төбенә чыгарып бастырды. «Минем кызым болай елап кайтырга тиеш түгел. Елап бетергәч керерсең», – диде. Безне кызганучы булмады... Бераздан авызымны ерып: «Мин кайттым, әтием!» – дип ишекне ачтым. Абыйны да, мине дә кырыс, бик кырыс тәрбияләделәр... Өйдә нәрсәләр эшләргә тиешлегем турында озын бер исемлек бар иде. Ә үзем өч мәктәптә укыйм: гади мәктәптә, рәсем һәм спорт мәктәбендә. Барысына да өлгерәм: идән юарга да, тузан сөртергә дә, хәтта әниләр эштән кайтышка нәрсәдер пешерергә дә... Холкымдагы төгәллек шул вакытлардан ук килә. Мин менә күбрәк акварель яки гуашь белән ясыйм. Майлы буяу түгел инде болар... Бу буяулар белән эшләгәндә рәсемеңне үзгәртә яки төзәтә алмыйсың: күпкатлылыкны яратмыйлар – бер генә тапкыр ясарга тиешсең. Алар синнән бик нык дисциплиналы булуны һәм үз-үзеңә ышануны таләп итә! Соңгысын үз-үзеңә чамадан тыш ышану белән бутарга кирәкми, ул – еллар белән килгән тәҗрибә... Акварель буяу синнән төгәллек көтә!

Безнең әти кайчандыр рәссам булырга хыялланган, тик сугыш комачаулаган. Башта ул Шамилдән рәссам чыкмасмы дип өметләнде. Ә абый утыра да пистолет, мылтык, танк, самолет рәсеме ясый... Шамил офицер безнең, подполковник – әти аның белән бик горурланды.

Үземне белгәннән бирле әти безгә китап укыды. Китапка тотынуга, миңа: «Ә син, кызым, яса», – дия иде. Ул укый, ә мин шул әкиятләрнең сюжетларын ясыйм...



УКУ Абый белән икебез дә яхшы укыдык. Шамил математика, физика буенча шәһәр, республика олимпиадаларында катнашты. Мин дә 11 нче мәктәпне тәмамладым, математиканы тирәнтен өйрәнү классында укыдым. Бөтен укытучыларыбызның да атказанган дигән исеме бар иде. Рус теле укытучыбыз – дворяннар нәселеннән. Революциядән соң ул Истанбулга китә, аннан кире кайта. Бу яктан бәхетле идек: алар үзләре алган тәрбия элементларын безгә дә бирде. Сәнгать мәктәбенә укырга кердем,

анда китапханәчебез шулай ук дворяннар гаиләсеннән иде. Рәссамнарда күзәтү сәләте бар: мин дә аларның сөйләшүләрен, үз-үзләрен тотышларын күзәттем. Кеше буларак формалашуыма барысы да тәэсир иткәндер...

Берничә көн авырып бармаган идем, мин юкта сәнгать мәктәбенә Даниянең атаклы рәссамы, карикатурачы Херлуф Бидструп килгән. Җәйге практика рәсемнәрен элгән вакыт иде. Эшләребез аны сокландырган! Аңа аеруча ошаган биш эшнең өчесе минеке булган... Сәнгать мәктәбендә миңа шуннан соң тагын да ныграк игътибар итә башладылар. Укытучыларыбызның 70 проценты Санкт-Петербургта Репин исемендәге институтны тәмамлаганнар иде. Белемлеләр! Бездән дә шуны таләп иттеләр. Константин Васильевич Ларин дигән укытучым, мәсәлән, миңа укырга көн дә әдәбият ташый иде. Остазларымнан нәрсәдер алсам, аның барысын да сәнгать мәктәбендә алдым.

Мәктәптән соң туп-туры Н. И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесына барып кердем. Укытучылар: «Ә без синең белән нишләргә белмибез», – диләр... Тиз эшли идем, шуңа күрә үземә максатлар куярга өйрәндем: монысын Ван-Гог кебек ясыйм, монысын... Беренче «обход» вакытында ук барлык эшләремне урладылар: IV курстан өч-дүрт кыз үзара бүлешкән. Римма Зиннәтова белән бөтен натюрмортларны бергә ясаган идек, шуңа күрә эшләрнең минеке икәнен исбатлау авыр булмады.

Группадашларымның барысы да диярлек җитеш гаиләләрдән. Матур киенәләр! II курста укыган вакытым. «Әни, кызлар Сорочи базарыннан джинсы күлмәк алганнар. Без дә барып карыйк әле», – дим. Барып таптык. Ә ул күлмәкләр 250 шәр сум! «Кит, кызым! Кайдан алыйк мондый акча?!» – ди әни. Кире борылып кайттык. Күземдә яшь... Ә әтинең бер хезмәттәшенең улы – Ильяс Субаев – Татарстан китап нәшриятында штаттан тыш рәссам булып эшли икән. Идрис абый әтигә: «Синең дә кызың бик матур ясый бит. Нигә барып берәр эш сорамый?» – дигән. Байназар Әлминов баш рәссам иде ул чакта. Без аның янына Зифа Мөхәммәтҗанова белән икәү киттек. Эш алып кайттык! Айга 200–250 шәр сум түләделәр. Зифа да, мин дә киендек... Шулай итеп, 16 яшемнән эшли башладым.



УҢЫШ Беренче шәхси күргәзмәм 1973 елда, училищены тәмамлауга булды. Уңышларыма артык игътибар да итмәдем бугай – һәрхәлдә, алардан башым әйләнмәде. Ничектер, шулай булырга тиеш кебек кабул ителде. Дөрес, кемдер килеп: «Ә бу китапны сез бизәдегезме?» – дип сораса, күңелле иде, әлбәттә. Бакый Идрисович берсендә: «Фәридә, рәссамны алга бер генә нәрсә этәрә – соклану», – дигән иде. Бу сүзләрнең мәгънәсен яши-яши аңладым. Әйе, рәссамны кулына кылкаләм алырга мактаулы исемнәр, дан-дәрәҗә этәрми... Менә әле үземә бүләк иткән пионнар – чалмабашлар бәйләменә сокландым да, утырып натюрморт ясадым...

1979 елны улым Айрат туды. «Зур Идел» күргәзмәсе узды ул елны бездә. Аны бертуган Ткачевлар, Гелий Коржев, Дмитрий Жилинский кебек рәссамнар җитәкләде. Совет сәнгатенең эталоннары! Аларның эшләре хәзер Дәүләт Рус музеенда, Третьяков галереясында тора... Мин бу күргәзмәдә Тукайның балачагы буенча ясаган иллюстрацияләрем белән катнаштым. Күкрәк баламны калдырып, күргәзмәнең ачылышына килә алдым. Гелий Коржев миннән: «Ә сез кайда эшлисез?» – дип сорады. Интерьерны бизәү эшләре белән шөгыльләнә идем – ул чакта дизайн димиләр иде әле. «Нәрсә? – диде ул аптырап. – Сез китап бизәүче рәссам булырга тиеш!» «XX гасырның Леонардо да Винчие» дип йөртәләр иде аны. Һәм шул рәссам миңа шушы сүзләрне әйтә! Әлеге сөйләшү җитте. 500–700 шәр сум хезмәт хакы алып эшли торган эшемне ташлап, Татарстан китап нәшриятына килдем – гади сәнгать редакторы булып. Аннан инде бүлекне җитәкли башладым – нәшриятның баш рәссамы булдым. Китап бизәүче рәссам булып эшләү бик зур җаваплылык ул. Син яшәгән дәвернең бер истәлеге, дәлиле булып калачак буыннарга кала бит ул китап.

Хәзер компьютерда барысын да эшләргә була: рәсемеңдә берәр линия артык икән – алып ташларга яки, киресенчә, өстәргә. Ә без ул чорда бары акварель буяулар белән генә эшләдек. Ясаган рәсемеңнең сыйфаты үзгәрмәсен, оригинал белән оттиск арасында аерма килеп чыкмасын өчен барысын да искә алырга кирәк иде. Валидолга тотынган чаклар да булды... Кайчак зур-зур тиражларны бракка чыгарырга туры килде. Офсет ысулы белән басуны республикага мин керттердем дисәм дә була. Типографиянең ул чактагы производство бүлеге җитәкчесе Дилбәр Хәйруллинадан хәтта моны таләп иттем... Китап графикасы өлкәсенә килүемә – 54 ел. Ул чакта рәсемнәрем белән Абдулла Алишның китабы чыгуга, мине авторлар эзли башлады. Аларның барысын бер күрдем – берәүне дә аермадым. Роберт Миңнуллинга тугыз китап эшләдем. Шәүкәт Галиевкә, Туфан Миңнуллинга... Ренат Харисның: «Менә бу кульязмага алынмассызмы?» – дип, беренче тапкыр яныма килүе истә. Булачак «Лап-лап» китабы иде ул. Кульязманы кулга алып берничә мизгел узуга ук тышлыгын күрдем... Ул елларда бик күп эшләнде. Еш кына моны башка сәбәп белән дә эшләргә туры килде. Кайбер рәссамнар заказны ала, әмма вакытында китерми. Аларның айныганын көтәргә вакыт юк – китапны тапшырырга кирәк. План яна! Синең бүлек премиясез калырга мөмкин... Харис ага Якупов: «Син бит энә белән кое казыйсың», – дия иде миңа. Сүз уңаеннан, нинди талантлы рәссамнар белән сөйләшү, аралашулар насыйп булды миңа: Бакый Урманче, Виктор Кудельки́н, Лотфулла Фәттахов, Кәнәфи Нәфыйков, Евгений Зуев... Һәрберсе шәхес! Иң гаҗәпләндергән сыйфатлары тыйнаклык иде. Дөрес, талантлылар бүген дә тыйнак алар. Рөстәм Хуҗин, Диләрә Нәүрүзова, Максим Покалёв, Елена Ермолина, Булат Гыйльвановлар... Безнең республиканы теләсә кайсы халыкара аренада күрсәтә алырлык рәссамнар болар.

Читкә киттем. Китап бизәү турында сөйли идем. Кемдер: «Нәрсәсе бар инде, утырган да ясаган», – дияргә мөмкин. Бер кыллы кылкаләм белән эшләгәненңе син үзең генә беләсең... Хәер, аңлауны көтәргә кирәкмидер дә. Мин үзем моның өчен түгел, ә эшли алмыйча тора алмаганга эшлим. Кулымнан кылкаләм төшә икән, яшәүдән дә туктыйм. Авырый башлыйм: сәламәтлек белән бәйле әле бер, әле икенче проблема килеп чыга... Рәссам һөнәре монахлык тормышына охшаган: син көндәлек мәшәкатьләрдән китәргә

һәм үзеңне эчке дөньяңа багышларга тиешсең. Ул синнән фанат булуыңны таләп итә. Ир-ат рәссамнарга, әлбәттә, җиңелрәк. Без гаилә турында уйларга, үзебезне балаларга, өлкәнәйгән әти-әниләргә дә багышларга тиеш. Хатын-кызның өстендә бурычлар һәрвакыт күбрәк.



МӘХӘББӘТ Минем кебек иҗатка, үз һөнәренә бирелгән кешеләр, гадәттә, шәхси тормышта бигүк уңмыйлар. Аннан кырыс гаиләдә үскән кызлар хулиганрак егетләрне үз итә. Язмыш шулай башка юлга кереп китә. Миңа да «начарлар» күбрәк ошады шул... Иҗат белән мавыгып, янәшәмдәге чиста, ихлас, җылы хисләрне күрмәгәнмен. Бүгенге күзлектән карап моны тагын да ныграк аңлыйм. Мине күбрәк саклый, яклый алучылар булган югыйсә... Әмма үземне хатын-кыз буларак бәхетсез дип санамыйм. Барысы да булды: мин дә яраттым, мине дә яраттылар. Үкенечләрем юк... Үземне ялгыз хис итмим. Менә дигән улым бар. Ике оныгым үсеп килә. Аязга тиздән – 12, Әминәгә 4 яшь тула. Кечә Әминә шалтырата: «Дәү әнием, син тазардыңмы инде? Дәваланырга кирәк, мин бит сине бик сагындым, күрәсем, үз өемә кайтасым килә», – ди. Минем фатирны үз өе дип саный ул. Кодагыйга рәхмәт – оныкларым чип-чиста татарча сөйләшә!



ДУСЛАР Дусларым бик күп минем! Зифа Мөхәммәтҗанова белән училищедан бирле дус булдык. Ул арабыздан киткәнгә кадәр. Зур югалтуларымның берсе ул Зифа... Рәссамнар Алсу Тимергалина, Лилия Золондинова белән дә якын дуслар без. Резедә Ахиярова белән көн дә бер шалтыратышып, хәлләр белешеп алабыз. Әйе, дусларым күп, проблема исә башкада – аларга вакыт бүлеп җиткерә алмыйм кайчакларда. Үз яшемә үзем ышанмас яшькә җитсәм дә, гел нииндидер планнар, проектлар белән яшәп яткан көн бит әле. Элек тиз генә эшләп куйган кайбер нәрсәләрне өчләтә озаграк эшләвемне дә сизәм хәзер. Рәссам буларак, үземә таләпләрем арту белән дә бәйледер бу. Үзем бик ошаткан эшләрем, гомумән, юк: яңадан кулга алырга туры килсә, гадәттә, гел гаепләрен күрә башлыйм. Нинди гадәттер... Әле менә улым бакча йортын сүткәндә чормадан «Әти авылы» дигән картинамны тапкан. Шундый дулкынланган: «Әни, әйдә багетын яңартыйк!» – дип, остаханәмә үк күтәреп килгән. Ә мин карадым да, кинәт үземә оят булып китте. Әллә никадәр кимчелеген күрдем! Нинди генә күргәзмәләргә куелмады ул – ничек берсе дә игътибар итмәгән?! «Юк, улым, болай гына булмый әле», – дим. Яңадан эшли башладым. 95 процентка әзер иде инде ул. Ә аннан остаханәмә су үтте дә, барысын да диярлек юды – су тимәгән бер почмагы гына калды. Шул картинамны кабат торгызу белән шөгыльләнәм. Мин аны хәзер «1983 елның җәе» дип атарга телим.



АКЧА Акча минем өчен бернәрсә дә түгел дип әйтү өчен җүләр булырга кирәктер. Әмма тормышта акчаны иң беренче урынга кую да дөрес түгел. Бәхет акчага берничек тә бәйләнмәгән. Югыйсә дөньяның иң бай кешеләре, аларның балалары арасында үз-үзенә кул салу очраклары булмас иде. Кинәт кенә баеп киткәннәргә дә кызыкмыйм, гадәттә, алар бик тиз тормышның ямен-тәмен, аннан якыннарын югалталар... Акчага дип тотынсам, ул заказның очына чыга алмый аптырый идем. Үз-үземне шуңа күрә беркайчан ирексезләмәдем – яраткан эшемне генә эшләдем. Теләмәгән эшкә тотынырга мине беркайчан беркем мәҗбүр итә алмады. Бу – бик зур бәхет.

Мин бөтен эшләгән акчамны әниләргә кайтарып бирә идем. Соңгы тиененә кадәр. Үземә кирәк булганда сорап кына ала идем аннары. Беркайчан әнидән: «Минем акчаларны нәрсә алырга тотасың?» – дип сораганым булмады. 50 яшемдә миңа аерым фатир бирделәр. Шунда гына үз акчама үзем хуҗа булдым. Безнең буын шулай тәрбияләнгән иде – мин моны шулай тиеш дип санадым.



БАЛАЛАР Улымны тапканда миңа 26 яшь иде. Әни булуны гел кичектердем: әле бер күргәзмәгә әзерләнәсе бар, әле икенчесенә... Рәссамнар берлегенең яшьләр секциясен җитәклим ул чакта – барысына да үзем үрнәк күрсәтергә тиешмен.

Айратка әни генә түгел, кечкенәдән үк дус та булдым. Ул эшләремнең иң беренче тәнкыйтьчесе дә иде. Мин рәсем ясый торган өстәл белән янәшә аның кечкенә өстәле торды. Сораулар биреп эштән бүлмәсен дип, аңа гел рәссамнар өчен анатомия энциклопедиясен тоттырып куя идем. Утыра да шуны актара. Үзлегеннән укырга өйрәнде! Дүрт-биш яшендә инде ул кайда балтыр сөяге, кайда нинди мускул икәнен белә иде – рәсем янына барысы да ук белән күрсәтелгән бит. Берсендә урамга уйнарга чыккач, дәресен кабатлап утыручы күрше кызының кулында «Анатомия» китабы күргән. Айрат: «Мин беләм, бу шундый сөяк», – ди икән. Аңа бу вакытта – дүрт яшь ярым!

Ул рәсемне бик яхшы ясый, әмма математика белән мавыкты. 131 нче мәктәпкә үзе барып керде, алтын медаль белән аны тәмамлады. Университетта аның дипломы «соңгы ун елдагы иң яхшы диплом» дип бәяләнде. Япония, Испания, Франция, Германия университетларыннан чакыру алды. Докторлык диссертациясен Бонннда яклады. КАИда проректор булып эшли. Мин һаман да улымның дусты булып калырга тырышам. Ул бәхетле булса, мин дә бәхетле.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ Казан сәнгать училищесына укырга кергән елны, әти белән әни миңа Ригага путевка алып бирделәр. Миңа бу вакытта 15 яшь. Беренче тапкыр читкә чыгуым. Кулымнан блокнот белән карандашны төшермим – гел туктап рәсем ясыйм. Риганың үзәк мәйданында яныма бер төркем туристлар туктады. «Сез кайдан, нинди милләттән?» – диләр. Аннан, гаҗәпләнеп: «Кем ул татарлар?» – дип сорадылар. Кайткач бу хакта әтигә сөйләдем. «Кызым, менә син хәзер рәссам буласың. Рәсемнәрең аша безне дөньяга танытырсың», – диде ул. Аның бу сүзләре мине гомер буе озатты. Мин – кырмыска, үземне китапларда да гел шулай сурәтләдем. Мондый зур бурычны – йөкне кырмыска гына күтәрә аладыр...

ЯҢА ЕЛГА ЯХШЫ КӘЕФ БЕЛӘН!

2022 ел илебез өчен дә, халкыбыз өчен дә шактый катлаулы, четерекле булды. Шулай да Яңа елны зур өметләр, яхшылыкка ышаныч, күңел күтәренкелеге белән каршы алырга кирәк. Төшенкелектән котылып, бәйрәм кәефен арттырасыгыз киләме? Балалар һәм өлкәннәр психологы, гештальт-терапевт Гүзәл ХИСМӘТУЛЛИНА күңелләргә бәйрәм рухы өрер өчен нишләргә икәнен сөйләде.

– Бик тиздән сәгать курантлары төнге уникене сугар, һәм без яңа елга – 2023 елга аяк басарбыз. Җиһанның үз кануны – дөнья мәшәкатьләренә, безнең кәефләргә карап тормый – вакыт гел алга чаба. Эштән, арып, аякларыгызны көчкә сөйрәп кайткан вакытлар еш буламы сезнең? Бәлки, хәзер, Яңа ел алдыннан мондый хәлләр гадәттәгедән ешрак күзәтеләдер? Аптырыйсы юк, хроник йончу синдромы күп кешеләрдә ел ахырына таба көчәя.

Чирләрнең халыкара классификациясендә аруны «яшәү көченең киму халәте» дип шәрехлиләр. Кешенең ел ахырына таба алҗуына аптырыйсы түгел. 12 ай буена без үзебезне беркадәр динамикада тотарга тырыштык. Ел башында һәркем үзен билгеле бер ритмга көйли. Күп вакытта ул моны үзе аңышмыйча, эмоциональ дәрәҗәдә билгели. Моннан тыш, ноябрь белән декабрьнең



энергетик яктан иң авыр ай булуын да онытмаска кирәк. Организмдагы витаминнар һәм кояш кытлыгы белән дә аңлатыла бу. Без инде яктырганчы ук аяк өстендә, тәнне җылытыр өчен дә күп энергия сарыф итeлә.

Ару һәм стресс организмда туплана бара. Шунлыктан күпләр Яңа ел җиткәндә күңел төшенкелегеннән интегә. Ләкин шуны онытмаска кирәк: һәрнәрсәнең ахыры булган кебек, бу авырлыклар да бары вакытлыча гына. Алар иртәме-соңмы бетәчәк һәм якты полоса башланачак. Алда безне озын Яңа ел яллары көтә, тиешенчә ял итеп, көч тупларга мөмкинлек булачак.

Дөресен әйтегез әле, Яңа ел алдыннан үз-үзегезгә ничә тапкыр: «Яңа ел якынлашкан кебек тә түгел» яки «Бер дә Яңа ел кәефе юк», дип кабатладыгыз? Мөгаен, бер генә дә түгелдер.

Ә мин болай дип әйтер идем: «Бәйрәм телисеңме – үзең тырыш! Кемдер килеп синең күңелеңне күтәрер дип көтмә. Күпләр өчен «әзергә хәзер» бәйрәм режимы инде бала чакта ук төгәлләнде. Хәзер, нәрсә, калган гомерне Яңа ел алды депрессиясе белән уздырыргамы? Һич юк!

Тик алдан ук кисәтеп куясым килә: бу киңәшләр тылсымлы пилюля түгел. Әлбәттә, көчле депрессиядән алар коткармас. Ә менә чын күңелдән үз кәефегезне күтәреп, якыннарыгыз өчен дә бәйрәм атмосферасы тудырырга теләсәгез, колак салыгыз әле сез аларга. Яңа елны яратмасагыз, бу бәйрәм сезне берничек тә рухландырмаса, әлеге киңәшләрне укып та тормагыз.

✦ Физик активлык: бәйрәмчә бизәлгән урамнарга, ак карга төренгән табигатькә хозурланып, бер урап кайту, бию, спорт белән шөгыльләнү, йөгерү – болар барысы да күңел төшенкелегеннән котылырга ярдәм итә. Йә, шуларның кайсысын үз тормышыгызда кулланa алыр идегез?

✦ Су кешегә җан тынычлыгын табарга ярдәм итә. Мөмкинлегегез булса, бассейнга барыгыз. Йөзү – кәефне күтәрүнең иң үтемле чарасы. Бассейнга бара алмасагыз, хуш исле күбек салып, ваннада иркәләнегез. Мунча яксагыз, үзегез белән файдалы эфир майлары да алырга онытмагыз. Лимон, мандарин, әфлисун исләре кешегә шатлык хисе өсти.

✦ Матур музыка да бәйрәм кәефен тудыра ала. Күңелне күтәрә торган дәртле җырлар куеп, гаиләгез белән бергәләп өйне, чыршыны бизәгез. Мондый шөгыль балаларга аеруча ошый, чөнки алар Яңа елны бигрәк тә түземсезләнеп көтә.

✦ Өйдәгеләрне өстәл артына бергә җыеп, кар бөртекләре кисегез. Шунда ук балачакның күңелле мизгелләре исегезгә төшәр, кәефләр дә күтәрелеп китәр. Ахырдан кемнең кар бөртеге матуррак килеп чыккан дип, конкурс оештырырга була. Иң-иң матур кар бөртекләрен тәрәзәгә ябыштырыгыз. Өйгә кайтканда алар ерактан ук сезне сәламләп, күз кысып каршы алырлар.

✦ Матур һәм уңайлы блокнот сатып алып, шунда барлык планнарыгызны һәм идеяләрегезне теркәп куегыз. Тормышка ашырылган планнарны сыза барыгыз, исемлеккә гел яңаларын өстәп торыгыз. Чынга ашкан хыяллар өчен язмышка рәхмәт әйтергә дә онытмагыз.

✦ Бергәләп рәсем ясагыз. Бу – бик мавыктыргыч шөгыль. Рәсем ясаганда кешенең нерв системасы тынычлана, мускуллар йомшый, проблемалар онытыла. Балаларыгыз белән бергәләп рәсем ясау, рәхәт мизгелләр булып, алар күңелендә озак сакланачак. Соңыннан бу рәсемнәрдән күргәзмә дә оештыра аласыз.

✦ Тәмле әйберләр пешерегез. Өйгә таралган хуш ис – теләсә кемнең кәефен күтәрергә сәләтле. Әлеге процесска балаларыгызны да җәлеп итсәгез, бу аларга икеләтә сөенеч булачак. Ә бәлки, бергәләп якындагы кафега барырсыз?

✦ Кемнедер сөендерегез. Кешене сөендерә алу – үзе бәхет бит ул. Ипи белән сөт күтәреп кассада торган әбигә кечкенә генә күчтәнәч сатып алыгыз. Ул бер тартма зефир, әфлисун яки бер шоколад кына да була ала. Кәрзиненә салыгыз да, елмаеп: «Бу сезгә! Яңа ел белән котлыйм сезне», – диегез һәм тизрәк китү җаен карагыз. Ышаныгыз, әбине сөендерүдән алган тәэсирләр әле җаныгызны озак җылытачак.

✦ Өлкән яшьтәге эти-әниләрегезгә күңелле сюрприз ясагыз – массажга яки спа-салонга сертификат бүләк итегез. Театрга яки киногa алып барыгыз. Әлбәттә, алар башта карышып маташырлар, ләкин соңыннан бу бүләккә үзләре дә шатланачак.

✦ Хәтерлисезме, элек бәйрәм саен почта тартмалары котлау открыткалары белән тула иде. Бу күркәм традицияне хәзер дә кайтарырга соң түгел. Открыткаларга ихлас теләкләрегезне язып, күршеләрегезнең почта тартмаларына салыгыз. Кемнән булды дип баш ватсыннар әле. Котлау язылган шаян плакатны лифт янына элеп куйсагыз, барысының да кәефе күтәреләчәк.

✦ Бер ял көнендә күршеләрегез белән ишегалдында кар шәһәрчеге ясагыз. Сезгә – күңелле, ә балалар өчен чын бәхет булачак. Күрегез дә торыгыз, идея никадәр катлаулырак һәм акылсызрак тоелса, йорттагы иратларны ул шуның кадәр илһамландырачак.

✦ Прокатка Кыш бабай һәм Кар кызы костюмы алып, Яңа ел алдыннан күршеләрегезне, дусларыгызны котлап чыгыгыз. Өйдә кечкенә балаларның булуы мөһим түгел, Кыш бабайны олылар да көтә бит. Әле матур шигырьләрен сөйләргә дә тартынып тормаслар. Ә сез аларга кечкенә генә сюрприз бүләкләр әзерләгез. Менә ул чып-чын бәйрәм рухы уятачак ичмасам!

Фото: гаилә архивыннан.



Нинди генә заманда яшәсәк тә, без – хатын-кызлар яшәрү, матурлык серләре эзлибез. Күзгә каршында бөтерелүләр, косметологка йөрүләр, үзеңә килешкән кремнар эзләүләр... Әмма составы сыйфатлы булган кремны табу бик авыр. «Талир Мюстела» компаниясе 30 ел инде хатын-кызлар матурлыгы сагында. Ул Европа һәм дөньяви сыйфат стандартларына туры килгән товарлар чыгарганы өчен Европа алтын реестрына кертелгән, бу исә чималның һәм чыгарылган продуктның югары дәрәҗәсен раслый. Компаниясенең хуҗабикәсе, илһамландыручысы Фирдәвес ДЕВЯТАЕВА белән сөйләшәбез.

МАТУРЛЫК СЕРЕ – ЧӘШКЕ МАЕНДА



Фирдәвес ханым, беренче тапкыр сөрткәч үк нәтиҗәсе күренә торган кремнарыгызның сере нәрсәдә?

– Чәшке маенда! Чәшке – тире авырулары белән авырмый торган бердәнбер җәнлек. Кайсы гына кремыбызны алсагыз да, аның нигезендә – балалар кремы. Ә ул үзебезнең Казан медицина университеты галимнәре тарафыннан чәшке маеннан ясалган. Балалар өчен ясалган кремга, белүегезчә, бернинди чит компонент кушарга ярамый, чөнки сабый тиресе бик сизгер була. Кремнар гипоаллерген, тире ялкынсынуын дәвалау стандартларына кертелгән. Моның өчен Россиянең җиде аллергологик үзәгеннән рөхсәт алынды. Шул исәптән, җитлегеп тумаган балалар клиникасыннан да. Табигать кочагында туып үссәм дә, битем бик коры иде. Студент чакта нинди генә кремнар кулланып карамадым. Ирем, Казан медицина университеты галиме Александр Девятаев: «Крем ясадык, сөртеп кара әле», – дип, кечкенә савытка салып бер крем алып кайтты. Аны сөртүгә үк тирем йомшарып китте. Искиткеч бер тәэсир калдырды ул миндә. Инде 30 ел үтте, ә минем башка кремны кулланып та караганым юк. Безнең компаниянең чишмә башы әнә шул кремнардан башлана. Кешенең тиресе катлам-катлам бит ул. Тиренең өске өлешенә генә тәэсир иткән крем үз нәтиҗәсен бирми. Ул «иң аскы кат»ка ук барып җитәргә тиеш. Ә чәшке мае нәкъ менә шул үзлеккә ия. Гади итеп кенә аңлатсак, ул файдалы матдәләрне тире астына алып керүче «үткәргеч» ролен үти. Шуңа кремнар тиз арада сеңеп бетә, биттә майлы булып калмый, хәтта Т-зона да. Битнең майлы өлешен майсызландыру, коры урынын дымландыру үзлегенә дә ия алар. «Сезнең кремнарны сөрткәч, битем сулый башлады», – дип әйтүчеләр бар. Бик дөрес сүз бу! Бит тиресе күзәнәкләрдән тора, ә алар чынлап та суларга тиеш. Битне безнең «Талир» кара тмин йә чәшке маеннан ясалган сабын, молочко белән чистартып, крем сөртсәгез, ул шундук сеңеп бетәчәк һәм картаюдан, тискәре тышкы факторлардан саклаячак.

Белүемчә, сезнең кремнар сәламәтлек чыганагы да...

– Хәзер бик күпләр тире коры булудан җәфалана. Ә ул, үз чиратында, төрле авырулар китереп чыгарырга да мөмкин. Моннан кала, коры тире тиз картаючан була. Безнең кремнарны сөртеп, битне дымландырып, сез инде тире проблемалары белән очрашмаска мөмкин. Әйе, дәва эффекты бирә торган кремнарыбыз да бар. Мәсәлән, нигезендә шулай ук чәшке мае, әрем, кара тмин, фукус булган кремнарыбыз тән пешкәндә дә ярдәм итә. Алар төрле ялкынсынуларга каршы тора, тирене яңарта, тиредәге ярсу, кычытуларны кимет. Гөлҗимеш маеннан ясалган кремыбыз кышкы салкын көннәрдә аеруча файдалы. Составында чәшке мае, көчле антиоксидантлар: А, С, Е витаминнары бар. Төрле яшьтәге хатын-кызлар куллана ала. Салкынга аллергиясе булган, кышкы-көзге чорда бите корып интеккән хатын-кызлар арасында популяр ул. Тирене ялкынсынудан, кабырчыкланудан саклый, вак яраларны тиз төзәтә. Кремны салкынга чыгар алдыннан 20–30 минут кала сөртергә кирәк. Суыкка аллергиясе булганнарга урам-

нан йөреп кергәч тә сөртергә киңәш ителә. Җылыту сезоны вакытында фатирларда, офисларда һава коры. Бу вакытта тән тиресенә, шул исәптән, биткә дә, аеруча игътибарлы булу мөһим. Чәшке маеннан ясалган дымландыргыч крем ярдәмгә килер – ул битне кибүдән саклый. Бигрәк тә бассейннан соң безнең сабыннар белән юыну, кремнарыбызны сөртү файдалы. Буыннар өчен файдалы крем хакында да әйтеп узасым килә. Аның составында камфора һәм пихта мае бар. Буыннар авыртканда сөртеп куйсагыз, тынычлап йокларсыз. Бу кремны ютәл булганда күкрәк читлегенә сөртеп куйсагыз, сулыш юлларыгыз шундук йомшап китәр. Сөлектән ясалган кремыбыз исә варикоздан файдалы.

«Талир Мюстела»ның йөзек кашы булган «Firdaus» алтын сериясе аерым игътибарга ия. Ул сезнең исемне йөртә, нәкъ менә сез әлеге продукциянең йөзе булып торасыз.

– Бу серия косметологиядәге 35 еллык тәҗрибәм нәтиҗәсе дип әйтсәм дә була. «Firdaus»та һәр продукт уникаль рецепт белән эшләнгән. Үз исемемне дә йөрткәч, билгеле, җаваплылык та зур. Без ясаган кремны кулланып, хатын-кызларның канәгать калуларына, аларның чибәрлеген саклауда үз өлешебезне кертүебезгә куанабыз. Бу сериядә көндезге, төнге, күз тирәсе өчен, кул өчен кремнарыбыз бар. Аларны даими сөрткәндә, тиренең тонусы күтәрелә, ул – алыштыргысыз лифтинг та. Бу кремнарны яшь туташларыбыз да, ханымнарыбыз да рәхәтләнеп куллана. Шулай ук алтын битлек «Firdaus» турында да аерым әйтәсем килә. Ул – бит тиресе өчен беренче ярдәм, яшьлек битлеге. Без аны бит тиресе бик сизгер булган кешеләргә дә киңәш итәбез. Битлек составында уникаль компонент – Марокködан кайтартылган вулкан балчыгы. Ә ул минералларга үтә дә бай. Безнең битлек хәзерге популяр битлекләр кебек, бит тиресен катырмый, тарттырмый да. Бу битлектән соң крем тидерү дә мәҗбүри түгел. Әлеге сериядәге тагын бер табышыбыз – «Firdaus» алтын мае. Ул хатын-кызлар өчен чын-чынлап хәзинә! Арган, кокос, чәшке маеннан ясалган 100 процент натураль составлы ул. Табигый майлар булгач, тиз сеңеп бетә, элпә эффекты да тудырмый, иң мөһиме – бит ялтырап тормый. Бер тамчы майның нинди могҗизага тиң икәнен кулланып карауга ук сизәрсез. Аны бераз гына кулга, муен, күкрәк тирәсенә дә сөртсәгез, үзегезне патшабикәләрдән ким хис итмәссез – тәнегез бәрхеткә әйләнер. Шулай ук Dr.9 профессиональ кремнарыбыз да бар. Ул табиб-косметологлар белән бергә эшләнгән. Бик сизгер бит тиресенә идеаль туры килә. Бу кремнарны без «антипроблема» дип атап йөртәбез. Ул бит тиресендәге җирле «иммунитетны» күтәрә, регенерацияне тизләтә, төрле ялкынсынуларны бетерә, җыерчыкларны киметә, блефаропластиканы алыштыра ала. Картаю билгеләрен бетерә. Өске күз кабакларына лифтинг эффекты бирә, күз тирәсендәге каралып торган урыннарны, вак җыерчыкларны киметә.

Сезнең әле чәч өчен кремнарыгыз да бар. Бәлзәм-кондиционер ише продуктларга ияләшеп беттек инде. Ә менә чәч кремы турында шәхсән үземнең ишеткәнем юк иде.

– Коронавирус белән авырганнан соң бик нык чәчем коела башлады. Бу проблема бер миндә генә булмады бугай. Миңа менә шушы кремыбыз ярдәм итте. Шифасы составыннан ук күренә. Кара тминнан, чәшке маеннан ясалган ул. Чәшке мае могҗизасы турында сөйләдем инде, ә кара тмин мөселманнар дөньясында бик тә популяр. Бу кремда йөздән артык актив матдә бар. Башны юар алдыннан ярты сәгать кала, кремны чәч тамырларына сөртәбез. Ул баш тиресен корудан саклый. Шулай ук чәч тамырларын ныгыта, структурасын яхшырта. Чәчләрегезне безнең «Талир» шампуне белән юып та алсагыз, нәтиҗәсе тагын да яхшырак булыр. Шампуньнар, сабыннар гипоаллерген безнең. Димәк, балаларны да юындырырга ярый.

Фирдәвес ханым, сезнең продукцияләрне кайдан сатып алырга мөмкин?

– Бүген компания кәрзинендә 60 төрле продукция исәпләнә. Арадан нәкъ менә үзеңә кирәген сайлап алырга кирәк. Казанда Карбышев урамы, 7 адресы буенча «Матурлык йорты»быз урнашкан. Анда сезгә консультант, дерматологлар киңәш бирер. Шулай ук башкалада туристлар зонасынданы сувенирлар кибетендә дә продукцияләребез тәкъдим ителгән. Хәзер интернет заманы. Кремнарны www.talir-mustella.ru интернет-кибетеннән дә, «Ozon», «Wildberries» маркетплейсларыннан да сатып алып була. Клиентларыбызга үзем дә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер. Кесә телефоным: 8 (987) 27-99-555. Минем һәр җирдә әйтә торган сүзләрем бар: «Кичтән биткә крем сөртү бер рәхәтлек булса, иртән уянгач, аның нәтиҗәсен күрү – зур бәхет». Менә шуны истән чыгармагыз, гүзәл затларыбыз. Көзгә каршында һәрвакыт кремнарыгыз торсын. Кичен бик йокыгыз килсә дә, крем сөртергә вакыт табыгыз. Минем мәрхүм әбием: «Матурлыкны Мәккәдән эзләмәгез», – ди торган иде. Матурлык ул безнең кремнарыбызда, чәшке һәм «Firdaus» майларыбызда.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



PRESSA



БУРЯТИЯ. ФОТОРЕПОРТАЖ



Алсу
ШАКИРОВА



Анна
АРАХАМИЯ

Ерак Себер якларында Байкал күлен кочып, иксез-чиксез далада җәелеп ятучы Бурятия Республикасына юл тотуыбызның максаты – монда гомер итүче милләттәшләребез белән танышу иде. Өч көндә бер мең чакрым юл узсак та, өстән-өстән генә йөреп чыгу түгел, язмыштан – язмышка, хатирәдән хатирәгә йөрү булды ул. Кызганыч... Бу язмага шул язмышларның берничәсе генә сыйды.

Ай, былбылым, вай, былбылым,
Кунып сайрый талларга;
Синең хакта серләремне
Сөйлим сандугачларга...


Юл буе колакта шушы көй яңгырады...

















БАЙ КҮЛ БЕЛӘН КУШЫЛГАН БЕЗ...

Алсу ШАКИРОВА

Идел буе татарларының хәзерге Бурятия Республикасына (элеккеге Верхнеудинск шәһәре) беренче тапкыр килеп төпләнүе XIX гасыр уртасына туры килә. Төп өлешен сәүдәгәрләр һәм сөргенгә җибәрелүчеләр тәшкил итә. Күбесе Байкал арты икътисадый тормышында үз урыннарын табалар, аның үсешенә зур өлеш кертәләр. Шул ук вакытта мәдәниятләрен, диннәрен саклап калалар. Шәһәрдә мәчет, хәтта мөселман зираты да булган. Татарларның күпләп күченү чоры 1930–1950 еллар белән исәпләнә. Ул елларда Бурятиягә күчеп килүчеләрнең 60–70 процентын татарлар тәшкил иткән. СССР Министрлар Советы рәисе Георгий Маленковтан нәкъ менә тырыш, эшчән татарларны бу якка күчерү буенча планның тулуын таләп иткән Бурят-Монгол АССР җитәкчелеге.

«Хәзер инде анда – Татарстанда туганнар калмады», – ди алар. Алай булырга тиеш түгел! Юллары гына аерылгандыр... Бу язманы укып чыкканнан соң, бәлки, узган гасыр урталарында Себер җирләрен үзләштерү программасы белән Бурятия Республикасына китеп, эзләре югалган туганнарыгызны да табарсыз. Татарлар яшәгән кайсы авылга барып керсәң дә, Кукмара, Саба, Балтач, Теләче, Мамадыш районы авылларын телгә алалар монда. Кырыс Себер шартларында, чит мохиттә дә югалып калмыйча, туган туфракларын алыштырган яңа җирлектә тирән эз калдырып, якты йолдыз булып балкыган алар. Татарлар! Һәр гаиләнең үз тарихы...

Аерылабыз күпкәме?

– Иртән сезне кулга алырга киләчәкләр...

Буа районы Янтуган авылында яшәп ятучы Мөхетдин Хисаметдинов йортына 1930 елда килеп ирешкән бу хәбәр көтелмәгәндә була. «2 нче категорияле кулак» исемлегенә кергәнлеген белмәгән Мөхетдин бабай. «Мин үз йортымнан аяк та атламыйм!» – дип каршы торган Мәүҗидә әби иртәгесен үзенең кайларга китәсен сизсәме...

Мөхетдин бабай яшь вакытта Әстерхан якларына китеп, нефть чыгаруда эшләгән – биш алтын тәңкә алып кайткан. Шул акчага үзенә йорт, авылга мәчет төзеткән. Кибет ачканнар, хуҗалыкларын зурайтып җибәргәннәр. Өч атлары, өч сыерлары, үз умарталыклары булган. Бакчадагы уңышны җыяр өчен эшчеләр яллап, аларга хезмәт хакын шул уңыш белән түләгәннәр. Мөхетдин бабай Әстерханда помидорлар үстерергә өйрәнгән, төрле тәмләткечләр, орлыклар алып кайткан. Ул утыртканны, тишелеп чыгуга, Мәүҗидә әби артыннан йолкып бара торган булган. Дөньяда булмаганны... Әллә ниләр үстереп яту мөселман кешесенә килешә торган эшмени?!

...Иртән боларның барысы да юкка чыга. Үзләре белән бер йортта яшәгән уллары Шиһапны, киленнәре Халисәне, әле өч ае гына тулган оныклары Расихны булса да саклап калу өчен аларның фамилиясен Батталовка үзгәртергә хәл итәләр. Авылда кешедән яшереп буламыни? Бөтенесен бергә Себергә, Байкал арты җирләренә сөрәләр...

Кая юл тотканын, бу рәхимсез юлның кайсы ноктада тукталасын да белмичә, оза-а-ак бара эшелон... Майда аларны баржага төяп, Ангара елгасы аша чыгаралар. Шул вакыт гаиләгә тагын бер кайгы килә. Бәләкәй Расих бик нык чирләп китә. Никадәр халыкның авыр шартлардан, ачлыктан, салкыннан күз алдында кырылганын күргән Мөхетдин бабай оныгын мөселманча озатырга дип «Ясин» сүрәсен укырга тотына. Яшәү белән үлем арасында өзгәләнгән сабый дога көче белән күзләрен ача, авыруны җиңә. Расихның озын гомер кичерәсе, оныкларын, оныкчыкларын сөясе алда була әле. Шул вакыйгадан соң Батталовларда яңа традиция барлыкка килә. Нәрсә булса да, иң элек «Ясин» укый алар. Әле дә шулай...

«Махсус поселениеләргә ул елларны барлыгы 381 мең гаилә озатыла. 40 нчы елларга кадәр тагын 490 мең кулак гаиләләре килеп кушыла. Газаплы юлда 90 мең кеше вафат була, 300 меңе, барып җиткәч, ачлыктан, төрле авырулардан үлә...» – дип яза соңыннан шушы нәсел кызы Саҗидә Батталова.

Ай, былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата;
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да елата...

Җәһәннәмнең бер чигедер

Гаиләне ерак тайгага, Чита өлкәсе, Могочинский районындагы Итака поселениесенә кадәр сөрәләр. «Ходай Сочины булдырган, шайтан – Могочины» дигән әйтемнең нәрсә икәнен анда яшәүчеләр генә аңлыйдыр, мөгаен... Җелегеңне суырырлык кырыс, авыр шартларда Хисаметдинов-Батталовлар гаиләсе тормышка тешләре белән ябыша. Исән калырга! Бирешмәскә, шушы җиргә таш булып ятарга, эрбет чикләвеге агачы кебек нык булырга, тау суларыдай юл ярып, алга барырга...

Татар станы, Рус станы... Көзгә җирдә землянка казып, шунда яши башлыйлар. Мөхетдин бабай алтын приискаларында эшли, мулла вазыйфасын да башкара. Җәһәннәмнең бер чиге булып тоелса да, Бөек Ватан сугышы башлану хәбәре бу якларга да бик тиз килеп җитә. Уллары Шиһап сугышка алына. Хатыны Халисә апа итәгендә дүрт кечкенә бала белән кала. Әллә ничә чакрым еракльгкта урнашкан мәктәпкә кыш көне дүртесенә бер итекне чиратлап киеп йөри балалар.

Тайга коткара аларны, тайга ашата. Үлән сихәтен, табигать көчен өйрәнергә ярдәм итә бу урманнар. Гөлҗимеш, мүк җиләге, кара җиләк, гөмбә, эрбет агачының сагызын җыялар да станциягә алып барып саталар. Һәр бөртеге исәптә! Халисә апаның җиләк җыйганда берне дә авызына капмый торган гадәте гомерлеккә кала...

Күпләрне сындырса да, Себер Мөхетдин бабай гаиләсен ныгыта гына, тормыш сабагының иң катлаулысын бирә. Тагын аякка басалар. Пенсия түләнмәсә дә, бер гектар җиргә бәрәңге утыртып, шуны сатып тормыш итәләр. Киленнәре Халисә сыер, сарыклар ала. Хәтта Янтугандагы туганнарына посылкалар җибәреп, аларны да ачлыктан саклап кала. Шиһап абый, яраланып, «За отвагу» медале белән әйләнеп кайта. «Дан ордены»на да тәкъдим итәләр аны. Кулак малаена, әлбәттә, ул орден бирелмәгән...

Сугыштан соң, ниһаять, гаиләгә Итаки поселениесеннән китәргә рөхсәт бирәләр. Яңадан Татарстанга? Юк, Мөхетдин бабайның күңеле таш булып ката, күрәсең. Бер киткәннән соң туган авылына бер тапкыр да әйләнеп кайтмый инде ул. Бу якларны үз иткәнме, авылдашларына рәнҗеп киткәнме, яңа буынны рәхимсезлектән саклап калырга тырышканмы... Сәбәбен берәү дә белә алмый. 1953 елда хатыны, улы Шиһап, килене Халисә, оныклары белән Бурятия Республикасының Улан-Удэ шәһәренә килеп төпләнәләр.

Әби-бабалары кичергән авырлыклар турында Батталовларның яңа буыны Халисә әбиләре исән чакта ук белгән булса, никадәр үзәк өзгеч хатирәләрне саклап калып



Расих, Рәстәм, Фәридә, Әмир Батталовлар.

булыр иде. Кызганыч, әбиләре дә, бабалары да – берсе дә бу хакта сөйләмәгән. Беркайчан да! Шулкадәр сер итеп сакларга кирәк бит... Сер капчыгы ялгыш кына сүтелеп китмәсә, шул килеш дала комнарына күмелеп, тайга җилләрендә таралып, эзсез югалыр иде ул тарих... Хәзер инде алар аны түкми-чәчми үз балаларына сөйлиләр.

– Бу якларга күчеп килүчеләрнең кайсын алсаң да, китап язарлык хатирәләргә юлыгасың. Әниебез ягыннан әбиебез Гәүһәрҗамал чын татар тәрбиясе алып үскән. Аерылышкан бер хәлле кешегә кияүгә биргәннәр аны. Сугыш алдыннан, урман хуҗалыгында эшләр өчен, 1939 елда Татарстаннан Бурятиягә күчеп килгәннәр. Тамыр җибәрергә дә өлгермиләр, сугыш башлана. Ире сугыштан исән кайтса да, гангренасы ачылып, озак та тормый үлә. Әнигә ул чакта – 4, абыйсы Галигә 10 яшь була. Мөселманча җирләрлек ир кеше булмагач, бу җаваплы эшнең рәтен улына өйрәтүдән башка чарасы калмый әбинең. Күлмәкне тарттырып тегеп кәфенлек ясый да, юып, әтисен соңгы юлга 10 яшьлек улы озата... Әби соңыннан бу вакыйганы искә алып гел елый иде... – дип сөйли Расих абыйның кызлары Нәсимә апа белән Рәйсә апа.

Батталовлар нәселе тарихы Бурятиядә дәвам итә. Ничек кенә әле! Рәстәм һәм Фәим Батталовлар Бурятиянең атказанган машина йөртүчеләре исеменә лаек була. Бүген Сажидә Батталова Бурятия халыклары ассоциациясе рәисе вазыйфасын башкара.

Татар кызы Нәкыя

Күчеп килгән татар балаларына белем бирер өчен 1941 елда Спас педагогика училищесын тәмамлаган бер төркем укытучыларны комсомол юлламасы белән Бурятиягә җибәрәләр. Алар арасында Нәкыя дә була. Балаларга белем бирү теләгеннән кала, тормыш һәм педагогик тәҗрибәләре булмый да әле бу 18 яшьлек кызларның. Апрель аенда Селенгин районына барып җитәләр, ә берничә айдан сугыш башлана. Өч кыздан кала, монда килгән 17 укытучы егетне сугышка алып китәләр.

Кызлар укытучы гына түгел, остаз да була җирле халыкка. Бу якларда Нәкыянең бурят халкын чисталыкка өйрәткәнен, татар мунчасы белән таныштыруларын әле дә искә алып сөйлиләр. Укыталар да, утын да әзерлиләр, кырда да эшлиләр укытучы татар кызлары. Җәй көне каникул вакытында ат белән заводка сөт ташыйлар. Ризык өчен эшлиләр шулай. Сугышка алыгыз дип бик сораса да, син монда бик кирәк, дип, Нәкыяне кире боралар.

Кыю татар кызы барыбер фронтка эләгә – 1945 елның августында товар поездына утырып япон сугышына качып китә. Очкычларга хезмәт күрсәтә, бомбалар төйи. Орден-медальләрен, документларын Новосибирск вокзалында урласалар да, туган якларына кайтып җитә.

Татарлар күчеп килгән районнарга мәктәптә татар телен укыту өчен ТАССРдан укытучылар җибәрү тәҗрибәсен, ни кызганыч, 60 нчы елларда туктаталар... Сугыш елларында мәктәптә белем биргән сөйкемле, кыю татар кызы Нәкыяне бу якларда әле дә хәтерлиләр. Мәктәп музеенда аңа багышланган стенд бар, аның турында коллегаларының истәлекләре белән китап чыгарганнар...

Без бүген Нәкыя апаны Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровның әнисе дип беләбез.

Өзелеп-өзелеп елар идем...

Бурятия Республикасының татарлар иң күп яши торган Усть-Кяхта авылы Монголия чигендә урнашкан. 1730 елда нигез салынган авылга 1940 елда беренче татар гаиләләре килеп төпләнә. Күбесе Мамадыш районыннан: Рәхмәтуллиннар, Гайфетдиновлар, Фәрхетдиновлар. 1952 елда тагын унбиш гаилә килеп кушыла: Әүхәдиевләр, Шакировлар, Хәлимовлар, Дәүләтшиннар, Гатауллиннар, Салиховлар... Яңа авылдашларын каршы алырга станциягә колхоз председателенең 8 яшьлек кызы, хәзер Кяхта районы депутаты Наталья Яковлевна да бара. Татар гаиләләре белән беренче тапкыр очрашуын бүгенгедәй хәтерли ул.

– Хатын-кызларның барысының да яулыклары артка бәйләнгән, ә аякларында ялтырап торган кара галошлар. «Әти, кара алар нинди туфли кигәннәр!» – дип, әтигә төртәм. «Тик кенә тор!» – ди миңа әти. Андый аяк киемен үз гомеремдә беренче күрүем иде. Авылда аларның барысын бергә элек сәүдәгәр яшәгән йортка керттеләр. Авыр тормыштан, хәерчелектән качып килдек, дип сөйләсәләр дә, сизелмәде ул. Татарларның нинди тырыш милләт булуын беренче көннән үк күрдек. Беләсезме, беренче чиратта нишләде алар? Авылга таба елга казыдылар. Аннары үзләре белән алып килгән алмагач үсентеләрен утырттылар. Һәр алмагач төбенә елгадан су юлы килә! Усть-Кяхта авылында 1000 алмагачтан торган бакча үсеп чыкты!

Күчеп килгән һәр гаилә үзенә йорт җиткереп кирә. Колхоздан аларга сыер, тәкә бирәләр. Алмагачлар янына чия агачлары, кура җиләге куаклары да утыртыла, умарталык булдыралар. Борчакны бу якларда күргәннәре дә булмый. Анысын да татарлар алып килә!

Шул елларда күченеп килүчеләр арасында ике кызы белән Әүхәдиева Бибигарифә апа да була. Олы кызы



«Рәхәттән чыгып китмәгәннәр инде. Ачлыктан, начар тормыштан качып килдек, дип сөйли иде әни. Ипине монда килгәч кенә туйганчы ашаганнар...» Бибигарифә апа кызлары Һәдия һәм Халисә белән. 1952 ел.

Һәдиягә ул чакта – 19 яшь. «Ул вакытта бу авылда татарлар бик күп иде», – дип сөйләгәне истә әнинең. Әтиебез Зөфәр гаиләсе алданрак килеп урнашкан. Әниләр эшелоны килгәч, әти: «Матур татар кызлары килгән авылга!» – дип куанган. Кавышып, гаилә корганнар. Бергә 60 ел яшәделәр», – дип таныштыралар үз нәсел тарихы белән бертуган Сания һәм Әлфия апалар. Алар – сагынып яшәүчеләр. Әниләре Һәдия апага Ринат Рәхмәтуллин башкаруындагы «Кайтсам әгәр туган авылыма, / Өзелеп-өзелеп елар идем» җырын тыңлатканнар. Җырны тыңлап, әниләренең өзелеп-өзелеп елаганын кызлары соңгы сулышларына кадәр онытмаслар, мөгаен... Туган якларына кайтып, әниләре яшәгән авыл урамнары буйлап йөрергә, мәктәбенә кереп, әниләре утырган партаны күрергә хыялланып яшиләр... Сагыну сагышы буыннан-буынга күчә, кан белән бирелә, күрәсең...

Алмагачлар еллар узгач корып бетә. Бүген Усть-Кяхта алма бакчасын бөтен авыл белән яңадан утыртканнар. «Безнең татарларыбыз истәлегенә!» – диләр күпмилләтле авылда...



■ Алдан ышандырган муллыкның күбесе булмый монда. Аның караві, килеп төшүгә ике капчык он бирәләр. Анна Тимофеева кызы Анастасия, кияве Таһир, оныклары белән. 1961 ел.

«Зерә» яхшы кешеләр

Берәүләр сагынып яшәсә, икенчеләре яңа җирлекне туган җире дип кабул иткән. Дан казанып, хөрмәткә лаек булып гомер кичергәннәр.

– Миңа дүрт ай булганда, әтием Солтан, әнием Маһинур дүрт балалары белән Саба районы Мишәбаш авылыннан бирегә килеп төпләнгәннәр. Әти алданрак килеп, йорт салып куйган. Аннары гына безне алырга кайткан. Бурятлар белән бик яхшы яшәп киткәннәр. Без күченеп килгәч, берничә айдан сугыш башланды, әти китте... Бурятларны «зерә яхшы халык», дип әйтәләр иде әти белән әни. Мин, бурятка кияүгә чыгам, дигәч тә каршы килмәделәр. Әниләрнең туган җирләрен сагынганын хәтерләмим... Әти берара авырып китте дә, туган як суы ярдәм итәчәк дигәч, туган авылларына кайткан идек. Ул кайтуында да Бурятияне сагынып яшәде әти. «Монда агач та юк, нигә кайттык», – дип, вәсвәсәләнеп йөрде. Әти савыккач, бер елдан яңадан Бурятиягә киттек... Әби-бабалары исән чакта балалар татарча гына сөйләшеп үстеләр. Әкренләп тел онытыла инде, сөйләшер кеше калмый... Татарстанда туганнар барын-югын белмибез, – дип сөйләде Тэгда авылында яшәүче Флера апа Хәбибуллина.

Флера апаның әтисе – Ленинградны блокададан азат итүдә катнашкан Солтан Хәбибуллин Синявино авылы тирәсендә күрсәткән батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз орденына лаек була.

Бурятиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Журналистлар берлегенең «Мактау билгесе» кавалеры Александр Фәрфетдинов та үзенең татар тамырларын күптән барлап куйган.

– 1952 елның мартында Кукмара станциясендә: «Э-эх, илдән китәбез, туган җирне ташлыйбыз!» – дип, моңлы гармун тавышына кушылып җырлаучылар, туганнарыннан аерылу сагышыннан күз яшьләрен сөртүчеләр, озаккамы, юкмы икәнен белмичә кочаклашып елаучылар арасында минем әби Анна Тимофеева да булган. Өч кызын ияртеп, яхшы тормыш эзләп китеп баруы булган аның. Тумышы белән Мамадыш районы Җөри авылы керәшене иде әби. Ире Семённы 42 яшендә сугышка алып китәләр. Суслонгер лагеренда укулар вакытында бозлы судан бүрәнәләр чыгаруда эшләгәннәр. Ике як үпкәсе ялкынсынып, бабайны өенә кайтарып җибәргәннәр. Үләргә... Үпкәсе боз булган, дип сөйли иде әби. Бабай бик газапланып дөнья куйган. Өйдә үлгәч, хатынына да, балаларына да фронтовик хатыннарына бирелә торган ташламалар эләкмәгән. Сугыш вакытында да, сугыштан соң да салымнардан азат итмәгәннәр аларны, сыерларын да, кәҗәләрен дә алып киткәннәр. Шул авыр тормыштан җиңеллек эзләп китүе булган әбинең...

Вербовщиклар да бик оста сөйләп, кызыктырып йөргәннәр, матур сурәтләр күрсәтеп, мул тормыш ышандырганнар. Кызыкмаслык булмаган инде ул серле Бурят-Монголия. Иң мөһиме – күчеп килүчеләрне салымнан да азат итәселәре икән!

Туган җирләрдән китүе авыр булган Анна апага. «Кал, җайлашыр әле», – дип тә караган туганнары. Юк инде, әйберләр җыелган, күз яшьләре түгелгән, артка юл юк... Большой Луг авылына килеп урнашалар. Бурятлар бик тыныч, тату халык булып чыга. Телләре дә охшаш икән. Бурятчага өйрәнү уңайсызлыклар тудырмый, җайлы гына сөйләшеп китәләр.

– Әтиебез Таһир белән әнием шушы авылда танышалар. Әтинең гаиләсе гражданнар сугышы елларында Совет власте төзү өчен килгән булган. Әбиебез Анна 94 яшендә, кичтән үзе мунча кереп, чиста килеш китеп барды... Без бу җир белән кушылган инде, аның язмышы – безнең дә язмыш. Ватаныбыз – Бурятиябез каршында хөрмәт белән баш иябез, – ди Александр Фәрфетдинов.

Казан–Улан-Удэ–Казан

Фотолар: гаилә архивыннан һәм «Татары на Байкале» китабыннан.
26 нчы биттә: Мөхетдин Хисаметдинов гаиләсе.

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.»





Ә АВЫЛДА ХӘЗЕР КАЗ ӨМӘСЕ...

Менә быел да ак кышларга аяк бастык. Кыш – сугым чоры, муллык чоры. Беренче кар төшү белән үк быел да авылларда каз өмәләре башланып киткәндер... Бездә өмәләр күп, ләкин каз өмәсе ул үзенә башка! Татар халкы гомер-гомергә күпләп каз үстергән. «Ун каз бер сыерга тора» дигән әйтем дә юктан гына чыкмагандыр. Авыррак тормышлы хуҗалыклар бер оя каз асраса, хәллерәкләрендә ике, хәтта өчәр оя каз булган. Билгеле инде, мондый ишле казларны бер көндә эшкәртеп өлгерү өчен эшче куллар да күп кирәк. Өмәләрне шуның өчен уздырган да инде халкым. Күрше-күлән, туган-тумача, яшь киленнәр, кызлар, кул астына керердәй бала-чага – өмәдән беркем дә читтә калмаган.



Лилия ГӘРӘЕВА

«Мине каз өмәсеннән калдырмассың», – дип, җиткән кызлар инде җәйдән үк хуҗаларга сүз каткан. Өмәдә катнашу – уңганлык билгесе дә, яшь кызлар өчен мәртәбә дә. Монда үзеңне күрсәтәсең, авыл яңалыкларын белешәсең. Өйләндерер улы булган апалар исә сиздерми генә сине күзли... булдырамы, янәсе, килен итеп алырлыкмы?

Кызлар булган җирдән егетләр каламы?! Гармуннарын култык астына кыстырып, җылы мунчага алары да елышкан. Бергә булгач, каз йолку эше үзе үк бәйрәмгә әверелгән.

Гадәттә, өмәне иртүк башлап җибәргәннәр. Иң беренче килгән кызны өмә башы итеп куйганнар. Кайдадыр өмә башы итеп тәҗрибәле килен билгеләнгән. Ул һәркемгә эш бүлеп биреп, суын, савытын барлаган, мамык тутырыр өчен мендәр сүрүләрен әзерләгән. Кайбер якларда каз өмәсенә әти-әнисе исән булган кызларны гына чакырганнар. Шулай итмәсәң, казлар киләсе елга күп бәбкә чыгармый дип ышанганнар.

Казларның мамыгын йолкып, эчен алгач, өмәнең икенче өлеше башланган. Матур шәлъяулыкларын ябынып, кешелеккә дигән бишмәтләрен кигән кызлар көянтә башларына пар каз элеп, чишмәгә каз юарга төшкәннәр. Кызларга үзен танытмаслык итеп киенгән берәр егет тә ияргән. Анысы, кызларны көлдереп, очраган берсен куркытып күңел ачкан.

Иңнәренә көянтәләрен элгән кызлар тезелешеп чишмәдән кайтышка авыл өстенә тәмле коймак исе таралган. Өмәчеләрне каз маенда кызган коймак белән чәй табыны көткән. Каз чәе белән өмәнең бу өлеше тәгәлләнгән. Казларны саркытырга элеп, кызлар-егетләр өйләренә таралышкан.

Кичен казның баш-аягыннан зур бәлеш пешереп, хуҗалар аларны кабат кунакка чакырган. Кайбер якларда кызларны көндез үк бәлеш белән сыйлап, кичен аларны җылы мунчага каз каурые сдырырга дәшкәннәр. Менә шунда уяулык соралган да инде.

Аны-моны уйламый гына урындыкка утырырга ярамый – адәм көлкесенә калуың бар. Шаяннар каз куыгын кабартып, көрпә астына яшерергә дә күп сорамаган. Утыруың була – ша-а-арт! Шартлый куык. Аннары аңлат көлә-көлә идәндә тәгәрәшкәннәргә гаепнең үзеңдә түгеллеген!

Хәзер бераз башкачарак узса да, авылларда каз өмәләре әле бүген дә гөрли. Мондый зур эш күрше-күлән ярдәм итми генә буламы соң?

– Үземне белә-белгәннән каз-үрдәк йолыкмый калган еллар булмады, – дип сөйли авылдашым, Арча районы Кышкар авылы мәдәният йорты мөдире Ләйсән Шәфигулина, үзе үскәндәге каз өмәләрен искә алып. – Без бала вакытта авылда каз асрамаган кеше булды микән? Күршебез Фәльия апаларның казлары бигрәк күп була торган иде. Кайнанасы Газизә апа казлар үстерергә бик маһир. Аларның казлары да үзләренә башка бертөрле, караңгы соры төстә, йомрылар, матурлар... Казларын сораучылар күп булгандыр, терелә́й дә сатканнарын беләм. Безнең әни дә алардан каз сатып алды. Теләсә кемгә, белмәгән кешегә каз сатмыйлар. Каз белән бергә кул арты китүдән бик курка халык. Фәльия апа да казны капчыкка салганда: «Ай, кара әле, нәрсә ул анда?» – дип, игътибарыңны читкә юнәлтә дә, сиздерми генә казның башыннан берәр каурыен йолкып ала торган иде.

Без бала чакта да каз өмәләре бик күңелле узды. Әнием Илсөя, күршедәге Наҗия, Мәрвәр, Нәфига апалар, чираттан өмә уздырып, каз йолкыйлар. Аларга без – бала-чага да иярәбез. Каз йолку, эчен-башын алып урнаштыру, ахырдан табак-савытларын юып, мунчаларны җыештырып чыгару шактый авыр хезмәт.

Һәр эшнең үз остасы була. Каз өмәсендә дә шулай. Наҗия апа казны бик җитез йолка. Кешеләр берне бетергәндә, ул инде икене йолкып өлгерә. Элек казларны хәзерге шикелле пешекләп тә, үтүкләп тә йолкымыйлар иде, бармак башлары ике каздан артыкка чыдамый. Шуңа да каз йолкучылар күп кирәк. Әниләр каз йолкый, ә безгә: «Шыпырт кына менә шуны эшләгез», – дип, баш-аяк чистартырга бирәләр. Хәзер инде баш йоннарын алучы кеше дә юктыр, элек шунысыннан да кечкенә генә диван мендәрләре ясый торганнар иде. «Баш йоны мендәре» дип йөртteләр аны.

Казларны йолкып бетергәч, эчен алырга кирәк. Монда инде Мәрвәр апага җиткән кеше юк. «Кагылмагыз, үзем алам!» – дип кенә тора. Ул да бик белеп кенә эшләнә торган эш. Безнең әни казның маен алырга оста. Эчен кечкенә генә итеп ярып, бик оста итеп ала. Пешекләгәч, кискән урыны, бөрешеп, тагын да кечерәя... «Күргәзмәгә куярлык булган», – дип, үз эшләренә үзләре сокланып, берберсен макташалар тагын.

Шул көннеме, икенче көннеме каз ашы үткәрәләр иде. Казның баш-аягыннан зур бәлеш салалар, каз шулпасы пешерәләр. Ашап, догалар кылгач, менә башлана иде уенкөлке. Апалар бер-берсенә тастымаллар атышалар. Казлар киләсе елга да күп булып чыксын өчен булган икән бу йола.

Бер елны шулай казларны йолкып бетереп, өс-башларны кагынгач, и тотындылар көлешергә. Ләүкә астында әле кагылмаган да бер каз качып калган икән. Кайчагында, кызык ясар өчен, өмәчеләрдән бер шаяны аны махсус да яшереп калдырган.

Ләйсән апаның каз өмәсе белән бәйле кызыклы истәлекләре байтак. Мәсәлән, элегрәк бала-чаганы, хәйләләп: «Бар әле, фәлән абыйлардан мамык машинкасын алып кайт», – дип чыгарып җибәрә торган булганнар.

– Бала-чага аяк астында буталып, комачаулап йөрмәсен өчен шулай эшләгәннәрдер инде, – ди ул. – Үземнең дә кайнатама бала вакытта берәүләрдән мамык машинкасы алып кайтырга кушканнар. Анда барса: «И-и, ул машинканы башка берәүләр алып торган иде бит әле», – дип, шаяртып, Тәлгать әтине тагын да арырак озатканнар. Тәки буш кул кайтырга туры килгән аңа...

Казлар авыррак йолкынса, сугымчыга эләккән инде. Берәр чаярак хатын, шыпырт кына килеп, арттан берне кундырган. Тәҗрибәле сугымчылар алдатмаган анысы – поднос кыстырып килә торган булганнар. Монысын үземнең әтием Җәүдәттән белдем.

Казларны урнаштырып, бераз сулу алгач, әни күрше әбиләрен дә каз ашына чакыра иде. Күрше Зәкия, Хәдичә әбиләр кереп, башта каурый сыдыралар. «Сыдырган мамык кушсаң, мендәр тиз генә искерми», – ди торган иде әни.

– Мендәр сөрүенә каз мамыгын тутыру эшен парлы хатыннарга гына тапшырганнар. Кияүгә бармаган яшь кызлар да, ире үлгән толлар да мендәр тутырмаган. – Балтач районы Шуран җирле үзидарәсенең «Ак калфак» оешмасы һәм ветераннар советы рәисе Әминә апа Мөхәммәтҗанова әнә шулай ди. – Беренче кар төшеп, көннәр суыткач, безнең Балтач якларында да каз өмәләре башланып китә. Иртәрәк ярамый: салкында казның мае калыная, итенә чын тәм керә. Кичтән казларны инештә коендырып алып менеп, чиста салам өстендә төн кундыралар. Мамыгы чиста булсын өчен шулай эшлиләр. Иртәгә каз суясы дигән көнне йорттагы хатын-кызлар йокламый инде. Аш-суын пешерәсе, мунча идәннәрен ышкып юып, мамык төшерергә урын әзерлисе бар... Ирләр пычак кайрый, каз тәпиләрен бәйләргә бауларны барлый... Иртән иртүк, кояш чыкканчы ук эш башлана. Без яшь вакытта казның йонын – аерым, мамыгын аерым төшерәләр иде. Йоны – түшәкястыкка, мамыгы – мендәргә. Йолкып бетергәч, карлы ләгәннәргә тыгып, казларны суыталар. Аннары кызлар өс-башларын кагарга дип урамга чыга. Урамда нинди кеше очрый, булачак ирең дә шундый кеше була дигән бер ырымы да бар иде. Башка төрле ырымнары да күп. Мәсәлән, казның муенын кисеп түгел, борып алалар бит. Анысын да кызлар башкара. Муенны ничә тапкыр борып ала, шул елдан гына кияүгә чыга, имештер.

Казларны суыткач, эчен алалар. Аннары кайнарлау, чистарту кебек эшләр кала. Эчәкләрне орчык башы белән әйләндереп, кат-кат юалар, ул ап-ак була. Эшкәртеп бетергәч, казларны пар-пар итеп көянтә башларына элеп, кызлар чишмәгә төшеп китә. Хәзер күп җирләрдә күрәм: казларны көянтә башына берәрне генә элеләр. Ул парлы итеп, казларны бер-берсенә

Фото: «Татар-информ». Салават КАМАЛЕТДИНОВ.

Каз өмәсе – Сабан туе кебек үк, халкыбызның иң кадерле ядкаре.

аркалары белән терәп, канатларын канатка чалыштырып эленергә тиеш – йоласы шундый.

Чишмә буе – элек-электән гашыйкларның серләшү урыны саналган. Каз юганда да киез итекләре бозга ябышып калган яшьләр була торган иде. Якындагы берәрсеннән җылы су алып килеп, кубарып алмасаң, итегенең табаны төшеп кала. Табансыз кайтып китүчеләр яки, кузгалып китәм дип, җиргә мәтәлүчеләр дә булмый калмый. Кызык итеп сөйләргә бер вакыйга була инде ул. Менә берзаман кызлар тезелешеп су буеннан кайта. Гаҗәеп матур күренеш!

Каз ашын шул көнне кич яки икенче көнне уздыралар. Безнең Түнтәрдә бәбкәләр бала-чага кебек ишле булсын дип, балалар ашы үткәрү гадәте дә бар иде.

Култык астындагы берничә бөртек хәрам йонынннан тыш, казның бер генә әйберсе дә әрәм булмый. Йонмамыгы – мендәргә, ите – ашарга, мае ризык кыздырганда тотыла. Каз мае туңмай шикелле катмый, гел йомшак булып тора. Өшегән, туңган җирләрне дәвалар өчен дә шифалы. Канаты белән идән себерергә кулай. Каурый очыннан май канаты – дөгәч ясыйлар... Ә каклаган каз тагын! Анысы әле дә иң-иң затлы сыйлардан санала.

Әлеге фикерне Ләйсән апа да дәвам итә:

– Казның койрык сөягендә бер учма йоны була. Каз күтиге диләр аны. Менә шуны юып-киптереп, яшь кызлар битләренә кершән якканда тоткан. Күз тимәсенгә, помпон итеп, балаларның башлыкларына такканнар.

Азнакай районы Буралы авылында яшәүче Фәридә апа Шәйдуллина да әнисенең каз өмәсе уздыруын искә алды.

– 1980 еллар дип хәтерлим, – дип сөйли Фәридә апа. – Әнием Зәмзәмия борынгыча итеп каз өмәсе уздырырга уйлады. Авылдагы уңган кызларны чакырдык. Гармуннарын күтәреп, егетләр дә килеп җитте. Без ул вакытта мунчада түгел, өйдә йолыккан идек. Каз өмәсенә яшь кызлар гына түгел, яшьлекләрен сагынышкан әбиләр дә килде. Һәркемгә эш җитәрлек була бит ул каз йолыкканда. Җигүле атка утырып, әбиләр чишмәгә каз юарга да төште әле хәтта. Үзләре юмасалар да, кызларны өйрәтеп тордылар. Шул матур бәйрәм күңелдә ничә еллар йөрде дә, моннан берничә ел элек үзем дә зур итеп каз өмәсе уздырдым. Шулай ук бизәп атлар җиктек, чишмәләргә төшеп казлар юдык... Бик күңелле булган иде. Миннән күреп, башкалар да кызыгып калды.

Моннан ике еллап элек, Кайбыч районына командировкага баргач, үзебез дә каз өмәсенә туры килдек. Ишегалдындагы кечкенә өйне җылытып, бишләп хатын-кыз шау-гөр килеп казларны йолкып бетереп ята иде инде. «Өмәгә иртәнге алтыдан киләләр аны, көндезгә инде эш бетә», – дип, шаяртып шелтәләде алар безне. Идәнгә зур җәймә җәйгәннәр дә, түгәрәкләнешеп утырганнар. Гөрли генә эшләре, мамыклары оча гына. Шактый эшләп өлгергәннәр – ишегалдындагы озын өстәлдә чистартылган казлар тезелешкән. «Инде боларны салкын суда юасы да, элеп куеп, суларын саркытасы», – диеште өмәчеләр.

Хуҗабикәнең сөйләшергә дә вакыты юк – каз йолкучыларны сыйларга табын әзерләп мәш килә.

– Инде бу бишенче йортыбыз, – ди кызлар. – Әле тагын чакыручылар бар. Монда тиз кирәк, белеп эшләргә кирәк...

Белеп эшләргә кирәк дигәннән... Килен булып төшкәч, кайнанам Миңлегөл әни дә каз өмәсе уздырды. Олы килене буларак, өмә башы мин булырга тиеш тә бит... Инде күптән казлар йолыккан юк, онытыла икән ул. Казның бүтәкәсен чистарту эшен миңа тапшырдылар. Сары элпәсен тавыкныкы шикелле җиңел генә кубармакчы булам, юк, бирешми. Күрше-күлән, туган-тумачаның сынаулы караш ташлап алганын сизеп торам. Ярый әле иремнең Раушания апасы: «Тавыкныкы шикелле җиңел генә купмый шул казныкы, аны пычак белән кырырга кирәк», – дип, сиздерми генә ярдәм итеп җибәрде. Балалар тугач, кайнанам һәрберсенә аерым-аерым мендәр ясап биргән иде. Әле дә тузмады шул мендәрләре, өр-яңа кебек.

Татар халкында каз белән бәйле ырымнар да күп. Мәсәлән, казлар бәбкәне күп чыгарсын өчен, киек казлар кайткан вакытта җирдән салам алып, каз оясына салганнар. Казларны чишмәгә юарга төшкәндә юл буйлап сыдырган каурый чәчә барганнар. Бу да киләсе елга казлар ишле булсын, судан тезелешеп кайтсын дигән нияттән башкарылган. Яр тутырып казлар үссен дип, кайбер авылларда каурыйны су буена тезеп чыкканнар. Каз өмәсенә килүчеләр канат урларга тырышкан. Канат урлап алып кайтсаң, үзеңнең дә казың уңа, имеш. Ә хуҗалар канатны саклап кына торган, тиз генә санап алып куйганнар. Бик гозерләнеп сорасалар, канатны өй почмагына кыстырып калдырганнар, кирәк кеше шуннан алып киткән. Кешегә биргәндә канатның очын кисеп, казан өсләрен сыпырып кына да биргәннәр. Югыйсә кул арты китәргә мөмкин, дигәннәр. Каз канатын еракка, су артында яшәүчеләргә бирергә ярамый дигән ырым да бар. Кайдадыр сул канатын бирергә яраган, ә уң канатны бирәүгә дә бирмәгәннәр.

Тере казны да ырымлап кына сатканнар. Усал, мәкерле кешеләргә каз сатмаганнар. Алган кеше сатучыга бер телем ипи бирергә тиеш булган.

Безнең як авылларда инде күптән йорт казлары асрамыйлар. Урам тутырып утырган ап-ак казлар – инкубатордан алып үстерелгән бәбкәләр. Шулай булса да, Сабан туе кебек, каз өмәләре бүген дә онытылмый. Дөрес, аны инде авылның бар уңган кызларын чакырып уздырмыйлар. Үз туганнарың, дуслар, күршеләр җыелышып эшли. Аның монысы да бик күркәм бит. Димәк, дуслык, туганлык, күрше хакы дигән олы хисләр онытылмый. Башка бәйрәмнәр кебек үк, каз өмәләре дә безне бердәм итә. Менә шуның белән кыйммәт тә ул.



« Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Киләсе елга «Сөембикә» журналына 110 ел тула!
Бу безнең өчен дә, сезнең – аның тугрылыклы укучылары өчен дә зур бәйрәм. Ә бәйрәм бүләксез булмый!

2023 ел (6 ай, 12 ай) өчен «Сөембикә» журналына язылып, квитанция күчермәсен редакциягә юллаучылар арасында түбәндәге бүләкләр уйнатыла:

ЙӨЗ УН!

/ **мультиварка** (2 данә)
/ **электрогриль** (2 данә)
/ **электр иттарткычы** (2 данә)
/ **планетар миксер** (2 данә)



Ә 2023 ел өчен бер елга журналга язылып, квитанция күчермәсен иң беренчеләрдән булып редакциягә юллаган 110 абунәчебезнең һәркайсы махсус бүләк алачак. **«Матурлык сандыгы»!***



Квитанцияләр 2023 елның 20 гыйнварына кадәр кабул ителә.
Бүләк уйнату 23 гыйнвар көнне узачак.

Квитанция күчермәләрен редакциягә җибәрүнең берничә юлы бар:
почта аша: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт
редакциянең электрон почтасына: ssuum@yandex.ru
ватсап номерына: 8(937) 288-18-01

АО «ТАТМЕДИА» реклама 16+

* Акция турында тулырак www.syuyumbike.ru сайтында укыгыз.

PRESSA

КАР БУРАНЫ... ЧИКСЕЗ АКЛЫК...



Оксана ИЛЬЮП

Ярым...

Бар җиһаным синең белән.
Синең якта.
Ярымчиттә булалмыймын
берничек тә.
Йөрәгемә ярсу салып сине
күзлим
һәм
таныш шәүлә күренәдер
күк-ишектә.

Тәрәзәгә төн үрмәли. Әлли-бәлли
Моңын көйли җилләр.
Гүя мин бишектә.
Синең сулыш бугай ан(ы)сы,
җилләрмени.
Юк,
ярымъерак булалмыйсың
берничек тә.

Сабыр булып таңны көтәм.
Әкрен генә
аркамнан үп.
Уйларымны син ишет тә.
Елмаермын төш аралаш
җылың тоеп.
Син
ярымъякын булалмыйсың.
Берничек тә.

Арабызда карлар...

Беркем аңламаган йөрәгемне
Ак бураннар гына аңлый белә.
Арабызда карлар.
Үтәлмәслек.
Һәм шул мәнә бәгыремне телә.

Әллә каян чикләр килеп чыкты.
Әһ, әгәр бу миннән генә торса!
Арабызда көртләр.
Шундый сәер –
Кичә генә якын идек юкса.

Ваз кичәмен синнән. Әмма һәр төн
Хатирәләр кабат били аңны.
Арабызда бозлар.
Һәм шул мәнә
Умырып-умырып
сызландыра җанны.

Толымнары энҗер төсендә

Чәчләренә кояш качкан бугай –
Толымнары энҗер төсендә.
Яланаяк йомшак кына басып
Йолдыз җыя күкләр йөзендә.

Әллә оча, әллә йөзә (гаҗәп!);
Ак күлмәге җилдә җилферди.
Уйнап микән, чынлап микән инде –
Үзе көлә, үзе бик җитди.

Үзе салкын. Үзе, бик теләсә,
Яндырыр күк ялкын эчендә.
Ә чәчләрен кояш үпкән бугай –
Толымнары – энҗер төсендә!

Ниләр генә юраса да дөнья

Ниләр генә юраса да дөнья,
Бу табигать кышлыгыннан купкан.
Бәйсез күңелең язык язны сорап,
Мине беркөн онытуыңнан куркам.

Ә син мине кочагыңа төреп,
Үбәсең дә кабат маңгаемнан,
«Шикләнмә» дип пышылдыйсың.
Шулчак
Куркуларым юкка чыга сыман.

Үз-үземнең юләр уйлардан да
Кочагыңда мин тынычлык табам.
Ниләр генә юраса да дөнья,
Без бәхетле.
Һәм без бергә.
Һаман!



Әлфирә НИЗАМОВА

Кыш җыры

Җәяүле буран себерә,
Әй, карлар оча гына.
Кереп барам табигатьнең
Мамыктай кочагына.
Кар бураны, чиксез аклык,
Җир белән күк тоташкан.
Күңелдә – уй, җирдә җилләр
Бөтерелә тоташтан...
Иңнәргә килеп сарыла,
Куна керфек, күзләргә...
Җаныма кереп оялый,
Әверелә сүзләргә...
Җәяүле буран урамда,
Әй, карлар оча, туза...
Ак дөньяны ду китереп
Кыш моңлы җырын суза.

* * *

Көлемсерәп көнгә кереп барам –
Иске елның иске көненә.
Сугар сәгать... җаннар тоташырлар
Яңа елның яңа төненә...
Күңел кабат тиз-тиз баскыч куяр
Өмет-уйдан хыял күгенә...
Догаларга төренеп ак теләкләр
Урнашырлар йөрәк түренә...
Көлемсерәп көнгә кереп барам –
Иске елның соңгы көненә.
Яңа елга аяк басу насыйп,
Күңелләр бит шуңа сөенә.
Олы бәхет яңа елга керү
Исәнлектә, бәхет, саулыкта...
Илләр тыныч булып, яшик әле
Бәрәкәтле байлык, муллыкта!
Көлемсерәп көнгә кереп барам,
Бәхет юрап килер көннәргә...
Чәчәк кебек карлар ак нур сала,
Сөрмә тарта керфек, күзләргә...



Равилә
МӨБАРӘКШИНА

Галиҗәнап вакыт

Вакыт җыя, вакыт тарата,
Вакыт – дәва, вакыт кичерә.
Үлчәүләрдә бизмән белән үлчи –
Яши-яши ышанганнар илчегә.
Галиҗәнап вакыт!
Вакыт туплый, вакыт тарата,
Вакыт сыный, кайчак сыната.
Ләкин үлчәүләрдә төгәл үлчи –
Яши-яши ышанганнар илчегә.
Һәммәбез дә җирдә – илчеләр...

* * *

Их!..
Күк капусы ачылганын күрсәм иде,
Ак сакаллы изгеләрнең анда
Тантаналы мәрәсимен тойсам иде.
Сәҗдә китеп шулчак теләк
теләр идем:
«Илләр-көннәр имин булсын!» –
дияр идем.

Теләкләрнең иң мөһимен
теләр идем:
«Изге ният, таза тәүфыйк,
якты бәхет
Бир син, Раббым, һәр кешеңә!» –
дияр идем.

Җиде төндә
көмеш йолдызларың белән
Җиде кат күк уртасында,
тыныч төндә,
Шушы галәм киңлегендә
Синең белән
Күк капусы ачылганын күрсәм иде!
Их!..

* * *

Мин сине кояшлы көзләрдә эзләдем,
Алтындай арышлар тулганда.
Мин сине буранлы
кышларда эзләдем,
Бар дөнья ап-акта булганда.
Мин сине эзләдем,
тик сине эзләдем,
Кабатланмас яшьлек гүзәлем!
«Ул сине ярата бик!» – диеп,
Әйтегез, җырларым, үзенә!



Вәзилә
ЧИНАЕВА

Миләшем-сердәшем

Сукмак буйлап атлап киләм,
Ап-ак карлар явып узган
Кызыл-сары тәлгәшләрдән,
Ай-һай, быел миләш уңган.

Көзен ачы булган җимеш,
Йөзем кебек татлы кышын.
Кышкы салкын буранда да
Тәлгәшләре саклый төсен.

Һәр көн киләм яннарына,
Тәлгәшләрен барлый-барлый.
Серләремне сөйлим аңа,
Миләшкәем мине аңлый.

Сукмак буйлап атлап киләм,
Миләшемә нәрсә булган?
Ак карларда – кызыл җәймә:
Миләш белән сукмак тулган.

Ак карларда – кызыл миләш,
Кышкы кичтә моңсу сурәт.
Коелгач җимешләрең,
Кемнәр бирер миңа киңәш?

Ак күлмәкле ак кышлар

Һәр агачны, һәр ботакны
сыкы баскан,
Гүя алар энҗе-мәрҗән,
сәйлән аскан.
Ялт-йолт итә шул сәйләннәр
айлы кичтә,
Моңсулатып күңелләрне,
салып хискә.
Табигатьтә шундый тынлык –
исми җиле дә.
Коелудан курка төсле
сәйлән җиргә.
Мамык кебек ап-ак шәлдән
каен-имән,
Әйтерсең лә кунак булып
туйга килгән.
Чыршы-нарат ак күлмәктән –
килен төсле,
Кыш фасылы кабул итми
башка төсне.



Галия
ГАЙНЕТДИНОВА

Ак томаннар

Ак томаннар. Әйтерсең лә җиргә
Ак болытлар күктән төшкәннәр.
Төшкәннәр дә үзәнлекләр буйлап
Таулар итәгенә күчкәннәр.

Көтүлекләр, куе әрәмәлек
Ап-ак томаннарга төренгән.
Җир белән күк арасына шулай
Томан толымнары үрелгән.

Томаннарга әллә мин иярәм,
Әллә алар миңа иярә?
Кайтып киләм шулай иртә таңда
Тәүге тәпи баскан җиремә.

Яшьлегем учагы

Толымнарын чайкый суда таллар,
Җилләр килеп тарый чукларын.
Тыңлыйм чишмә җырын,
Күрәм, әнә, моннан ерак түгел
Без кабызган учак утларын.
Хәтер күрә, очкын чәчә-чәчә
Уйнап янган яшьлек учагын.
Кире кайтарып, эх, булса икән
Гомерләрнең җанга җылы биргән
Мәңге онытылмас шул чагын.

Минем учта

Карлы юлдан әле яңа гына
Чанасына печән төялгән
Бер ат узган.
Төшеп калган аннан бер уч печән.
Хисләремне минем кузгатырга
Шул да җиткән.

Бер уч печән. Таныш чәчәкләре.
Җиләк яфраклары, үләннәр.
Алар кипкән.
Җылы тыным өреп, терелтәсем килә.
Җәйләремне кыштан кайтарырга
Шул да җиткән.

Бер мизгелгә әллә җәйгә кайттым,
Әллә инде нәни чагыма?
Ак кар тышта.
Гомеремнең узган җәе бүген
Аңкып торган хуш исләре белән
Минем учта.



Гөлүсə Закирова хикəясендə – бүгенге кырыс чынбарлыгыбыз. Билгесезлек, көтү, борчылулар... Ə Яңа елга керер алдыннан күңел барыбер могҗиза көтə. Хикəя геройлары да көтелмəгəн сөенечлəр турында хыялланып яши, язмышларының бəхетле чишелешенə ышанасы килə. Укыгыз əле: якты килəчəккə өмет уята бу хикəя!



Гөлүсə ЗАКИРОВА

БИЯЛƏЙ

(Хикəя)

Үтəли җил җанны каезлый. Муенына ураган шарф очларына учларын яшерергə тырышты Газизə. Нигə туңа аның куллары? Өзлексез телефонына баскалагангамы? Фəнил яздымы? Фəнил кайда? Бүген чыгаралармы? Кайчан алып китəлəр?.. Шуның ише билгесезлеккə җавап əнə шул телефонда гына яшеренгəн иде кебек. Хəзер бер хəбəр килер дə авыр киноның иң яхшы финалы булыр төсле.

Газизəнең «Казан Экспо» каршына килеп басканына ярты сəгать үтте инде. Ə Фəниле күренми. Парковкада машина куяр урын да калмаган. Ничек кирəк, шулай бер почмакта урнашып, штаб каршына килде ул. Кертмəделəр. Озакламый полигоннан кайтасылар икəн. Көтəр. Җир читенə китсə дə, көтəргə əзер ул аны. Кайтсын гына...

Казаннан читтə – аэропорт янəшəсендə үк урнашкан «Казан Экспо» күргəзмəлəр үзəге берничə атна эчендə аерым бер дөньяга əйлəнгəн дə куйган. Əле ике ай элек кенə бу урын дөньяның төрле кыйтгаларыннан корылтайга җыелган, милли киемле, шат күңелле миллəттəшлəр җыр-моңына күмелгəндер дип һич əйтмəссең. Кайдадыр һаман шундый күтəренкелек бардыр. Əмма мобилизациялəнгəннəр өчен, аларның якыннары өчен яшəүнең элек һəм хəзер дигəн чиклəре барлыкка килде. Əнə Экспо ангарлары тимер рəшəткəлəр белəн əйлəндереп алынган, анда хəзер солдатлар яши. Кайда да хəрбилəр. Рəшəткəне дə хəрбилəр саклый, солдатларның үзлəрен дə...

Газизə рəшəткəлəрне учы белəн кысып тотты. Тимернең салкынлыгы кайнар əрнүгə əверелде. Ниһаять, якын-тирəдəге сөйлəшүлəр колакка чалынды.

– Əти! Əти! Син миңа тəти алып кайтасыңмы?

– Иң яхшысын, иң матурын алам, билгеле!

Баланың челтерəп көлгəн тавышы Газизə колагын да иркəли.

– Əтисе, менə бу пакетта өч пар оекбаш, балаклава-башлык, биялəй...

«Əтисе» җавап биреп тормый, пакет кыштырдаган тавыш ишетелə – кулына алды, ахры. Газизə чыдамый – аларга таба борыла. Бəлəкəч сабын куыгы очырып уйнап йөри, ире хатынын кочаклаган да, тын калганнар. Кулындагы пакет җил искəн саен кыштырдап тора... Ə Газизə биялəй алмады. Кулы туңмаган булыр иде менə...

Кайдадыр кычкырып сөйлəшкəн тавышлар ишетелə. Яшьлəр көлешеп тə алалар. Ə-ə... əнə бер компания килгəн дə машина капотына кабымлыклар куеп, сыйланалар. Мөгаен, дусларын озаталардыр.

Телефон шалтырады. Иптəш кызы икəн.

– Сəлам, Газизəкəй!

Ул гел шулай. Гел шат. Аңа үпкəлəп булмый. Ул киселгəн əфлисун кебек: тəмле телле, җор сүзле, җылы энергия чыганагы. Битендəге чокырлары да тулы бəхет аның. Үзе шуны башкаларга тараткан саен, күбрəк өстəлеп тора шикелле.

– Сәлам, Айгөлем...
– Шундамы?
– Әйе. Фәнилне көтәм.
– Хәзер без дә килеп җитәбез.
– С1 терминалы янында. Яме!
– Яме!!! Кара аны, көн болай да бозылырга тора, яшьләрең сыгасы түгел.
– Түгел инде, түгел...
Айгөл шалтыраткач, өмет уянды. Өметсез булмый. Буласы булган инде хәзер. Повестка килгән – үзе кебек ир-егетләр белән бергә ватан сагына басты Фәниле. Аны – Газизәне бер мәртәбә газап дигән уттан тартып чыгарган батыр да иде шул ул. Тагын сынатмас. Ил белән бит...
...Газизәнең эшкә урнашып йөргән чаклары. Радиога! Алып баручы булып! Бәхетле көннәр. Айгөл белән әнә шул радиода якынаеп киттеләр дә инде. Бер бүлмәдә утыралар, берсенең компьютеры паролен икенчесе белә. Егетләр белән дә язышкалап алалар. Дамир белән язышкан Айгөлгә Газизә матур шигырьләрне табып кына тора. Шагыйрь егет, ахры, Газизәнең экспромт шигырьләрен Айгөлнеке дип, тәмам хыялланды бит. Өзми дә куймый очрашуга чакыра башлады.
– Газизәкәй, кәгазь битенә шыпырт кына булса да фирменный шигырь юллары язып биргәләрсең, әйдә, әйләнеп кайтыйк. Иптәш егетен дә алып килмәкче. Үзем генә нишләп йөрим инде, хет туйганчы көлербез, әйдә инде...
Шулкадәр өзгәләнеп сорый бит, чакыра белеп тә чакыра.
– Әйдә, тик алдан ук сөйләшеп куйыйк, теге егеткә мине кодалыйсы түгел.
– Түгел инде, түгел...
Аннан тәм табып көләләр. Кызларның чырык-чырык килүләрен ошатып бетермәүчеләр дә булды, билгеле. Фәнисә Сәлимовна – күрше кабинетта гына утыра. Трафик буенча бик күптәннән эшли торган «карт бүре». Күрмәгәне, белмәгәне юк. Радионың бөтен гайбәте дә, күзе дә анда. Түрәләр дә шүрләп тора бугай,囲 эштә алныартны гел карап йөрергә тырышалар. Аны күрсә, вахтер бабай да урыныннан торып, ишекне ачып кертә. Кызларның Дамир белән свиданиега киткәне дә сер булып калмады. Яшел «десятка»ны тәрәзә жалюзилары артыннан күпне күргән «сканер» күзләр озатып калды.
Кызларның анда эшләре юк иде... Карап калмагае...
– Көнләшүдән шартлап үләр инде әбекәй... – дип, Айгөл шыпырт кына Газизәгә пышылдады.
Газизә елмайды гына, чөнки Фәнисә Сәлимовна көн кадагыннан бик тиз төшеп калды, онытылды, эреп югалды. Егетләр бик «культур-мультур» булып чыкты. Кафега кереп каһвә, круассан белән сыйладылар, Казанны машинада аркылыга да буйга да әйләнделәр, аннан Бутлеров урамын җәяү иңләделәр. Гаҗәп, моңарчы ничек күрмәгән ул борынгы йортлардан гына торган тарихи урамны?! Дамирның дусты Илнар медакадемиядә эшли икән. Бутлеровка терәлеп торган тыкрыкларда медицина корифейлары әлегәчә йөри кебек тоелды. Авызына карап тора белә Илнар. Урам фонарьлары яктысында беренче кар бураннары вальс уйный башлады. Соң иде. Илнар кайтарып куярга булды. Башта Дамир белән Айгөлне озаттылар. Ахырдан, тулай торак каршында Газизә төшеп калды. Матур кичкә хисләнеп ишек катында кар бөртекләрен учында эретеп басып торды әле ул. Әмма кермичә булмый, унбердән соң ишекне бикилиләр, таңга кадәр кар чүпләп басып торып булмас...
Икенче көнне эш телефонына шалтыратты Илнар. Әрсез, дип ачуланырга авызын ачкан гына иде, өлгермәде. Әй Аллам, ничек ди: «Кичә бияләйләреңне махсус «онытып» калдырган идеңме?»
– Нишләп онытыйм! Алар үземдә ич минем!
– Менә бит. Ак йон бияләй. Синеке түгелмени?
– Дөрес, минем ак бияләй. Мин аны өйдә онытып чыкканмын дип торам.
– Ну чыгып ал инде.
– Әллә эшкә килдең?
– Килдем.
– Минем эфир вакыты. Тагын ярты сәгать.
– Көтәрмен.
Бу юлы алар Кабан күлендә үрдәкләр ашаттылар. Киләсе очрашуда зоопаркта маймыллар санап чыктылар.
Газизә кулга ияләшә башлаган иде инде. Илнар аның өчен генә туган яр кебек. Яңа елга хәерле теләкләр генә теләргә кирәк. Быел ул бәйрәмне ялгыз үткәрмәячәк.
Бер көнне эфир вакытын төгәлләп, кабинетына менүгә:
– Минем Илнар шалтыратмадымы? – дип сорап куйды ул.
Фәнисә Сәлимовна да шунда икән, ике урындыкны бер итеп утыра. Кылыч борынына элгән күзлеге белән җаныңны үтәли тишеп карап тора, нидер әйтергә җай чыкканга сөенеп, сүз ала:
– Нишләп синеке булсын ул? Аның бит хатыны бар!
– ...
– Җаным, кеше ирләре белән йөргәнче, ахырын чамаларга кирәк. Гаиләсе юкмы икән моның дип уйлап та карамадыңмы? Әллә белә торып, кеше ирләре белән типтерергә җыенган идеңме? Билләһи, оят юк бу яшьләрдә. Менә рәхмәт әйтерсең аннан минем кебек апаңнар белән эшләгәнгә. Ышанмасаң, менә, кара, – дип, белешмә китап чыгарып өстәлгә куйды Фәнисә апасы. – Укый беләсеңме? Белмәсәң, кычкырып укыйм: Илнар Гарифуллин, медакадемиядә АХЧ мөдире. Өйләнгән, ике баласы бар.
Башлары әйләнеп китте Газизәнең. Хезмәттәшенең шулкадәр тәмләп табышлары белән уртаклашуы күңелен болгатса, Илнарның интригалары аны тәмам гаҗиз иткән иде. Боларның икесенә дә цирк аренасы кирәк булган. Менә тамашачылар, уенчылар, корбаннар...
– Алай гына да түгел, җаным, Фәнисә апаң күзләре күрмәгән бер генә адәм актыгы да юк бу дөньяда. Илнарның улы әнә каршыдагы гимназиядә укый. Класс җитәкчесе – минем ахири. Ышанмасаң, безнең бина артындагы гаражлар янына чык та көтеп тор – тәмәке тартырга өйрәнеп ята малае. Ничек танырмын дип карыйсыңмы миңа? Танырсың! Кулын сындырган узган атнада. Уң кулы – гипста. Булдымы? Рәхмәт әйтерсең әле менә үземә.
– Рәхмәт...
Газизә баскычтан аска очты. Беренче каттагы бүлмәгә кереп бушанырга кирәк. Тавыш яздыру студиясе буш иде – әйбәт булды әле – елаганын беркем ишетмәс.



Фәнисә Сәлимовна тантана итә иде. Күтәрелгән аякләре «Мин булганда чебен дә очалмас» дия иде кебек. Айгөл гадәттәгечә, елмаеп, бүлмәсенә озатты хезмәттәшен.

– Ай маладис, Фәнисә. Белмәгәнең юк. Моның өчен сиңа медаль бирерләр инде. Радиода эшлисеңме син, КГБдамы? Һич аптыраган менә.

– Белеп торырга кирәк. Кызлар башыннан йөри ул ирләр.

– Улы чынлап гимназиядә укыймы?

– Чынлап. Ышанмасаң, әнә кара... – Фәнисә Сәлимовна тәрәзәдән гаражлар артына баручы өч-дүрт малайга ишарәләде. Айгөл тәрәзәгә күз салды. Кулы гипслы малай коеп куйган Илнар иде.

Студиядә караңгы. Гадәттә, тавыш яздыру кабинасында Кәрим абыйлары утыра, менә бу микрофонга артистлар шигырь укый, җыр башкара. Бүген берәү дә юк. Күңел дә бушап калган.

Газизә телефоныннан таныш саннарны җыйды. Таныш тавышны ишетүгә бер сулышта соравын яудырды да:

– Илнар, син өйләнгән кешеме? – Трубканың аргы башында телсез калдылар. – Синең чыннан да ике балаң бармы?

– Ну син... булса ни... Мин бит вәгъдәләр бирмәдем.

– Рәхмәт, яме. Дөресен әйткәнгә рәхмәт. Бәхетле бул. Башка мине эзләмә инде син, яме. Минем дә йөргән егетем бар. Яңа елга никахыбыз булачак.

– Аһ, син, сука... Хатын-кызның барысы да бер камырдан. Давай, пока.

Газизәнең нишләптер елыйсы килмәде. Микрофон каршына килде дә шигырь укырга кереште:

– Шаянлыгым өчен генә / Үпкәләр дә күбегез. / Тормыш бит ул – бер картина, / Ә бизәге – үзебез. / Хисләр белән уратылып / Шау килеп гомер уза. / Кичерегез, йөрәгемә... / Бер генә кеше хуҗа!

Шулчак баян тавышы ишетелде. Моң иясе «Хәмдия» көен уйный иде. Газизә кем уйнаганын да сорап тормый, хискә бирелде, җырлап җибәрде.

– Яр гынай булып яралмаган, җаннар көйдерер өчен яралган...

Җырга егет кушылды:

– «Хәмдиягә сүз әйтмәгез, / Зиһене таралган чагы...»

Газизәнең бөтенләй елыйсы килми иде инде. Киресенчә, кәефе күтәрелде. Кем бу егет? Йөрәк ярасын шулай юа алган баянчыга рәхмәтле иде ул. Фәнил белән ул әнә шулай танышты. Җыр яздырырга килеп, уңайсыз сөйләшүнең шаһиты булган, матур шигырь тыңлап, үзе дә уенга кушылган Фәнил аның тормышын үзе дә сизмәстән бөтереп тә алды.

Урамда кар бөртекләре куып йөрмәде алар. Бер кич туйганчы җырлаштылар, икенче кич шигырь укыдылар. Концерт киемнәрен, баянын Газизә бүлмәсендә калдырып торган көнне, бәлки миңа күченерсең, дип, егет тәкъдим дә ясады. Яңа елга никах укытырбыз, диде. Тик... Күчену мәшәкатьләре белән янган көнне тагын бер сынау көтеп торган икән. Ачык ишектән ишек шакымый гына военкомат вәкиле килеп керде. Фәнил кулына өлешчә мобилизациягә повестка тоттырды...

Тимер рәшәткәләрдән суык үтә башлаганда, арттан кочаклап алдылар. Фәнил! КППдан күзен дә алмады лабаса. Кай арада чыгып җиткән диген.

– Тәрәзәләрдән ай караган, түшләренә мәрҗән кадаган...

Газизә генә ишетерлек итеп таныш җырны сузды Фәнил. Кызның йөрәге учка тоткан чыпчык баласы кебек бәргәләнә, еламаска тырышудан тәне калтырана иде. Солдат бушлатына сенде ул. Тәмәке, тир исе – ирләр исе килә. Әмма ул кочакта тыныч һәм җылы иде. Аяк астында күшеккән яфраклар ятып кала, салкын тын күләгәсендә кар бөртекләре биешә. Бер бушлатта ике йөрәк тибә...

Шул арада меңләгән халык арасыннан Айгөл белән Дамир да эзләп тапты үзләрен. Бер-берсенең күңелләрен күтәрергә тырыштылар. Шаярган булдылар. Көлеп саубуллаштылар.

– Ул әйләнеп кайтачак, – диде Айгөл, Фәнилне озатып өйгә юл тотканда.

– Кайтачак! – диде Газизә. – Тиеш!

Әмма вакыт бик акрын уза. Менә бер атна инде хәбәре юк. Газизә сабыр гына көтәргә вәгъдә бирде. Ул еламый, ул кайтыр көнне саный.

...Яңа ел алды көннәрендә почта әрҗәсендә бер кәгазь ята иде. Нидер килгән. Әй Ходаем, нинди хәбәр, нинди хат... дип, өйгә дә керми, кәгазьне алып, почтага очты. Анда исә кызга бер кечерәк кенә тартма тоттырдылар.

Өйгә кайтып җиткәнче, аяклары йомшарып, хәлсезләнгән иде ул. Куркып кына тартманы ачты. Ә андагы төргәктә... ак мамык бияләй ята иде. Һәм Фәнилдән хәбәр:

– Кулларыңны туңдырма!



Рәсем: Наталья Васильева

КИТАП УКУ – УЛ ТРАДИЦИЯ

КИТАП УКУ УЛ...

– Белем дәрәҗәңне күтәрү, дөньяга карашыңны киңәйтү. Бер сүз белән әйткәндә, шәхесеңне үстерү.

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...

– Укырга мәхәббәт уяткан авторымны атыйсым килә. Әмирхан Еники! Мәктәптә укыганда ул язучыга, аның язу стиленә, иҗатына гашыйк булдым. Аның әсәрләре арасыннан иң яратканы – «Әйтелмәгән васыять». Шул повестьне укыганнан соң китапларга кереп киттем. Ул чын-чынлап миндә укуга мәхәббәт уятты.

МИНЕ /ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ/ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...

– Антуан де Сент-Экзюпери «Маленький принц». Тулысынча карашымны үзгәртте дип әйтә алмыйм, ләкин яңа фикерләр өстәде, дөньяга бераз башкачарак карый башладым.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ-КИТАП...

– Әлбәттә инде, Әмирхан Еники. Аның җыелма әсәрләре. Аннан соң Чеховны яратып укый идем. Укыган һәр әсәрен хәтерлим.

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ

– Чит ил классикасын бик яратам. Бигрәк тә XIX–XX гасыр язучыларының әсәрләрен. Өстәлемдә һәрвакыт Оскар Уайльд әсәрләре һәм Джером Сэлинджерның «Над пропастью во ржи» китабы ята.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

– Инде күптән укый башладым, әмма укып бетерә алмадым. Дэниел Киз «Цветы для Элджернона».

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ ӨЧ ЯРАТКАН ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ...

– Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – 41 нче ел балалары» һәм, әлбәттә инде, иң беренче урында – Әмирхан Еники. Аның «Матурлык» әсәре.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...

– Басма китап та, электрон китап та хәзерге заманда кулланыла. Аларның бер начар якларын күрмим. Улым Айдан белән аудиокитапларны да тыңлыйбыз. Алар самолётта очканда бик уңайлы. Ләкин моңа карап кына, басма китаплардан баш тартырга җыенмыйбыз. Ул бит аерым бер идиллия. Кич белән яткач, кулга китап алып, битләрен ача-ача уку үзенә күрә бер искиткеч, күңелгә якын һәм җылы күренеш, хәтта бер традиция дә дип әйтер идем.

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...

– Татар, рус, чит ил классикасын укыгыз. Классика ул бөтен китапларның нигезе дип саныйм. Данлыклы авторларның китапларын кабат-кабат укысак та, артыгы булмый. Мәсәлән, мин Антуан де Сент-Экзюпериның «Маленький принц»ын өч тапкыр укып чыкканмындыр. Укыган саен яңадан, икенче яктан ачыла. Шуңа күрә классикларны кабат-кабат та укыгыз. Укырга киңәш иткән китаплар исемлегем менә шундыйрак:

1. Михаил Булгаков, «Мастер и Маргарита». Һәркем укырга тиешле китап дип уйлыйм.
2. Александр Грибоедов, «Горе от ума». Бик җиңел укыла, һәм хәзер дә актуаль.
3. Фаина Раневская, «Фаина Раневская. Смех сквозь слёзы». Актриса тормышы турында. Бик ошады.
4. Оскар Уайльд, «Портрет Дориана Грея». Өч тапкыр укып чыктым, гел яңа яктан ачыла.
5. Шарлотта Бронте, «Джейн Эйр». Бигрәк тә сериаллар карарга яратучыларга укырга киңәш итәм, кино караган кебек укыла.
6. Пауло Коэльо, «Вероника решает умереть». Көч өсти торган китап. Тормышның кайчан өзеләсен белмибез, һәр мизгелнең кадерен белергә кирәк.
7. Зөлфәт Хәким, «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар» романы. Зөлфәт абыйның теле бик ошый, фәлсәфи фикерләре, уйланулары. Аның афоризмнарын да укырга киңәш итәм.
8. Яраткан шагыйрьләремнең шигырьләрен бик яратып укыйм, классиканы яттан беләм: Хәсән Туфан, Һади Такташ, Әнгам Атнабаев, Ләис Зөлкарнәй, Александр Пушкин, Михаил Лермонтов, Владимир Маяковский, Марина Цветаева, Анна Ахматова. Хәзерге шагыйрьләрдән Йолдыз Миңнуллина, Ренат Галиәскәр шигырьләренә мөкиббәнмен.
9. Туфан Миңнуллин пьесалары. Татар әдәби телен өйрәнергә теләүчеләр өчен киңәш итәр идем.
10. Психология белән бәйле китапларны укырга яратам һәм бөтен кешегә укырга киңәш итәм. Үз-үзеңне, кешелек дөньясын аңларга ярдәм итә.

Гөлназ СӘФӘРОВА, теле-алып баручы, журналист





Кечкенә чагында әни еш кына: «Ирем Абзалов фамилияле булса иде», – дип хыялланган. Моны ул туганнары – Абзаловлар гаиләсендәге кебек, тормышының мул, таза булуын күзаллап, өстәлдә һәрчак ак ипи булуын теләп уйлагандыр.

Алда хыялларының тормышка ашачагын, әкияттәге кебек мәһабәт гәүдәле, чибәр, укымышлы Абзалов Фәритне очратып, аңа кияүгә чыгасын ул вакытта әле үзе дә белми, билгеле. Фәрите Кайбыч районы Кошман авылында 1932 елның 18 декабрендә дөньяга килә. Әтисе Абзалетдин – авыл Сабантуйлары батыры, бик тырыш кеше була. Бөек Ватан сугышына кадәр үз тегермәнендә авылдашларына ашлык тарттыра. Әнисе Вәсимә – тирә-якта атаклы аш-су остасы, авылдагы мәҗлесләр аның ризыкларыннан башка узмый.

Сугыш башлангач, Фәритнең әтисе, миллионлаган ватандашлары кебек, илен саклар өчен яу кырына чыгып китә. Гаиләдә олы малай булган Фәрит ике сеңлесе белән ике энесен карашуда әнисенең төп терәгенә әйләнә. Нәкъ шуңа күрә дә инде ул 4 нче класстан мәктәпне ташларга мәҗбүр була.

Тормышында изге җанлы, үз язмышына битараф булмаган кешеләрне күп очрата Фәрит. Шуларның берсе – башлангыч сыйныф укытучысы, әнисе янына килеп: «Фәрит сәләтле бала, аңа укуын дәвам итәргә кирәк», – ди.

Тагын берсе – рус теле укытучысы. Ул чорда сигезенче сыйныфтан унынчыга кадәр имтиханнар түләүле. Сигезенче, тугызынчы сыйныф имтиханнары өчен түләсәләр дә, соңгысы – унынчы сыйныф имтиханы өчен гаиләнең түләрлек акчасы булмый. Кайдан булсын?! Сугыштан авырып кайткан әтиләре озак яши алмый, дөнья куя... Әнә шул авыр вакытта рус теле укытучысы эчкерсез ярдәм кулы суза аларга.

Кулына аттестат алуга, район юлламасы белән Кайбыч районы Бәрлебаш авылы мәктәбенә математика укытучысы булып урнаша Фәрит. Ике еллап эшләгәч, армия сафларына чакырыла. Армиядән соң Казан педагогика институтын тәмамлый, Кайбычта математика укыта. Җаваплы, белемле егетне районда тиз күреп алалар һәм күрше Чәчкаб авылы мәктәбенә башта – завуч, аннан соң директор итеп куялар. Кайсы мәктәптә генә эшләсә дә, аз сүзле, тирән белемле, кешелекле Фәрит Абзал улын барысы да ихтирам итә. Дәресләрендә шук малайларны тыңлатырга бер күз карашы да җитә аның.

1957 елның җәендә Казан дәүләт университетын тәмамлап, Кайбыч район газетасына эшкә килгән Сарман кызы Нәсимәне очрата. Бер күрүдә гашыйк булу дияргә мөмкиндер моны. Шушы очрашудан соң, кызны күрмичә тора алмый инде Фәрит. Авыл арасындагы чакрымнар да куркытмый аны. Мәхәббәт утында янган яшьләр бер елдан соң гөрләтеп туй уздыралар.

1962 елда Кайбыч районы таркала, соңрак Чәчкаб авылы мәктәбе дә ябыла. Фәритне ерактагы Борындык авылына математика укытучысы итеп билгелиләр, Нәсимә исә иренең туган авылы Кошман мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты, тарих фәннәре укытучысы булып эшли башлый. Ике ара ерак булганга, алар атнага бер генә күрешә. Бакча тутырып үскән чәчәкләргә карап кадерлесен юксына Нәсимә:

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар,
Өзеп бирер кешең булмаса?
Нәрсә соң ул күктә янган кояш,
Үз кояшың балкып тормаса...

Соңрак аның бу шигыре, җырга әверелеп, халык күңелен яулый.

Әти белән әни арасындагы олы хис әнинең соңгы көннәренә хәтле сүнмәде. Әниебез 2020 елның 27 февралендә яныбыздан мәңгелеккә китте.

Аның өчен әтиебез гомер буе бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булды. Фәритен һәр күзәнәге белән яратты кебек ул:

Син булганда юлларыма бәхет ява,
Кояш батмый,
нурланып гел күктә яна.
Кыш көне дә җир өстенә чәчәк ява,
Хыялым ул,
миннән калмый, бергә бара.

Әтиебез Абзалов Фәрит Абзал улына 18 декабрьдә, Аллаһ бирсә,

90 яшь тула. Ул гомер буе эшчән, тырыш, гадел, белемгә омтылучан булды. Яшь чагында фотога төшерү белән мавыккан, шуңа гаиләбезнең төрле чорын чагылдырган фотосурәтләр күп альбомыбызда. Районда беренче автомобильне дә эти ала. Хуҗалыкта ат, сыер, куян, нутриялар асрады, күп еллар умарта кортлары белән шөгыльләнде. Лаеклы ялга да бары 79 яшендә генә чыкты ул. Хезмәтенең җимешләре – үзе укыткан укучылары. Күбесе остазлары эзеннән атлап, хәзерге көндә Апас, Кайбыч мәктәпләрендә укыта.

Лаеклы ялда да эти кул кушырып утырмый: кыш көне чаңгыда шуа, күп еллар район бассейнына йөреп, ярышларда катнашты. Шахмат-шашка ярышларын да калдырмый. Әтиебезне киләчәк юбилее белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Ул – чын мәгънәсендә гаиләбезнең башлыгы, безгә үрнәк, безнең горурлык.

Гөлфия АБЗАЛОВА.
Кайбыч районы, Кошман авылы.

Берничә ел элек фатирыбызга ремонт ясарга уйладык. Белдерүләр аша табып, телефоннан бер белгеч чакырдык. Безнең белән рус телендә сөйләшсә дә, бусагадан кергәндә «Әссәламегаләйкем» дип, мөселманча исәнләште ул.

Фатирдагы башкарасы эшләрне карап чыккач, җиң сызганып эшкә дә тотынды. Ара-тирә аның «иншаллаһ» дип әйтеп куюын ишетеп тордык. Төшке ашка туктагач, өйлә намазын укып алды. Рус милләтеннән булган бу егетнең ислам динен тотуы, гыйбадәтләрне үз вакытында җиренә җиткереп үтәп баруы бездә кызыксыну уятты. Сөйләшеп киттек. Аның сөйләгәне гыйбрәтле иде...

Армиядә хезмәт иткәндә Әфган сугышына җибәрәләр аны. Шунда әсирлеккә эләгә. Яшь булса да, ачы язмышына аек акыл белән карап, үзенә төшкән авырлыкларны кабул итә ул. Үз-үзен эш белән юата. Тырышлыгын әфган хәрбиләре дә күреп ала. Алар янында яшәп, ислам динен кабул итә егет. Берничә елдан аны совет гаскәрләре килеп коткара. Әсирлектән котылгач та, ислам диненнән ваз кичми – намазларын укый, уразасын тота. Христиан динендәге туганнары аның ислам диненә күчүен башта кабул итә алмый. Тора-бара күнегәләр үзе. Бераздан егет рус кызы белән танышып, өйләнергә ният итә. Ләкин кәләшенә бер шарт куя – ул да ислам динен кабул итәргә тиеш. Мәчеттә никах укытып, ислам кануннарын үтәп яши башлыйлар.

Кызганыч, бу егетнең исеме инде хәтердә калмаган. Телефонын да саклап кала белмәгәнбез. Татар егет-кызлары ислам диненнән читләшкәндә, рус егетенең чын мөселманча яшәве сокланырлык бит, минемчә.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ,
сугыш һәм хезмәт ветераны.
Казан шәһәре.

Телефонымны карап утырганда фотолар килеп чыкты. Былтыргы фотолар. Бәрәңге алып бетергәч – әллә балачакка кайтып киләсе килде, әллә аппетит уянды шунда – учакта тәгәрәтеп бәрәңге пешергән идек. Шул фотоларны күрдем дә, учакта пешкән бәрәңге ашыйсы килеп китте.

Без үскәндә зур-зур бакчаларга бәрәңге утырталар иде. Абзар тулы мал-туар, тавык-чебеш – аларны да ашатасы бар. Җәйли үзенә игътибар, кул көче таләп иткән бәрәңге бакчасында хезмәт һәркемгә җитәрлек иде. Ә менә хезмәтеңнең җимешен тату – җан рәхәте. Сабакларын чабып, бакчаны бер-ике көн җилләткәннән соң, бакча умарта күче кебек гөжләп торыр иде. Күрше-тирә – олысы-кечесе, баласы-чагасы, җыйнаулашып, бәрәңге ала. Әти белән әни буразна казый, энем белән мин алар артыннан бәрәңгеләрне көшелләргә өеп барабыз. Ул арада әйткәләшергә, бәрәңге белән атышып, бер-беребезне елатырга да өлгерәбез әле. «Бүгенгә җитәр!» – монысы әти тавышы. «Көшелләр җилли торсын, әйдәгез, ашап-эчеп чыгыйк». Шулай ягымлы итеп әни дәшә.

Иң сөенечле көн – бәрәңге алып бетергән көн! Бөтен күрше-тирә, җыелышып, учакта бәрәңге пешерә. Бәрәңге пешкән арада, һәркем чиләгенә утырып, бер түгәрәк ясап, гәп куерта. Дөнья хәлләре, быелгы уңыш турында сөйләшү, Ходайга рәхмәт уку... Аннан җиргә бер җәймә җәеп куялар. Күз ачып йомганчы ул җәймә ризык белән тула. Ипи, коймагы, пәрәмәч-өчпочмагы, тозлы кыяр-помидоры, тозлы кәбестәсе, өч литрлы банкага җиләк-җимешләр салып ясалган кайнар чәе дисеңме – һәрберсе шул җәймә өстенә «кунаклый». Ару-талулар шундук эреп юкка чыга.

Учакта кетердәп пешкән бәрәңгене кабыгы белән ашауның ләззәтен авыл баласы гына белә. Кулны пешерә-пешерә, шырпы кабына салынган тозга мана-мана, тозлы кыяр кетердәтеп ашаганда рәхәт чигүләр... Онытырлыкмы соң?! Ә тоз салынган шырпы кабы һәрчак кесәдә йөри, әллә каян эзләп йөрисе дә юк. Авыз-куллар кара күмергә буялып бетә.

Эти үләсе елны да күршеләр белән җыелышып шулай учакта бәрәңге пешереп утырганыбыз хәтеремдә. 2006 елның көзе иде. Җыйнаулашып утырулар, күршеләр белән аралашулар сирәгәеп бара иде инде ул чакларда. Эти барыбызны да бакчага – бер табынга җыйды. Ике айдан үзе китеп барды.

...Бәрәңгене этидән соң да пешердек без. Тик... Тәме башка. Эти-әни, күршеләр янәшәсендә генә тәмле булган икән ул!

Эти дә юк бүген... Әни дә бик еракта... Балачак эзләре калган туган нигез бакчасында күптәннән бәрәңге үсми... Сәлам бирим дисәң, күршеләрнең дә күбесе бакыйлыкка күчте инде. Эти-әниле балачак елларында учакта тәгәрәп пешкән бәрәңге тәме генә һич онытылмый...

Гүзәл ХӘБИБУЛЛИНА.
Балык Бистәсе районы,
Корноухово авылы
Мәдәният йорты мөдире.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

– Мин алар белән һәрвакыт сөйләшеп йөрим. Сизәм: алар минем янәшәмдә. Уңышларыма шатланалар, хәвеф-хәтәрдән саклыйлар... Татарстанның халык артисты Нәфкать НИГЪМӘТУЛЛИНны моңлы, җырларын тыңлаганда елата торган җырчы, диләр. Җырлары моң, сагыш, сагыну, сыктау белән уралып, йөрәк түреннән чыкканга шулайдыр... Ул бит гомере буе сагынып яши... Барысы хакында да үзе ачыктан-ачык сөйләсен әле.



Фото: Анна Арахамия

Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

«МОҢ

Июльнең матур бер көне. Миңа 9 яшь. Әни мине чакырып алды да: «Чибәр әбиләреңә карагат җыярга бара, син дә ияр әле», – дип, җиде литрлы чиләк тоттырды. Безнең бакчада да үсә иде ул карлыган, күрәсең, без, бала-чага өлгергәнче ашап бетергәнбездер. Ә әнинең, безне ашатасы килгәндер, бәлки, авыз тәме өчен карлыган кайнатмасын үзенең кабасы килгәндер. Ул бит инде авырый иде... Авыл халкы карлыган җыярга йөргән урын җиде чакрым ераклыкта. Анда барганымны, чиләкне тутырганымны хәтерлим. Әмма аны шул озын юл буена күтәреп алып кайта алмаганмындыр, мөгаен. Чибәр әби булышкандыр. Мин мөлдерәмә тулы чиләгемне күтәреп кайтып кергәндә, әни хәле бетеп өйдә утыра иде. Шуннан соң озак тормады, август аенда өзелде. Әниле балачакның иң соңгы хатирәсе әнә шул карлыган белән бәйле минем. Ә аңа кадәр бик рәхәт, күңелле яшәдек без. Сигез бала. Мин – җиденчесе. Әти дә, әни дә – Тимергали белән Хәтирә – икесе бер авылдан. Янаул районында Уракай дигән бик матур авыл ул. Әти безнең балта остасы иде. Авылда ир-атлар белән артель төзеп, төрле җиргә төзелешкә чыгып китә. Әни сугыш вакытында бригадир булган. Әтигә кияүгә чыккач, төрле эшкә йөрде. Без үсә төшкәндә зур абый, апа чыгып киткәннәр иде инде. Бер апабыз кечкенә чагында үлгән. Әнинең беренче ярдәмчесе булган Нәзхәт абый мине – күкрәк баласын караган. «Нәфкатькә бер яшь тулгач кына урамга уйнарга чыгам», – дип әйтә торган булган. Гармунда уйнаган. Әмма гомере кыска була. Җылысын тойган якын кешем әнә шулай мине калдырып китә. Без дүрт малай үстек: Физанур абый, Мизхәт абый, мин һәм Фирин энем. Өйдә һәрберебезгә эш бүленгән. Мин гел хатын-кыз эше эшләдем. Урын җыештыру, идән юу – барысы да минем өстә, һәм аларны бик оста башкарам. Әни тегә, чигә, бәйли. Һәркемнең дә әнисе чиста-пөхтәдер инде, әмма минем әни аеруча пөхтә иде. Ак күлмәкләр генә киертеп йөртте ул безне. Ә без абый-энеләр белән балачакның рәхәтен күрәбез. Мизхәт абый белән энекәш тә гармунда уйный. Ул чорда гармун илаһи бер уен коралы бит. Гармун уйнаган кешегә хөрмәт шундый зур, сокланып карыйлар. Ә безнең өйдә гармун тавышы тынып тормый. Хәтта уйнаганда да гармун безнең белән була. Кичләрен дүрт малай җыелышабыз да, бер-беребезне армиягә озатышлы уйныйбыз. Дүртәүләп кочаклашабыз да кычкырып җырлыйбыз. Кышкы кичләрдә өй яңгырап тора иде. Безне тирә-як күршеләр дә ишеткәндер, мөгаен. Авылда малайларның урам буйлап җырлап йөрү гадәте дә бар иде. Мизхәт абый гармунда уйный. «Апай, синең тавыш барысыныкыннан да ныграк яңгырап тора. Көчле булып чыга», – дия иде. Әткәй белән әнкәй, туганнарым исән вакыттагы иң җылы хатирәләрем бу. Бик еш искә төшә ул чаклар... Еш...

ЧИШМӘЛӘРЕМ СЕЗ...»

Ул бәхетемә озын гомерле булырга язмаган. Озак кына авыртып йөргәннән соң әни безне ташлап китте шул. Абыйны тапкач, бик нык салкын тидергән икән ул. Юньләп дәваланмаган, күрәсең. Туберкулез яман шешкә әйләнгән. Хастаханәдә тиешенчә дәваланса, бәлки, терелгән дә булыр иде. Ул дәваланырга кереп ята, әти энем белән мине ияртеп хәлен белергә бара. Әни безне күргәч елый. Ике көннән соң кайтып та җитә. Сагынган инде ул безне. Әни белән бик якын идек шул. Үскәч табиб булам да, әнине дәвалыйм дип хыяллана идем. Бөтен теләгем әнине терелтү булды. Әмма... Әни үлгән көнне әле дә хәтерлим. Кичен апаларга кунарга алып киттеләр безне. Икенче көнне уянуга – ә без бик иртә уяна идек – әнинең хәле ничек икән дип уйлап куйдым. «Әниең үлде», – дигәч, шундук өйгә чыгып чаптым. Кайтып кергәндә әнине юып бетергәннәр иде инде. Үлгәненә ышанмадым. Йоклый гына кебек тоелды. Әмма әнине зиратка алып киттеләр. Бик каты елаганым әле дә хәтеремнән китми. Югыйсә 51 ел узган бит инде! Мин елыйм, миннән катырак Мизхәт абый елый... Халык таралып беткәч тә зиратта әни кабере янында басып калды ул. Әнине җирләп кайтканда коеп яңгыр ява иде... «Авылның иң акыллы, затлы хатыны китте», – диде авылдашлар...

Әнине бик нык сагына идек. Суга гына киткәндер, менә-менә кайтып керер төсле. Безгә әни җылысы бик кирәк чак бит әле. Хәер, әни җылысы кешегә гомере буе кирәк икән ул... Бик авыр булса да, елап ятып булмый. Тормыш дәвам итә. Безне ашатырга, аякка бастырырга кирәк. Әти эштә. Алагаем зур хуҗалык безнең өстә. Дуңгыз белән атка кадәр бар! Безгә Чибәр әби килеп йөрде. Чәйләр куеп, ашатып, мәктәпкә озата. Физанур абый район үзәгенә тугызынчы класска укырга китте. Мизхәт абый белән икәүләп хуҗалык эшләрен алып бардык. Мәктәпкә киткәнче ул тирес чыгара, ашарга сала, ә минем өстә бәрәңге төю, су бирү. Мизхәт абый баһадир гәүдәле бик елгыр малай иде. «Мин үлеп китсәм, апайларыңны саклап кара», – ди торган иде әни аңа. Мәктәптә тәнәфес вакытында минем янга класска керә дә, җайлап кына: «Апай, ничек хәлләрең? Мин өйдә менә шушы эшләрне эшләп куйдым, син, апай, шуларны эшләп куй, яме», – дип әйтә иде.

Әни үлеп бер ел узгач, әти күрше авылдан бер апаны алып кайтты. Җәмилә исемле иде ул. Кошчылык фермасында эшләгән. КПССның XXIV съезды делегаты! Без аны шундук якын иттек. Килүгә үк «әни» дип эндәштек. Килгәннең икенче көнендә ул мине: «Бәбәем, тор», – дип уятты. Үзенең балалары булмаса да, безне яратты ул. Йокыдан үбеп уята иде кайвакытта. Энекәшне аеруча яратты. Энекәш баянда уйный, ул җырлый. Икесе җырлашып утыралар иде шулай. Ул безнең белән өч кенә ел яшәде. Яман шеш авыруы белән авырый башлагач, туганнары алып китте. Әнинең туганнары безне якын итте. Күрше авылга укырга йөргәндә, аның бертуган сеңлесендә яшәгән идем әле. Хәзер дә аралашып торабыз. Җәмилә апаны да югалту безнең сабый күңелебезгә тагын бер яра салды. Әмма яралар моның белән генә бетәсе булмаган икән... Җәмилә апа үлгән вакытта 16 яшьлек Мизхәт абыйны югалттык. Бигрәк көтелмәгән үлем булды. Авылның беренче егете иде бит ул! Бик туган җанлы иде Мизхәт абый, мине «тәти энем» дип кенә йөртте. Әнине югалтуны күтәрә алмагандыр инде. Төнлә дә каберенә барып йөргән булган. Әнине ул ныграк яратты микән, әни аны микән... Аңлата да алмыйм. Сагынуына түзә алмагандыр, мөгаен. Әни белән янәшә җирләделәр. Абыйны югалтуны бик авыр кичердем. Энем белән абый арасында үскән бала бит мин. Кабер өсләренә ятып елый идем. «Абыйсын сагынып, чирләп китә күрмәсен бу бала», – дип борчылган ул вакытта авыл халкы. Әйе, гомерем буе аны сагынып яшәдем мин. Төшләремә бик еш керде ул... Әмма өлешемә төшкән бәхетсезлек моның белән генә бетмәгән икән әле...

Җиденче сыйныфны укырга әти мине Уфага ятим балалар өчен интернат-мәктәпкә алып китте. Нигә мине генә илткәндер әти, белмим. Энекәш бит өйдә калды. Газиз баласын чит җирләрдә калдырганда бик елады әти. Интернатка урнашкач, янындагы бакчага кердек тә, өйдән пешереп җибәргән тавыкны ашарга утырдык. Әти дә ашый алмый, мин дә. Ул да елый, мин дә елыйм. Бик сагына идем анда укыган чакта. Бигрәк тә, энекәшне... Сагынуга чыдар сабырлыгым калмаган чакларым да булды. Шуңа да тормыш юлымны Уфа белән бәйлисем килмәгәндер. Уфа минем өчен сагыш каласы ул. Интернатта укыган чакта шулай күңелемә кереп утырган инде. Аннан соң Уфадан авылга кайтып йөрү дә бик авыр. Билетны ике атна алдан алып куясы. Җәфа-интегүләр үз эзен салмый калмый шул...

Җәмилә апа бездән китеп ике ел узгач, мин интернатта укыганда әти тагын бер апа алып кайтты. Гаифә әни белән бергә 37 ел бик матур яшәделәр. Аңа да килүгә үк «әни» дип эндәштек. Әткәйгә иптәш кирәк дип кабул иттек без аны. 95 яшенә кадәр яшәде әни. Вафат булганына әле ике ел гына. Гаифә әни бик әйбәт булды. Ашарга пешерде, юды, чистартты. Яратты ул безне. Малайларга бер үпкәм юк, дип, риза-бәхил булып китте. Беркайчан да урамга чыгып гайбәтебезне чәчеп йөрмәде. Кайбер үги әниләр гаеп итеп сөйләүчән була, ул сөйләмәде.

Интернатта ике ел укыганнан соң, Янаулга кайтып, мәктәпне тәмамладым. Янаул авылга якынрак бит. Еш кайтырга да була. Апа да, кияүгә чыгып, район үзәгендә яши иде. Аларга да барып йөрдем. Аннан соң Казанга килдем. Ерак булса да, бару җиңелрәк – поезд юлы бар.

Минем язмышым да моңыма тәэсир итми калмагандыр. Җыр белән юанамдыр шулай.

Казан Казан инде ул! Балачактан ук татар әдәбияты укып үскән кешеләр бит без. Ике туган абый да монда укый иде. Әни үлгәч, табиб булам дигән хыялым юкка чыкты. Минем өчен табиб булуның мәгънәсе калмагандыр инде. КХТИга нефтянойда укыйм дип килдем, әмма элемтә техникумына укырга кердем. Шуннан армиягә киттем. Иң зур абыем Галинур мин армиядә вакытта фаҗигале төстә үлде. Абый өйдән иртә чыгып киткән иде, читтә укып, читтә яшәде. Армиядә вакытта аның белән хатлар алыштым. Айга ике тапкыр 25 сум акча сала иде. Ул вакытта зур акчалар инде. «Нәфкать, син армиядән кайткач, Сочига ял итәргә барырбыз», – дип язган иде бер хатында... Абыйны югалту кайгысы суынырга да өлгермәде, «энекәшең авыр хәлдә» дигән телеграмма килеп төште. Минем яраткан энекәшем Фирин! 18 яшендә! Янаулдан авылга кайтканда мотоциклында әйләнгән. Бәреп киткәннәрдер инде аны дип уйлыйм. Биш көн һушсыз ятты да, мин кайтып җитеп өч сәгать узгач, җан бирде. Көткән инде, хушлашмый китмәгән... Минем энем бит ул! Балачакта, кунакка баргач, безгә җырларга кушалар иде. Мич артына кереп китә идек тә: «Әйдә, син башла, әйдә, син», – дип, төрткәләшеп алгач, икәүләп җырлап җибәрә идек. Яңгыратып җырлыйбыз. Тик үсә төшкәч җырлаудан туктады, гел баянда уйнап йөрде. Бик матур, бәрхет тавышлы, бар яктан булган чибәр егет иде ул. Гомумән, бар ир туганнарым да чибәр, баһадир гәүдәле иде минем. Алар арасында иң кечкенә гәүдәлесе, иң ямьсезе – мин. «Абыйларың да матур, энекәшең дә матур, нишләп син генә ямьсез соң?» – ди торганнар иде. Үпкәләми идем. Чынлап та, бик матурлар, барысы да җырлый иде. Әни ягыннан бөтенесе дә гармунчылар, җырчылар иде шул.

Армиядән кайткач, кабат Казанга чыгып киттем. Әти елап калды. Авылга кайтып яшәрмен, иң яхшысы шул булыр, дип, авыл хуҗалыгы институтына читтән торып укырга кердем. Әмма авылга кайтмадым инде. Үзешчән ансамбльләрдә җырлап йөри башладым. Авыл хуҗалыгы буенча фәнни институтта эшләгәндә басуда җырлый торган идем. Шулай җырлап сагыш-сагынуларымны чыгарганмындыр инде, күрәсең. «Тавышың матур, җырчы булырга кирәк сиңа», – диләр иде миңа. Рифкать абый Закиров Марс Макаров белән таныштырды. Ул баян белән җырлатып карагач: «Материал бар синең, энекәш», – диде. Институтны тәмамлагач, музыка училищесының көндезге бүлегенә укырга кердем. «Син җырчы булырга тиеш, басуда йөрергә кирәкми», – дип, эштән җибәрә торганнар иде. Шуннан җыр белән хыялландым инде. Училищены тәмамлагач, үз тавышымны таптым. Аңа кадәр Илһам Шакиров, Фидан Гафаров, Газинур Фарукшиннарга охшатып җырлыйм. Бик күп ансамбльләрдә солист булып йөрдем. Әнә шулай тамашачыларга танылу, ярату килде. Инде менә 30 ел буе популяр булып тору зур казанyштыр инде ул.

Моң тумыштан булгандыр миндә. Махсус моңланып җырлап утырып булмый. Әни турындагы җырлар бигрәк тә йөрәктән чыга инде ул. Ә җыр йөрәктән чыкса гына тамашачы күңеленә барып җитә. Әлфия апалар, Илһам абыйлар авырлык күреп үскәннәр, шуңа да драматизм көчле аларда. Халыкны җырларың белән елата аласың икән, ул инде нәрсәдер аңлата. Минем язмышым да моңыма тәэсир итми калмагандыр. Җыр белән юанамдыр шулай. Тормышым тоташ югалтулардан гына торды дисәм дә, ялгыш булмас. Иң соңгы җирләгән якын кешем – әти. 87 яшендә үлде ул. Әле үз аягы белән район үзәкләренә барып йөри иде. Ул көнне, шалтыратышып, хәлләрне белештек. Озак та үтми, абый шалтыратып: «Әти китте», – диде. Юынып кергән, киемнәрен алыштырган, ашап утырган җиреннән хәлем китте, дип, урынына барып яткан да, җан да биргән. Концертым барганда тәнәфес вакытында ишеттем кайгылы хәбәрне. Концертны эшләп бетердем. Артист язмышы шул инде. Тамашачыга синең тормышыңдагы кайгыны белү нигә кирәк?! Син җырларга тиеш һәм нокта.

Мин нечкә күңелле. Күңел тиз тула. Кеше күрмәгәндә елап та алам. Үткәннәр искә төшә. Балачагымдагы иң якын кешеләрем, бер табактан ашап үскән туганнарым әнә шулай бер-бер артлы китеп барды. Хәзер өчәү генә калдык: апа, абый һәм мин. Үземне бәхетсез кеше дип әйтә алмыйм. Нindидер теләкләрем дә чынга ашты. Әмма янымда братларым юк. Менә шул үзәкне өзә. Сагынган саен авылыма кайтам. Поездга утырам да – туп-туры Янаулга. Төп нигезебезгә ремонт ясадым, карап торам. Анда беркем яшәми, үткәндә-сүткәндә концерт төркемебез белән тукталып, ял итәбез, әйткәнемчә, ялгызым да кайтып киләм. Туган нигез тарта шул. Ул бит әти, әни, абый-энекәшләр нигезе. Өйдә һаман аларның тавышлары яңгырап тора сыман. Туган нигезен ташлаган кешеләрне аңламыйм мин... Ничек ташламак кирәк?! Ничек аны чит кеше кулына тапшырмак кирәк?! Әти дә васыять итеп: «Улым, йортны ташлама», – диде. Ялгызым гына кайткан чакларымда бик моңсу. Әмма, нишләтәсең, бары шунда күңел тартып тора. Зиратта әти белән әни, дүрт туганым ята бит. Һәрберсенең каберен тәртипләп торам, берсенекен дә онытмыйм. Кеше тормышында ни генә күрсә дә, нәрсәләргә генә ирешсә дә, балачак хатирәләрен сызып ата алмый. Балачак һәрберебезне озатып йөри ул. Соңгы сулышкача. Минем белән килешерсез: нindидер вакыйгалар онытылырга мөмкин, әмма балачак онытылмый. Чөнки ул кешенең иң самими тәүге ядкарьләре.

Туганнарым белән әле дә сөйләшеп йөрим. Авыр вакытларымда ярдәм итегез дисәм, булышмый калмыйлар. Вакытында төшкә кереп, кисәтеп торалар. Бер тапкыр газ плитәсенә чәйнек куйган килеш йоклап киткәнмен. Әти шунда төшкә керде: «Тор!» – ди. Уянып китсәм, чәйнек эри башлаган. Менә алар минем белән түгел дип, ничек әйтәсең инде...

ТАТМЕДИА

ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН КАР КӨРИ ТОРГАН ҖАЙЛАНМА, ТЕЛЕВИЗОР ҺӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР

Бүләкләр 2023 елның 9 февралендә уйнатылачак



1 ЯЗЫЛ

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 21 гыйнварга кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

телевизор, электр иттарткыч, электрогриль һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – кар көри торган җайланма!



Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 2022 елның 22 октябреннән 2023 елның 20 мартына кадәр уздырыла.
Реклама. Яшь чикләве – 16+

«ТӨШЛӘРЕМДӘ АК КҮЛМӘКТӘН СИН...»



Фото: Анна Арахамия

– Бер ай буе эчем янды. «Ай буе Илнарны гына сөйләп тордың син», – диде соңыннан эштәге кызлар. Кая барган, нишләгән, кайчан кайткан, кем белән кайткан, нәрсә дип әйткән – телемдә улым гына булган… Ә мин әнә шул эчтәге ялкынны гына хәтерлим. Хатын-кызларның олыгаю яшенә хас үзгәрешләр башланамы әллә, нигә бу кадәр янам соң, дип аптырап йөрдем. Илнарга булган икән…



Алсу ШАКИРОВА

Юлларың ипсез булмасын, дип теләде дәү әнисе һәрвакыт. Аның да күңеле сизгәнме әллә?

3 декабрь. Елның соңгы аен ваклап, дөнья акка төренгән кышкы кич... Төнге сәгать унбер җитеп килә. Апас районы Карабай авылының бер йортында утларны сүндереп, йокларга ятарга әзерләнәләр. Өйдәге тынлыкны бозып, ире Иршатның телефоны шалтырагач ук, Наилә апаның күңеле әллә нишләп куя... Төнлә җүнле хәбәр белән шалтыратмыйлар... Кем икән? Трубкада яңгыраган таныш булмаган тавыш тагын шом өсти.

– «Шевроле круз» машинасында йөри торган малаегыз бармы? – дип сорыйлар Иршат абыйдан.

– Әйе.

– Хәзер кайда ул? – дип соравын дәвам итә кырыс тавыш.

– Казанда...

«Нишләп Казанда булсын инде, Тәтешкә кайтып киләбез диде бит Илнар, онытканмы әллә әтисе?» – дип, Наилә апа аптырашка кала.

– Авария булган, килегез...

Өс-башларына нәрсә туры килә, шуны киеп, кайнанасы Галиябану апага берни әйтмичә өйдән атылып чыгып китәләр. Илнар авариягә юлыккан дигән хәбәрне олы кешенең йөрәге ничек күтәрер? Барысы да артта калды, борчылырлык урын юк дип, кайткач кына әйтерләр әле... Илнарны авылда кечкенәдән Галия малае дип йөриләр бит. Шулкадәр охшаганнар. Дәү әнисе кулында үскән малай шул. Кайтып керүгә: «Дәү әни, кайттым», – дип күрешә, киткәндә дә озатып калуын көтә. «Илнарым» дип кенә тора үзе дә. «Гел юлда йөрисең, улым. Юлларың ипсез булмасын, бу кадәр дә тәүфыйклы малайсың, озын гомерле бул инде, берүк бәрелүләрдән сакласын Аллам», – дип тели һәрвакыт. Аның да күңеле сизгәнме әллә?

Инде болай да тормышта күп авырлыклар күргән Галиябану әниләрен борчымыйча гына барып кайтырга кузгалалар.

Апас чиген борылгач, Югары Ослан ягына килергә куша ГАИ хезмәткәрләре. Бик озын юл була ул. Бер ел барган кебек тоела Наилә апага. Бер авыз сүз дәшмичә баралар... Бары тик караңгыда кышкы юлны ярып барган ут яктысыннан да тизрәк ашкынган күңел генә әллә кайларга алып китә, башка мең төрле уй кертә.

...Бүген сменадан гына чыкты шул әле Илнар. Казанның икмәк заводында сменасы тәмамлангач, сөйгәне Гөлфия белән Тәтешкә, Гөлфиянең сеңлесенең туган көненә кайтып килергә уйладык дип шалтыраткан иде. Дәү әнисенең: «Юлга чыкканчы бер-ике сәгать булса да ял ит», – дип әйтүенә колак салмый калмагандыр. Төнгә каршы юлга чыгуын хупламаса да: «Чәчәк тә, торт та алыгыз, улым», – дип, үз кинәшләрен бирә Наилә апа. «Беләбез инде, әни», – дип елмая Илнар. Гел авызы ерык инде аның! «Котлыйбыз да, кире китәм, Гөлфия авылда кала, миңа иртәгә эшкә бит», – дип, әнисен тынычландырып куйган иде.

...Теге борылышка килеп җиткән мизгелне төш кебек кенә хәтерли Наилә апа. Ашыгыч ярдәм машинасы да юк... Инде китеп барганмы? ГАИ хезмәткәрләре, салкында туңып, машиналарына кереп утырганнар. Ә юл кырында... өстенә каплаган... уллары ята. Көчсез ыңгырашу сыман: «Безнеке ич...» – дигән сүзләр ананың үзәгеннән үк бәреп чыга... Язмышның иң авыр сынавына – бала хәсрәтенә юлыккан ата-ана, кочаклашып, күз яшьләренә буылып елыйлар...

«ГАЗель» машинасы белән бәрелешү Илнар ягына туры килә. Дамба астына очканда янәшәсендә утырган Гөлфиянең куркынычсызлык мендәре ачыла, кыз исән кала. Ашыгыч ярдәм машинасы белән аны Буага алып китәләр. Илнарныкы ачылмый... Шунда ук җан бирә егет... Үз-үзен белештермәс хәлгә җиткән ана, апасына шалтыратып, «Илнар юк бит инде», дип хәбәр итүләрен дә, улын моргка алып киткәннәрен дә, машинаны эвакуатор төягәнен дә, машинаның арткы утыргычында таралып яткан туган көн бүләкләрен – тортны, чәчәкләрне дә соңыннан төш күргән кебек кенә исенә төшерә...

«Машинаң белән Ставрополь шәһәренә кадәр барып исән-имин кайттың, Казаннан кайтып җитә алмадың... Менә шушы ничә тапкырлар узган Казан–Апас юлында 22 яшеңдә гомерең өзеләсен кем уйлаган?! Ашыгып йөри торган малай да түгел идең. Көпчәкләрең кышкыга алыштырмаган булган шул... И улым, улым...» – дип өзгәләнә ана йөрәге, улы белән сөйләшә. Гомере беткәнгә бер сәбәп, диләр... Гөлфиягә бүләккә алган алтын чылбырын бирергә дә өлгермәгән...

Икенче көнне егетне соңгы юлга озатырга килгән халыкны күреп, гомер иткән Галиябану апа да шакката. Авыл халкы, күрше авыллар, дуслар, туган-тумача гына түгел, Илнарның эшендәге хезмәттәшләре, яшәгән фатир хуҗасына кадәр кайта бит!

Аннары Илнарсыз тормыш башлана... Кайтып-кайтып уйлаулар, тегеләй булса, болай булса дип сынап караулар, үкенечләр. Илнарның сөйгәне Гөлфиянең әти-әнисенең «без гаепледер» дип өзгәләнүләре... Буранда йөрмәгез дип әйтсәләр дә, сеңелләренең күңелен күрергә теләгән яшьләрне алар да туктата алмый шул. Ата белән ана да: «Нык торасы булган, юлга чыгармаска иде», – дип, гаепне үзләреннән күрә. Гаепле кешене табып та барыбер Илнарны кайтарып булмый. Моргтан биргән нәтиҗәләрне дә, ГАИ язган кәгазьләрне дә укырга кулы бармый Наилә апаның. Сигез ел үткән инде менә, әле дә бер сүзен дә укый алганы юк. Ә күңел гел Илнар белән сөйләшә...

«Ничек яшәргә? Артыңнан ук китеп барсам иде, балам... Үзем генә үлгән булсам иде... Алай ансат кына китеп булмый шу-у-ул. «Бер малай алып кайт, әни, үстерергә үзем булышырмын», – дия идең. Кырыкка җиткәч нинди малай инде, дип кул гына селтәдем, улым, хәтерлисеңме? «Үзегез генә каласыз бит: дәү әни мәңгелек түгел, сеңлем Илүзә дә чыгып китәр», – дип үгетләдең гел. Әле соңгы очрашуыбызда да өмет өзмәдең: «Гөлфияләрне балалар йортыннан алып үстергәннәр әнә. Үзең алып кайтырга курыксаң, кыз-

Үлеп китүе бик тиз икән. Теләгәннәрем кабул була түгелме соң?



Илнар белән төшкән соңгы фотосурәтләре.

лыкка алыгыз», – дигәнең әле дә колакта яңгырап тора, улым. Әйе, Гөлфияләрне – өч бертуганны әтиәнисе алып үстерделәр шул. Менә синең кебек бер матур малай табармын да, китеп барырмын синең яныңа! Шулай булсын иде, улым...»

Ул баланы кем үстерер, ничек үстерер – анысын уйларлык хәлдә булмый Наилә апа. Ул шундый уйлардан арына алмый көн артыннан көн уздырганда Иршат абый бәләкәй адымнар ясап, яшәүгә таба атлый. Хатынын да үзе артыннан ияртә... Үлгән артыннан үлеп булмый, диләр. Әйтүе генә җиңел бит... Үләсең шул, балаң белән үзең дә үләсең икән. Ә яшәргә кирәк. Ире булмаса, белмим, нишләр иде Наилә апа. Әкренләп тормышка кайта башлыйлар. Һәр эшләрен, һәр хәрәкәтләрен «Илнар сөенер иде», дип башлаганнарын үзләре аңладылар микән? Илнар матур булганны ярата иде дип, өйне тышлыйлар, түбәне, мунчаны яңарталар. Ул исән вакытта кул җитмәгән бөтен каралты-кураны матурлап чыгалар шулай. Тиз булсын, матур булсын, әйбәт булсын дип яшәде Илнар!

Фаҗигагә юлыккан машинаны штрафстоянкадан ук сатып җибәрәләр. Ә менә Илнарның үзенә эшләр өчен алган «ГАЗель» машинасын нишләтергә дә белми аптырыйлар. Иршат абый анда эшләргә теләми, техниканы тик торгызу да килешми. Илнар риза булыр иде микән, дип, йөз түгел, мең кат уйлый ата белән ана. Сатып җибәрәләр...

Илнар әнисенең төшенә керә шуннан соң. «Улым, саттык инде машинаңны. Әтиеңнең анда эшлисе килми, нишләтәсең...» – дип борчыла Наилә апа. «Борчылма, әни, монда андый машиналарым әллә ничә минем!» – дип тынычландыра улы. Ә үзе – апак күлмәктән! Төшләренә ак күлмәктән керә Илнар... Бергә төшкән соңгы гаилә фотосурәтендә дә ап-ак күлмәктән басып тора әнә.

Ә теге «тагын бер бала» дигән уй барыбер күңел түренә кереп оялый. Танышлар аша: «Наиләгә тагын бер бала кирәк. Узса, алып кайтсын», – дип киңәшләрен җиткерүче хатын-кызлар табыла. Аның хәлендә калган аналар юк түгел икән... Кемдер, фаҗигадә олы баласын югалтканнан соң, «тагын бер бала алып кайтмадым», дип, гомере буе үкенеп яши, кемдер «ярый әле балабыз туды», дип шөкер итә. Бала... Яшәр өчен бала кирәк...

Бар да алар теләгәнчә генә булмый шул... Илнарсыз килгән беренче җәйдә «уздым, ахрысы» дигән хәбәр артыннан тагын югалтуы да күтәрми. Бөтенләй бәләкәй яралгы хәсрәт тулы йөрәк астында үсеп китә алмый... Сөенергә дә өлгерми калалар. Тагын авыр була...

«Тагын бер узасың әле, теләгең булса, алып кайтасың», – ди табибы. Каян белгән, диген... Ноябрь аенда Илнарның ел ашын уздыралар. Декабрь азагында яңа ел могҗизасы булып гаиләгә яңа хәбәр килеп ирешә. Бала! Аларның тагын бер балалары булачак!

...Кыз көтә Наилә апа. Малай дип өметләнеп, тагын җанны яралыйсы килмәгәнгә микән... Ә Иршат абый өзми дә, куймый да – малай булачак! «Кырыкны узганнарга малай бирмәсләр», – дип, ирен сабыр булырга өнди ул. Кем буласы Ходай кулында. Яшисе килүдән яралган бала булгандыр... Исән-имин тусын иде! Карынында җан кергән нарасый йөрәк яраларына җөй саламы – бу юлы бөтен барлыгы белән яшәүгә таба атлый Наилә апа.

УЗИга Иршат абый белән бергә баралар. Шулкадәр читенсенеп!.. Бөтенесе дә аларга карый кебек. Кайчан да булса бишенче дистәңне ваклаганда бала күтәреп йөриячәксең дип әйткән булсалар, үпкәләр иде әле. Беренче тапкыр әни булырга әзерләнгән яшь кызлар белән бергә 44 яшеңдә УЗИга чират тор әле син! Наилә апа белән Иршат абыйдан да олы кеше булмый ул чиратта.

...Дөньядагы иң тансык шушы сүзләрне ишетүгә Наилә апаның күзенә мөлдеремә яшь тула. «Сезнең улыгыз булачак!» Еламыймы соң инде?! Икәүләп елыйлар. Бу юлы – икесе генә аңлаган чиксез шатлык яшьләре була ул. Барысын да заманча эшлиләр – әнисенең карынында селкенеп яткан улларын дискка төшереп, фотоларын чыгартып алып кайталар. Исем дә уйлап куялар хәтта. Кыска да, яңгырашлы да булсын, «Н» хәрефенә дә башлансын! Нияз!

Бәбине үзе таба Наилә апа. Көтеп алган нарасыен – улын күкрәгенә салып озак юанырга туры килми. Кан китә... Табиблар ананың гомере өчен көрәшкәндә, системалар куеп, өстәмә кан биргәндә, яңа туган улының бик каты елаганын хәтерли Наилә апа. «Үлеп китүе тиз икән. Бала тапсам иде дә, үлсәм иде дип теләгәннәрем кабул булган түгелме соң? Юк, Раббым, зинһар, исән калдыр, шушы са-

быем хакына калдыр! Аны үстерәсе бар бит әле!»

Барысы да яхшы булачагына ул вакытта ышана алмый әле 44 яшьлек яшь әни. Бергә укыган классташы күргән төш турында да белми әле ул чакта. «Авыл урамы буйлап кайтып киләм, минем алдан бер егет бара. Кулында кечкенә бала. Сезнең өй турына җитте дә, капкагызны ачып шул баланы кертеп җибәрде. Үзе кермәде... Китте...» – дип сөйләр ул соңыннан Наилә апага. Илнар булган инде ул...

Наилә апа белән Ниязны бала табу йортыннан каршы алырга бик күп туганнары, дуслары килә. Шул вакытта яңадан яшәү тәмен тойган кебек була әни кеше. Чын күңелдән көләләр, шатланалар. Ә Ниязны кара син! Шулкадәр абыйсына охшаган бит! Абыйсының чалымнарын барысы да сизеп алалар. «Охшатасы килә шул, улым, абыеңа охшатасыбыз килә. Син дә аның кебек бер диган чибәр егет булып үсәрсең әле!»

Өйдә баланы Галиябану әбисе белән Илүзә апасы кулдан да төшермиләр. «Ниязча» яшәү башлана. Ул уенчыклар, машиналар, ул киемнәр дисеңме. Нәрсә сораса, шул әйбере бар Ниязның. Ике буын малай үстердек дип гаҗәпләнә Наилә апа. Чагыштыра торган да түгел икән. «Шунда гына басып тор!» – дип калдырып чыгып киткән Илнар кузгалмас та иде. Нияз кырык тапкыр әйләнеп килә. Күз-колак булмый кара бу замана баласына! Ярый әле дәү әнисе бар. «Бик зур эш көтә әле сезне – мине соңгы юлга озатасыгыз бар», – дип торган олы кешегә яңа җаваплылык йөкләнә хәзер. Ниязны тәрбиялисең, укытасың бар әле, әни!

Тугызынчы дистәсен ваклаган әбисе белән Нияз дуслар дисәң дә дуслар инде менә! Үзенә яңа машина сорап алганда дәү әнисенә дә алдыра. Аныкы да искергән ләбаса! Икесенеке дә яңа булса, тагын да күңеллерәк була бит уйнаулары! Өйгә кайтуга, дәү әнисе янына ашыга малай – икесе бергә уйныйлар. Борчып йөрмәгез, дип, ишекләрне үк ябып куя. Дәү әнисенең догалары, теләкләре белән кадерле булып тәгәрәп үскән мәле. Илнар абыйсын фотосурәтләрдән иң беренче табып күрсәтә. Кечкенәдән «абыең» дип үстерәләр шулай. Аның ничек вафат булганын да белә Нияз. Каберенә дә бергә баралар. Абыйсының беренче машинасы Лада Приора булганын күптән хәтерләп калган. Үзе дә шундыйны алачак ул! Абыйсыныкы кебекне!

Авыл кибетенә баргач, олимпийкага күзе төшә баланың. Өзми дә, куймый да – шул кирәк! Наилә апа хәйран кала – Илнарның нәкъ шундый «Адидас» фирмасы олимпийкасы бар иде... Алмыйча кайталар. Өйгә кайткач, әтиләре: «Нигә алмадыгыз инде аны?» – дигәч, икенче көнне барып алалар. Нияз шуны өстеннән салмый диярлек киеп йөри. Каян белгән диярсең... Нәкъ Илнар...

– Менә, абыйсына охшаганмы минем улым? Охшага-а-ан, каккан да куйган. Абыйсы тазарак иде, Ниязның таза буласы килми, ашарга яратмый бер дә. Апаска футболга йөри, футболкаларга кадәр тектердек. Аныңча гына яшибез, – дип сөя бәләкәй улын әни кеше.

– Карап торган кешебез инде, җаным, – ди дәү әнисе.

Әтисенең 50 яшьлек юбилей кичендә кызлары Илүзә сүз алгач та, тамакка төер утырган иде. «Нияз өчен рәхмәт сезгә. Мин үзем генә түгел, туганым бар», – дип рәхмәт әйтә кызлары. Аралары 16 ел булгач, Илүзә апасы бик булыша Ниязны үстерергә. Һәркайсы өчен яңа өмет, яңа тормыш алып килгән бала шул энесе...

Илнарның вафатына дүрт ел булгач, юлга чыгарга туры килә Наилә апага. Тәрбиячеләр өчен квалификация күтәрү курсларына барырга кузгала шулай. Автобус көтеп тормыйча, туктаган бер машинага утырып китә. Теге борылышны узганда йөрәк кысылып куйганына иялэшелгән дә инде. Бүгенгедәй күз алдында... Илнар авариягә очраган җиргә җиткәч, «монда улым үлгән иде», дип күрсәтә ул машина хуҗасына. «Мин бит аны күрдем!» – димәсенме бу ир! Дүрт ел элек Илнар һәлак булган авария бу ирнең күз алдында булган икән. «Бик яхшы хәтерлим», – дип барысын да сөйләп бирә...

Илнарның бу дөньяда яшәгән соңгы мизгелен күргән кешене аның юлына Аллаһы Тәгалә юкка гына чыгармаган, билгеле. Очраклылык кына түгел бу... Ничә еллар узганнан соң «Кем гаепле?» дигән сорауга җавап табар өчен микән әллә? Каршыга чыккан машина гаепледер бит инде... «ГАЗель» гаепле булса да, гаепле иттермиләр инде», – ди юлдашы. Тынычланырга, онытырга, җавап эзләп җанны телгәләмәскә кирәк... Дөрес, хаклык эзләп йөрмәделәр дә. Ул вакыйгага бәйле кәгазьләр әле дә шул килеш ята. Барыбер Илнарны кайтарып булмый. Гомере бетмәсә, бик каты бәрелүләрдән дә исән кала кеше. Гомер беткән булса, бер сәбәп кенә кирәк... Яшәргә кирәк. Хәсрәтне эчкә йотып, язмышка буйсынып яшәргә кирәк. Алар күрәсе сынау булган инде...

Сигез ел сигез көн кебек кенә үтте, ди Галиябану апа да. «Нигәдер гел Илнарны гына сөйләп торасы килә. Дөньяның бер ипле баласы иде. Еладым да еладым. Әллә миннән туган бала... Кайтканда бөтен кирәк-яракны төяп алып кайта иде. Илнар алып кайткан кәстрүлне күз карасыдай саклап тотам. Нинди генә яңалары да аныкын алыштыра алмый», – ди дәү әнисе. Сагыналар... Ул арада Нияз йөгереп килеп җитә дә, бөтен дөньяларын шатлыкка төрә. Олы балаларының үскәнен дә белми калган әти-әни менә шул балдан татлы мәхәббәт җимешләре өчен яшәп яткан көннәре. Сораганын алып бирәсе килә... Булдырасы килә... Үзләре дә башка төрле инде хәзер. Олы хәсрәт кичергән һәм чиксез бәхеткә тап булган икенче кешеләр...

Апаска футболга баргач: «Ниязның дәү әтисеме сез?» – дип сорыйлар Иршат абыйдан. «Улым ул минем. Үз улым!» – дип, горур җавап бирә әти кеше. Ел саен яңа сәпит сорый әнә Нияз. Алмыйлармы соң?! Күрше малаеныкы кебек квадроциклга кызыккан хәзер. Ул да кирәк! Күрше малаеның бишенче класста укуы гына борчый Ниязны. Ул кадәр түзеп булмый бит инде. «Әни, мин беренче класстан түгел, өченчедән башлыйм!» – дип хәл иткән 6 яшьлек малай. Янәсе, квадроциклга якынрак булачак шулай.

– Башларсың, улым, башларсың, исән-сау гына бул...

МӘҢГЕЛЕК ТҮҢ ИЛЕНДӘ

Лариса
МАЛИКОВА

Якутия белән танышуым самолетта ук башланды. Экипаж командиры: «Хөрмәтле пассажирлар, самолетыбыз Якутия өстеннән оча», – дип игълан итүгә, иллюминаторга капландым. (Бәхеткә, урыным җайлы туры килде.) Аста – тайга, ә агачлар арасында – күлләр. Нәкъ күзләр…
Алар миңа Якутия күзләре булып тоелды. Һәм ул күзләр күкләргә текәлгән: биектә – болытлар янәшәсендә очкан самолетка карап:
«Бу юлы миңа кемнәрне алып киләсең? Нинди уй-ниятләр белән килә алар?» – дигән сорау биргән сыман…

Якутия – ул бөтенләй икенче, гаҗәеп дөнья. Мондагы климат кырыс – кышын температура 67 градуска кадәр төшсә, җәен исә кырык градуска кадәр күтәрелә. Аерма 100 градус була түгелме? Табигатьнең бу кадәр кырыслыгына теләсә кем чыдый алмыйдыр… Шуңадыр, мондагы халык көчле холыклы, тырыш, шул ук вакытта балаларча самими, гади, ачык булып тоелды миңа… Аларның ата-бабалардан калган борынгы гореф-гадәтләрен, традицион милли киемнәрен ниндидер бер җылылык белән саклауларын күреп сокландым дию генә аз. Бу хакта аерым сөйләрмен әле.

Якутлар төрки халыклар төркеменә керә. Моңа дәлилләр безгә һәр адым саен очрап торды – охшаш сүзләр, ризыклар… Якутияне 1600 нче елларда Россия империясенә кушалар. Аңа кадәр якутларда тәңречелек – Күк тәңресенә ышану була. XVIII гасырда исә христиан диненә күчә башлыйлар, әмма мәҗүси ышану һәм йола элементлары аларда әле бүген дә саклана.

«Далбар Хотун»

Якутск шәһәрендә узган Татарстан көннәре чараларында без – республикада нәшер ителүче газета-журналларда эшләүче бер төркем журналистлар да катнаштык.

Якутск шәһәренә барып җит тә, коллегаларыбыз – Якутия хатын-кызларының «Далбар Хотун» журналын чыгаручы кызлар белән күрешмичә кит ди. («Хотун» сүзенең хатын дип тәрҗемә ителүен чамалагансыздыр инде?) Дуслыгыбыз берничә ел элек – алар Татарстанда Якутия көннәрендә катнашкан вакытта башланган иде. Журналның баш мөхәррире Зинаида Архипова әле без Казанда чакта ук: «Сезне бик көтәбез!» – дип шалтыратты. «Далбар Хотун» журналына кунакка коллегам – «Идел» журналы баш мөхәррире Гөлүсә Закирова белән икәү бардык.


Безне редакциягә… чистарыну йоласы үткәреп кенә керттеләр. (QR-код буенча узып, сез аның видеосын да карый аласыз. Язмада әйтеп бетермәгән күп нәрсәне дә анда күрә алырсыз.) Милли киемнәр кигән бер хезмәткәрләре махсус йолалар башкарды: аның кулындагы тәлинкәгә салган кәгазь кисәкләре исә әкрен генә төтәп, төтен чыгарып торды… Шул рәвешле чистарынып – үзебездәге негатив энергияне, начар уйларны бусаганың теге ягында калдырганнан соң, «Сахапечать» җитәкчесе Ньургуйаана Михайловна бүлмәсендә тәмле чәй эчә-эчә эш турында гапләштек. Сөйләшер сүзләр күп безнең! Укучыларыбыз уртак булмаса да, гамьнәре шул ук – җилкәләрендә мең мәшакать йөрткән, матурлыкка омтылган, гаиләсен тәрбияләгән, үзен дә онытмаган гүзәл затларыбыз Татарстанда да, ерак Якутиядә дә бертөрле алар.

Мәңгелек туң патшалыгы

Вакыт бик чикле, әмма якутларның безгә барысын да күрсәтеп өлгерәсе килә. Тау эчендә урнашкан боз мәгарәсенә узабыз. Җәй көне биредә температура –4 градус, кышын да –10 градус тирәсе икән. Хуҗалар үзләре: «Кыш көне монда җылынырга керәбез», – дип шаярталар.

Кояш астыннан тирләп, әлсерәп керәсең дә, бер мизгелдә җәйдән кышка атлыйсың. Өстә – җылы плащ, аякта – киез ката, башта – каска… Йөзгә салкын дулкын килеп бәрелә. Ул сине урап алып, баштан аякка кадәр төшеп җитә. Суык белән беренче көрәшү мизгеле узуга тирә-юнеңә күз саласың. Төрле төстәге утлар белән яктыртылган боз диварлар, боз түшәм, боз идән… Бозлы идәндә таймас өчен аяк астына палас җәелгән, ә чит-читләрендә **хаар (кар)** ята. Боздан ясалган нинди генә сын юк монда!

Якутларның суыклык символы – салкынлык патшасы Чыс**хаан** да шушы мәгарәдә яши икән… Аны Кыш бабай белән бутарга ярамый – балаларга бүләкләр өләшеп йөрми ул. Көзен Төньяк боз океаныннан җир өстенә ярымкеше, ярымүгез чыга. Ул һәр адым атлаган саен, башындагы мөгезе үсә бара – салкынлык та көчәя. Мөгезе озынрак булган саен, көннәр суыта… Гыйнварда каргалар очып килә – Чысхаанның бер мөгезе өзелеп төшә: урамда җылыта башлый. Февральдә ул мөгезләренең



Мәңгелек туңлык мәгарәсендәге аучы бүлмәсенә керергә дә куркып тордык. Хаскилар! Ясалган сыннар булып чыкты.

икенчесен югалта, мартта инде – башын. Апрельдә исә бу салкынлык патшасының гәүдәсе тәмам тарала, Лена елгасы аны үзе белән кабат океанга алып китә… Менә шундый риваять. Чысхаан бүгенге көндә Якутия Республикасының төп брендларыннан берсе.

Мәгарә эчендә тын гына көй агыла. Якутларның милли көйләре! Медитация музыкасы белән шундый охшаш ул…

Мәңгелек туң патшалыгыннан чыгуга кабат җәйге эсселек уртасында калдык. Рәхәт…

Ысыах

Бу – якутларның чын этник бәйрәме. Риваятьләр буенча, Ысыах вакытында җиргә Кояш Алласы – Айыы төшә: аның атларын бәйләп куяр өчен мәйдан уртасына Сэргэ баганасын урнаштыралар. Ысыах гасырлар дәвамында кояш торгынлыгы көнендә билгеләп үтелә, аны икенче Яңа ел дип тә йөртәләр. Миңа ул үзебезнең Сабантуйны хәтерләтте. Шулай ук туганнар җыела, шулай ук төрле ярышлар уза… Әмма аермасы да бар. Бик зур мәйданда төрле улусларның (районнарның) чатырлары урнашкан. Һәр чатыр янында уратып алган мәйданчыклар да бар. Шунда алгыслар (юк, шаманнар белән бутый күрмәгез.



■ Муллык агачы. Аның эченә кереп, өч мәртәбә сәгать угы йөреше буенча әйләнеп чыгу, кешегә бәхет, байлык һәм бәрәкәт алып килә дип санала.



Алар үзләрен шулай атаганны, гомумән, яратмый. «Шаман – кара көчләр белән аралашучы, ә без башка», – диләр.) халык өчен чистарыну йоласын уздыра. Шулай ук мәйданчыкларда ашлар әзерләнә, өстәлләр корыла. Сыйлаудан баш тартырга ярамый – һәр кунак ит һәм кымыздан авыз итәргә тиеш. Безне дә шәһәр башлыгының чатырына чакырып, сый-хөрмәт күрсәттеләр.

Ысыах бәйрәмендә исерткеч эчемлекләр эчү, бер-берең белән ачуланышу һәм бәхәсләшү тыела.

Бәйрәмгә барысы диярлек милли киемнән килә – ирләр дә, хатыннар да. Хатын-кызларның зәркән бизәнү әйберләре күз явын алырлык! Элек аларның авырлыгы бер потка, ягъни 16 килограммга җитә торган булган. Әлеге комплектның башка киелә торган өлеше – бастынга дип атала. Иң зурысы һәм иң авыры – илин-кэлин кэбиһэр. Анысы безнең изүне хәтерләтә, әмма ул озынрак һәм күкрәкне генә түгел, арканы да каплый. Шулар янына тагын алкалар, ике беләзек һәм балдакларны кушыгыз... Илин-кэлин кэбиһэр хуҗасын явыз көчләрдән – абаасадан саклый. Христиан динен кабул итсәләр дә, якутлар абаасаларга ышануларын дәвам итәләр, алардан һаман да куркалар. Бу явыз көчләрдән бөтенләй котылу мөмкин түгел, аларны вакытлыча куып торырга гына була, ди алар. Алгыслар (шаманнар) ниндидер бик катлаулы йолалар уздырып, ул көчләрне кире үз дөньяларына кертергә булышалар...

Аннан бөтен халык үзәк мәйданга җыелды. Быел Ысыах бәйрәмендә 200 меңнән артык кеше катнашты, диделәр. Хәтта тамашачылар арасында Екатеринбургтан килгән «Ночные волки» байкерларын да күрдем.

Ысыахның тагын бер йоласы турында сөйләп китәсем килә. Мәйдан уртасына ат чыгаралар, ул тыныч торса – димәк, киләсе ел уңышлы, әйбәт булачак. Бөтен халыкның күзе атта. Ә ул кинәт пошкыра, «бии» башлады... Тын да ала алмыйча торган бер мизгелдә аны җитәкләп чыккан егет йөгәнне кысыбрак тотты бугай – ат аңа буйсынды, тынычланды. Тирә-юнемә карамасам да, сиздем – меңләгән тамашачы, ниһаять, җиңел сулап куйды...

Аннары алгыс, учак яндырып, үз телләрендә нидер укый башлады. «Ул безнең һәммәбез өчен теләк тели», – диделәр. Сәламәтлек сорый; тормышта, эштә уңышлар; ялгызларга – парларын табуны, баласызларга – балалы булуны... Һәр теләктән соң алгыс Кояшны «Уруй-Айхал!», «Уруй-тус кул» дигән сүзләр белән сәламли. Аңа кушылып, бөтен халык кулларын күтәрә һәм бертавыштан «Уруй-Айхал» дип кабатлый. Каз тәннәре чыга...

Осуохай

Ә хәзер менә нинди күренешне күз алдыгызга китерегез: бөтен халык, урыннарыннан торып, диңгезгә кушылырга ашыккан елгалар сыман, мәйдан уртасына агыла... Иң уртада – Сэргэ баганасы. Кешеләр, кулга-кул тотынышып, шул багана тирәли әйләнеп йөри башлыйлар. Яңалар кушыла тора – багана тирәли әйләнүчеләрдән торган түгәрәкләр өстәлә бара. Багана янындагы түгәрәк әле кечкенә, аннан ераклашкан саен түгәрәкләр зурая, зурая, зурая... Менә инде түгәрәкләр белән бөтен мәйдан тула. Меңләгән кеше! Бу – Кояшка табынучыларның борынгы

Нәрсә алып кайтырга

■ Әлбәттә, тозлаган, ыслаган балык (муксун, чир, омуль, нельма), болан ите. Болар – гастрономик сувенирлар.

■ Якутия истәлеге итеп мамонт сөягеннән ясалган төрле сувенирлар алып кайтырга да тырышыгыз.

■ Тагын ниләр алыргамы? Чорон – кымыз сала торган савытлары шулай атала. Аны якутларның милли савыты дип әйтеп була. Ысыах бәйрәмендә төп йолаларның берсе дә чоронсыз үтәлми. Кешеләр басалар да кымыз салынган чоронны түгәрәк буенча җибәрәләр: һәркем берәр йотым кымыз каба, бәхет һәм бәрәкәт тели… Савыт төбендә калган кымызны корбан китерү буларак җиргә түгәләр. Туйларда яшьләргә кымызны шулай ук чоронга салып эчертәләр. Сувенир итеп, чоронның үзен дә, чорон сурәтләнгән магнитлар, брелокларны да сатып алырга була,

■ Якутиягә баручылар аннан милли зәркән эшләнмәләрсез – алка-муенсаларсыз да кайтмыйлар. Сүз уңаеннан, элек-электән колак алкасы якутларда хатын-кыз турында бик күпне сөйләгән: кияүдәме ул – түгелме, балалары бармы, күпме… Хәзер исә алка сайлаганда бу шартларга инде карамыйлар – матурлыгы, бизәкләренең катлаулыгы гына җәлеп итә. Безне генә түгел, якут хатын-кызларының үзләрен дә.







■ Яңа танышыбыз – Халыклар Дуслыгы йорты җитәкчесе Антонида Николаевна бәйрәмгә Санкт-Петебургтан кайтасы туганнарының кызларына әзерләгән зәркән бизәнү комплекты.



Осуохай биюе. Әлеге күренештән шундый көчле энергетика бөркелә… Осуохайда катнашу һәркемгә алдагы елда җитәрлек иминлек, сәламәтлек, энергия һәм яңа көч бирә дип санала.

Ысыахның төп йоласы – Күн **Керсютэ (Көн күрсәтү)** – кояшны каршылау. Элек-электән аны 22 июньгә каршы төндә уздырганнар. Әмма 1941 елдан соң бу традиция үзгәргән – хәзер әлеге йоланы бер атна алдан уздыралар. Кызганыч, монысына без инде элегә алмадык…

Язмада – Якутиянең бер кыйпылчыгы гына. Күп нәрсәне күрергә өлгермәдек. География дәресендә Лена баганалары турында үткәнне хәтерлисезме? Табигатьнең бер могҗизасы – Лена елгасы ярында күп чакрымнарга сузылган багана сыман кыялар алар. Аларны күрәсе килү хыялы мәктәп елларыннан ук күңелдә йөри. Әмма, кызганыч, тагын чынга ашмады… Димәк, Якутиягә кунак түгел, турист буларак та барырга туры киләчәк…

Казан–Якутия–Казан.

Ризыклар

Якутларның төп сые – катырылган балык һәм ит. Аларны юнып бирәләр – кул белән тотып, тоз-борычка манып ашыйсың. Струклап, ягъни юнып ашар өчен чир һәм нельма балыкларын катыралар. Иң салкын көнне тоткан балык иң шәбе булып санала, чөнки ул судан чыгаруга ук ката.

Язма башында әйткән идем бит, охшаш сүзләр дә, ризыклар да шактый дип. Өстәл уртасында урын алган, кабып карагыз дип кыстаган деликатеслары – **харта** – безнең карта булып чыкты.



Саламат

Аның турында аерым языйм әле, бәлки, әзерләп тә карарсыз. Саламат бәйрәм сые дип санала. Якутлар аны туйларга, юбилейларга, бәби ашларына әзерлиләр.

Кирәк:
- 130 мл су;
- 150 мл сөт;
- 150 г ак май;
- 2 аш кашыгы бодай оны;
- тоз.

Эш барышы:
1. Майны кечкенә савытта эретәбез.
2. Он өстибез.
3. Бераз кыздыргач, кайнар сөт салабыз. Әйбәтләп болгатабыз..
4. Кайнап торган су өстибез, теләгәнчә тоз кушабыз.

Әзерләү вакыты – биш-җиде минут. Саламатның калориясе бик зур, шуңа күрә аны кунакларга 50 шәр граммлы кечкенә савытларда гына чыгаралар. Йә, нәрсәгә охшаган? Нәкъ татар халкының әлбәсе бит!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

«УЛ МИҢА ҮЗЕ ТӘКЪДИМ ЯСАДЫ...»



Раил ШӘМСУАРОВ,
Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 9 ел;
балалары – Нәфисә (8 яшь),
Әсфәндияр (2 яшь).

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.**

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Чәченә! Хатын-кызның чәче озын булса, күз ихтыярсыз шунда төшә. Билгә кадәр җиткән чәчкә кызыгу ир-атның канындадыр, мөгаен. Озын чәч кызларга шундый килешә бит ул! Кызым Нәфисәнең дә чәче биленнән узды инде. Әле бер тапкыр да кистергәнебез юк. Әнисенең дә чәчләре озын бит. Шушы яшькә җитеп Зөлфиянең чәчен әле бер тапкыр буятканы да юк. Чәчтарашханәгә барган саен шаккаталар. Мине дә шул чәчләре белән сихерләгәндер инде ул...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Беренчедән, бу кешенең үзеннән торадыр. Мин менә эчемдә ниндидер үпкәләр җыеп йөрмим – тиз онытырга тырышам. Югыйсә үзеңә авыр була... Кемдер хатын-кызның күп сөйләшүен дә кимчелек дияргә мөмкин. Анысы гына саналмый да бит аның! Кайчак үзләре генә очрашалар да дөньяларын онытып сөйләшәләр алар. Рәхәтләнеп сөйләшсеннәр! Ир-ат моны хупларга гына тиеш. Зөлфия дә кайчак дус кызлары белән шулай китеп югалгалый. Хатын-кызга мондый онытылып алулар кирәк дип саныйм.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Шулдыр инде, хыянәттер... Бу темага Зөлфия белән дә сөйләшкәнебез бар, ләкин минем аңа тирән керәсем килми. Кирәкмәгән нәрсәләр турында күп уйларга ярамый, алар материальләшә диләр бит. Хатыныма 100 процент ышанам! Әмма шундый хәл булган очракта да, әгәр кеше сиңа бу ялгыш булды дип әйтә икән, чын күңелдән яратсаң, мөгаен, гафу итәсеңдер... Юк, бу хакта уйларга теләмим!

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр.

– Зөлфия – универсаль, аңарда боларның икесе дә бар. Хатын-кыз бик көчле зат бит ул: бөтен нәрсәгә өлгерә, бөтен нәрсәне үзенә сыйдыра... Гастрольләрдән өйгә кайтып керергә яратам. Иң дулкынландыргыч мизгелләр... Аерылышып торуны без, гомумән, бик авыр кичерәбез. Элегрәк әле елашып аерылыша идек. Бу күбрәк мин каядыр киткәндә шулай була иде... Гастрольдән кайтканда башта аэропортка килеп төшәсең, аннан автобуста Казанга килеп керәсең. Таныш урамнар... Тик син булмаган арада нәрсәдер үзгәргән шикелле. Ишекне ачуга: «Әт-и-и-и!» – дип, балалар килеп сарыла. Күрешми торулар хисләрне дә яңарта...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әйе, була ала һәм булырга тиеш тә! Дус та, сердәшче дә... Кайсы вакыт чишә алмый торган төеннәрне чишәргә булышучы, кирәк вакытта тынычландыручы... Зөлфия белән безнең иң яраткан вакыт – якшәмбе көнне иртәнге чәй. Дүртебез дә бергә булган мәл! Бөтенебез бергә җыелган чак сирәк шул...

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Зөлфияне беренче тапкыр үзебезнең театрда күрдем. Аның Казан театр училищесында укыган чагы – чыгарылыш курсы студентларының спектаклен карарга килгәннәр. Мин шунда ук аңа игътибар иттем: алкаларына да, киемнәренә дә... Үзем әле исемен дә белмим. Берничә көн эчендә әллә ничә тапкыр очрады ул миңа. Урамда, дискотекада... Юкка гына түгел инде бу, дим. Ул чакта Зөлфиянең итәкләр күпкә кыска, чәчләр таратылган. Янып торган шәһәр кызы! «Мондый чибәрлеге белән миңа карамас...» – дим. Ә ул дуслыгымны кабул итте! Беренче свиданиебез ноябрь ахырында булды. Аз гына инде кар яткан чак. Мин күн курткадан. Текә! «Фасонны китергән идең – башымны шулай әйләндердерең», – дип көлә Зөлфия ул көнне искә төшергәндә.
Ә тәкъдимне ул миңа үзе ясады. «Әйдә, никах укытабыз», – диде. Шундый көтелмәгәндә һәм шундый гап-гади булды – чәй эчкән кебек кенә. Аның зур вазыйфа икәнен ул чакта аңламыйча да... Әниләр Зөлфия белән танышырга өлгергәннәр иде инде. Җәй көне әтинең юбилее булды, ә Зөлфия шул мәҗлесне алып барырга кайтты. Табында кунакларның кайсыдыр миннән: «Әле башлы-күзле булырга җыенмыйсыңмы? Кыз тапмадыңмы?» – дип сорады. Әтинең абыйсы –

шагыйрь Таһир Шәмсуаров шунда: «Ул үз кешесен тапкан инде», – дип әйтеп куйды. Бу фатыйха бирү шикелле булды. Туганнарның барысы да Зөлфияне бик үз итә. Безнең якта – Лениногорскида «иркәм» дип сөйләшәләр, хатыныма да «Зөлфия иркәм» дип кенә торалар. Мин үзем дә аңа шулай эндәшәм. Казанда яраткан кешеңә генә шулай диләр – минем бу сүзгә ике мәгънә кушылды. Исем белән дәшсәм, ул аптырап карап куя. Нәрсәдәндер канәгать булмаганда гына чыга ул минем авыздан.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Хатынымны әниемә охшатам дип әйтә алмыйм. Эшчәнлеге, тырышлыгы белән булса гына. Әти белән әни Зөлфияне бер күрүдән яратты, үз кызлары кебек күрәләр – икесе дә «кызым», диләр. Бу сүз аларга тансык, без бит гаиләдә ике малай гына үстек. Зөлфия үзе дә аларга «әти, «әни», дип эндәшә. Килен белән кайнана кебек түгел алар. Берсе икенчесен шелтәләргә дә мөмкиннәр. Үпкәләшмиләр! Шул сыйфатларын яратам инде.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Шөкер, хәзер үзем белән андый хәлләр булганы юк. Моңа сөенәм... (*Көлә.*) Мин үзем дә китапча яшәргә тырышам: матурлыкка карыйм да, сөбханалла-машалла, дим һәм башка ул якка күз салмыйм... Ир-атлар да бит төрле: гәүдәгә, төс-биткә матур булып та, үзен кыюсыз тотканнары бар. Андый очракларда хатын-кызга беренче адымны ясау дөрестер. Мингол абый Галиев – җыр буенча хәлфәм. Ул аудиториядә кызларга гел: «Берәр егетне ошатсагыз, мин аны бәхетле итә алам дип уйласагыз, тотыгыз да бәхетле итегез», – дия иде. Чынлыкта, бездә дә бит беренче адымны Зөлфия ясады. Мин әле шулай сузып йөргән дә булыр идем.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Бүген – күбрәк матур киемдер. Моны кызларның үзләреннән дә ишеткәнем бар. «Аяк киеме яхшы, чиста булса, бетте инде, шунда ук гашыйк булам», – диючеләр бар. Әмма кием – тышкы кабык кына, ир-ат үзенә хатын-кызны гамәлләре белән, үзен ирләрчә тотуы белән җәлеп итәргә тиештер. Зөлфиягә дә бу сорауны биргәнем булды. «Нигә мине, нигә башканы түгел?» дигән сорауны һәр пар башта бер-берсенә бирәдер... Уенын-чынын кушып, аның: «Буең озын булганга – миңа астан өскә таба сиңа карау шундый рәхәт», – дигәне бар. Серне ачмый!

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Мин юкта Зөлфия өйгә үзгәрешләр кертергә ярата. «Атмосфера ясыйм», – дип аңлата ул моны... Диваннарга, шкафларга ук кагылмаса да, бала караватлары, тумбочкалар гел бер урыннан икенче урынга күчеп тора бездә. «Авыр бит, тотынма», – дип карыйм. Исе дә китми: «Әй, күчердем инде», – ди... Өйдә ул бездән гел тәртип таләп итә һәм аңа буйсынырга тиешбез дип саный. (*Көлә.*) Яшермим: «Нигә бөтен нәрсә син дигәнчә генә булырга тиеш?» – дип карышмадым түгел, карыштым. Аннары аңладым: ул хаклы – өйдә тәртип булырга тиеш. Миндә кайбер нәрсәләрне гадәткә әйләндерергә Зөлфиягә озак вакыт кирәкмәде...

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Төрлечә була: кайсы вакыт, чынлап та, юл куясың, ә кайвакыт ризасызлык белдереп, үз фикереңне әйтәсең. Йә синеңчә була инде, йә аныңча... Яши генә башлаганда, бу сүз көрәштерүләрнең зурга киткән чаклары да булды. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга икән. Әйтерсең моны үзең эшләмисең – кемдер синең белән идарә итә шикелле... Еллар узган саен, үзгәрәсең: башта сүзеңне уйлыйсың, аннары гына әйтәсең. Үзеңә үзең психолог була башлыйсың, кәефеңне дә көйләргә өлгерәсең. Тормыш өйрәтә икән ул!

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Үзем пешерәм дип тотынсам, бик озак булыр – пиццага заказ бирергә туры килер. Өйдә тавыш чыкмасын өчен, шулай эшләү дөресрәк булыр... Мин аш-су тирәсендә кайнашмыйм шул. Яңа Иштерәккә кайткан саен, Зөлфия әтигә карый да: «Их, Раил дә пешерсә иде», – ди... Әни укытучы булгач, әти иртән торып гел пешерә иде безнең элек. Дөрес, әни хәзер инде укытмый, ләкин әтинең гадәте калды. Ул бик иртә тора, әни уянганчы чәйне кайната, пешерә... Миннән булмый шул... «Каһвә ясарга булса да өйрән инде», – дип көлә Зөлфия. Балалар белән өйдә үзебез генә калсак, суыткычта нәрсә бар – шуны гына ашап торабыз.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Кайвакыт минем үземне җыеп алып чыгарга кирәк. (*Көлә.*) «Әйдә, тизрәк! Вакыт, вакыт!» – дип, ишек төбендә басып, аны көткән чагым сирәк. Нәфисәне генә мәктәпкә барганда тизләтергә туры килә менә. Йокы шундый әйбер инде ул – аны җиңү бик авыр...

Ә тамаша башлангач залга кергән тамашачы, үзенең соңга калганын аңлап, тыныч кына урынын табып утырса, бик комачауламый инде ул. Әмма шундый кешеләр дә була – тирә-юньнәрендә гел ыгы-зыгы тудыралар. Үзем беркайчан да конфликтларга кермәскә тырышам. Минем өчен бик газаплы хәл ул – йөрәгемә ярамый. Тынычлык яратам!

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Яшьрәк чакта Зөлфиягә чәчәкләр бүләк иткәндә гел лилияләр ала идем. Аларның исе үземә ошагач, Зөлфиягә дә ошый дип уйлый идем. Ә ул бу исне бөтенләй яратмый икән! Ничә еллар узгач кына әйтте бу хакта... Зөлфия миңа гел сыйфатлырак, кыйммәтрәк бүләкләр ала. Ул, гомумән, бүләк сайлауга җитдирәк карый. Бүләкләрне миңа гына түгел – башкаларга да бирергә ярата. Алдан ук аны әзерли, матур сүзләр белән котлый. Шуннан рәхәтлек ала... Берәүнең дә туган көнен онытмый. Барыбызны да җыйнап тота шулай.

Тулысынча укыгыз »





БИТКӘ СУЫК КАГЫЛМАСЫН

Сәламәт тән тиресенә кыш куркыныч түгел! Температураның кисәк үзгәрүеннән ул стресс кичерми. Ә менә коры һәм сизгер тире турында болай дип әйтеп булмый. Җылылык радиаторларыннан бөркелгән эссе дә, урамдагы җил һәм салкын да зыян китерә аңа. Косметика химигы һәм брендлар технолог-уйлап табучысы Олеся МОСТАЕВА коры, сулган, сизгер һәм ялкынсынучан бит тиресенә ярдәм итү чараларын барлый.

Коры тиренең, гадәттә, саклык функцияләре бозылган була. Бу нәрсәсе белән куркынычмы? Тиредә аллергия реакцияләре, сизгерлек һәм корылык, тиренең тартылып, уңайсызлап торуы, кубалаклануы һәм кызаруы күзәтелергә мөмкин.

Саклык барьеры зарарланган коры һәм сизгер тире үзенең церамидларын (тиренең өске катлам структурасындагы мөһим компонентлар) торган саен күбрәк югалта, юкара, төсе тоныклана. Андый тире тиз кызара, тиз ялкынсына, еш кубалаклана, хәтта чабырырга һәм дерматитлар чыгарга да мөмкин. Бит тиресе гел тарттырылган, хәтта ачыттырып кызышкан кебек тоела, һәм ул көчәя генә бара.

Ләкин яхшы хәбәр дә бар: бу барьерны кабат торгызырга, ә тиренең сизгерлеген киметергә мөмкин.

Моның өчен Олеся Мостаева «Мастерская Олеси Мустаевой» һәм «Она иная» брендларының абсолют хитлары булган ике продуктны бит тиресен тәрбияләү өчен кулланылучы чаралар исемлегенә кертергә тәкъдим итә. Әлеге продуктлар кыш көне аеруча актуаль. Болар:

✓ крем № 3

✓ бит тиресе өчен «Она иная» тонигы.

Крем № 3 составында церамидлар комплексы бар. Алар тиренең тиз һәм тулысынча тернәкләнүенә ярдәм итә. Церамидлар тиренең өске катлам күзәнәкләрен үз урыннарында тота, тышкы ярсыткычлардан, бактерия һәм вируслардан саклый. Моннан тыш, церамидлар тиредәге дымны тоткарлый. Бу исә бит тиресенең сулуын һәм иртә картаюын кисәтә.

Крем № 3 – коры, сулган һәм кубалакланган тире өчен ашыгыч ярдәм чарасы да ул.

Әлеге крем дерматология тикшерүе узган. Составында яшь чикләвен билгеләүче ингредиентлар юк, шунлыктан аны яңа туган балаларның тән тиресен тәрбияләү өчен дә кулланырга мөмкин.

Бу кремның барлык үзлекләре дә клиник расланган.

Кремны тидергәнче, биткә тоник сиптерергә киңәш ителә.

Бит өчен «Она иная» тонигы составында, беренчедән, тирене озак вакытка яхшылап дымландыручы актив компонентлар бар. Икенчедән, тиренең күзәнәкләрен стрессы факторлардан (температураның үзгәрүе, салкын, зыкы, шәһәр тузаны, гаджетлардан бөркелгән зәңгәр ут) саклый.

«Она иная» тонигының бит тиресендәге ялкынсыну дәрәҗәсен һәм кызаруны нәтиҗәле киметә алуы Россия һәм Корея лабораторияләрендә клиник яктан расланган.

Тиренең саклык функцияләрен эшләтеп җибәрү һәм аның халәтен яхшырту өчен «Она иная» тонигын иртән дә (битне юганнан соң), һәм көн дәвамында бит тиресе кичергән стрессларның зарарлы нәтиҗәсен киметү максатыннан, төнгә каршы да кулланырга киңәш итәбез.

Крем № 3 һәм **«Она иная» тонигының** эффектлы булуының сере нәрсәдә соң?

«Бар сере – дөрес дозаны билгели алуда, составының балансны булуында һәм уникаль рецептурасында», – ди Олеся Мостаева.

Исегезгә төшерәбез, **Крем № 3** һәм **«Она иная»** тонигының барлык үзлекләре клиник расланган. Шулай ук «Она иная» һәм «Мастерская Олеси Мустаевой» брендларының барлык продукциясе дә «Хәләл» стандартлары сертификатына ия.

1



«Она иная» тонигы:

- дымландыра
- кызыллыкны сизелерлек киметә
- тирене стресслардан саклый
- тиредәге картаю процессларын тоткарлый (anti-age)
- тиренең төсен тигезли

2



Крем № 3

- тирене 24 сәгать буе тирәннән дымландыра
- тиренең барьер функцияләрен саклый һәм торгыза
- интенсив тукландыра
- һава торышы тәэсиреннән саклый

КЫШ КӨНЕ ДӘ СӘЛАМӘТ ТИРЕ!

510 сумнан башлап

- ✓ тирәннән дымландыра*
- ✓ интенсив тукландыра һәм саклый*
- ✓ тиренең тыгызлыгын һәм сыгылмалылыгын яхшырта*
- ✓ косметик процедуралардан соң тирене торгыза*
- ✓ чабыручан, кибүчән, сизгер, кубалакланучан, кызаручан тире өчен*
- ✓ дерматологик тикшерү узган*

*клиник тикшеренүләр нигезендә
нәтиҗә № NSP 091327 2019 елның 5 декабреннән. Реклама







master-om.com



Яңа елны ничек каршы алырга

Куян – гаилә җанлы җәнлек. Шунлыктан Яңа елны гаиләгез, бик якын туганнарыгыз һәм дусларыгыз белән генә каршы алыгыз. Бәйрәм табынында өегезгә беренче тапкыр аяк баскан кешеләр булмасын. Яңа елны өйдә түгел, башка берәр җирдә каршы алырга теләсәгез, ул сезгә инде күптәннән таныш урын булсын. Яныгызда туганнарыгыз, якыннарыгыз булса, Куянның күңеле күтәрелер.

ЙОМШАК һӘМ ЯГЫМЛЫ БУЛ, КУЯН ЕЛЫ!

Бәйрәмгә ничек киенергә

Яңа ел хуҗасы кычкырып торган җете төсләрне яратмый. Тыйнак Куянның күңелен күрим дисәгез, аксыл, яшькелт, алтынсу, шоколад, кызыл кирпеч төсләрен сайлагыз. Су куяны елын каршы алганда зәңгәр төсләр дә урынлы булыр. Әлбәттә инде, Кара куян кара төсне дә үз итми калмас. Ә менә ерткыч җәнлек тиреләрен хәтерләтүче бизәкләрдән, мехлардан (табигыеннан бигрәк тә!) тыелыгыз, югыйсә Куянны куркытып куюыгыз бар.



Бәйрәм табынына нәрсәләр куярга

Барыбыз да яхшы белә – куян үлән ярата. Бәйрәм табыны ел хуҗасына ошасын дисәгез, яшел тәмләткеч үләннәр, яшелчәләр, җиләк-җимеш мулдан булсын. Куян дип уйлауга, күз алдына иң элек кишер белән кәбестә килә. Болар – аның иң яраткан ризыклары. Бәлки, үзегез яраткан салатны кишер рәвешендә ясарсыз – Куянның күңелен күрми булмас бит?! Әлбәттә, бәйрәм табыны итле ризыкларсыз да булмый. Ләкин берүк куян ите әзерли күрмәгез тагын.

Нәрсә бүләк итәргә

Бүләк бирешү – матур гадәт. Яңа елда да якыннарыбызга кечкенә генә бүләкләр әзерләп, күңелләрен күрми ярамас. Куян уңайлы, кирәкле һәм артык кыйммәт булмаган бүләкләр яклы. Бу – оригиналь кучтәнәч, куян сыны рәвешендәге брелок яки сувенир булырга мөмкин. Куян рәсеме төшерелгән картина да яхшы бүләк. Җылы бияләй, башмак, йомшак плед, шарф... Саный китсәң, бу исемлек бик озын.





2023 ел якынлаша. Бер ел буе җиһанда Кара су куяны хакимлек итәчәк. Мондый хәл алтмыш елга бер генә туры килә. Куян тынычлык һәм татулык ярата, каударланганны өнәми, дусларга, туганнарга хәерхаһлы. Көнчыгыш йолдызнамәсе буенча, Куян – елгырлык һәм үрчү символы. Әз генә җилбәзәклек һәм киеренкелек тә хас үзенә. Бер үк вакытта ул җаваплы, хисчән һәм нечкә күңелле. Кыскасы, Куян – күркәм холыклы җан иясе. Иясенә охшап, 2023 ел да тыныч һәм матур килер дип өметләник.

Яңа елга юраулар

Яңа елга әҗәтләрсез керү кирәклеген барыбыз да белә. Акча энергиясен җәлеп итү өчен, яңа ел чыршысы тирәли сары төстәге тәңкәләр тезеп чыгарга кирәк дигән гыйбарә дә яши. Табындагыларга вак акча өләшү гадәте дә киләсе елда уңыш китерә, имеш. Яңа елны яңа эскәтер җәелгән өстәл артында каршыласаң, ел уңышлы узачак, диләр. Байлыкны җәлеп итү өчен, тәлинкә астына тәңкә кую гадәте дә бар. Ярый соң, сынап карыйк.

Өйне ничек бизәргә

Өйнең төп күрке, әлбәттә – бизәлгән яшел чыршы. Ләкин быел җете төстәге чыршы уенчыкларын ераграк яшереп торыгыз. Җәнлек сыннарын да өнәми ел хуҗасы. Ул уңайлылык яклы. Өстәлдә – матур ашъяулык, диванда – күңелне күтәрә торган төстәге йомшак мендәрләр, стенада – гаилә фотографияләреннән тезелгән гирлянда, киштәләрдә агач әрҗәләр (чөнки бу елның стихиясе агач) – менә ни белән күңелен күреп булачак аның. Тере чәчәкләр, чүлмәкле гөлләр дә бик урынлы. Буш вазаларга яшел чыршы ботаклары утыртыгыз. Билгеле инде, иң күренә торган җирдә – куян сыны. Куян елы булсын да, үзе булмасын, имеш!



Узган Куян елларындагы тарихи вакыйгалар

- 1963 ел – кешелек тарихында беренче хатын-кыз космонавт Валентина Терешкова Галәмгә оча.
- 1975 ел – физик-теоретик Андрей Сахаровка Нобель премиясе бирелә.
- 1987 ел – «ВАЗ» автомобиленең «тугызынчы» моделе күпләп җитештерелә башлый. Германия Федератив Республикасы гражданины, 18 яшьлек Матиас Руст шәхси самолеты белән Мәскәүнең Кызыл мәйданына төшеп утыра.
- 1999 ел – Борис Ельцин Россия Президенты вазыйфасыннан китә, аның урынына Президент булып Владимир Путин килә. Европа илләрендә яңа акча берәмлеге – евро кулланышка керә.
- 2011 ел – Япониянең Фукусима-1 атом электростанциясендә авария була.

Фото: ru.freepik.com



йолдызнамә–2023

Кучкар. Яңа ел Кучкарларга күп вәгъдәләр бирә. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылачак, яңа белем яки яңа һөнәр алу ихтималы бар. Матди яктан да уңыш көтелә. Яңа фатир яки яңа йортка ия булу өчен шансыгыз зур, файдаланып калырга тырышыгыз. Гаиләгездә күңелле вакыйга көтелә – сафларыгызга яңа туган кушылачак.

Үгезбозау. Төп көчегезне гаиләгезгә бирегез, беренче урында якыннарыгыз торырга тиеш. Бераз матди кыенлык кичерерсез, ләкин бу узгынчы проблема, аның өчен борчылу урынсыз. Гаиләдә һәм карьерада тотрыклылык булыр. Яңа танышлар һәм яңа дуслар табарсыз, киләчәктә алар сезнең таянычыгызга әверелер.

Игезәкләр. Хыялыгызны тормышка ашыру өчен кулыгыздан килгәннең барын да эшләгез. Сүзләргә игътибарлырак булыгыз, мөнәсәбәтләрне җимерүдән сакланыгыз. Хисләрне йөгәнләргә кирәк, аларны иҗади юнәлештә файдалану күпкә отышлырак. 2023 ел – яңа бизнес-проектлар башлап җибәрү өчен кулай чор. Дусларыгызга таяныгыз, аларның ярдәме зур булачак.

Кысла. Яңа ел үз кануннарын кертә: уңышка ирешүнең төп шарты – шик-шөбһәләрдән арыну. Шикләнәсез икән, бер урында озак таптанырга туры киләчәк. Кыюрак булыгыз! Шәхси тормышта һәм һөнәр баскычында уңыш көтелә. Хыялларыгыз тормышка аша башлар. Кыюларны язмыш юмарт бүләкли.

Арыслан. Ихтыяр көче, сабырлык, үҗәтлек, шәфкатьлелек – менә шушы сыйфатларыгыз уңышка һәм казанышка ирешүдә төп булышчыларыгыз. Тырышлыкның нәтиҗәсен озак көтәргә туры килмәс. Аралашу һәм эш даирәсен алыштыру ихтималы бар. Ялгызларга да бәхет елмаячак, алар үзләренә тиң кешене очратыр.

Сөмбелә. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылырга тора. Бераз гына тормышчан фикер йөртсәгез, теләсә нинди максатка ирешәчәксез. Хәтта иң кыю планнарыгыз да тормышка ашачак. Әҗәткә акча яки кредит алырга ашыкмагыз, бераз мөмкинлегегезгә карап яшәсәгез, уңай нәтиҗәсен күрми калмассыз.

Бизмән. Җиңүләр елы. Төрле конкурсларда ешрак катнашырга тырышыгыз – уңыш сезнең якта булачак. Бизмәннәрнең тигезлеген бозучы вакыйгалар да булмый калмас, аларга фәлсәфи карагыз. Ел уртасыннан тормышыгызның яңа этабына керәчәксез. Бу гаилә тормышы яки социаль статусыгыз белән бәйле булырга мөмкин.

Чаян. 2023 ел Чаяннар өчен уңышлы булачак – һөнәри өлкәдә үсеш көтелә. Бөтенләй яңа эшкә керешүегез дә ихтимал. Ни генә булса да, үзгәрешләр сезнең файдага. Ял итү, сәламәтлекне ныгыту, яшәү шартларын яхшырту өчен акчагызны кызганмагыз. Эчке сиземләвегез – иң ышанычлы киңәшчегез. Үзегезгә билгеләнгән юлдан тайпылмагыз, яңа танышлар белән сак булыгыз.

Укчы. Кызыксынучан Укчыларга бер урында гына утыруы кыенрак булачак. Тормышыгызны үзгәртәсе килү теләге көчле – кемдер эшен, ә кемдер хәтта яшәү урынын ук алыштырырга мөмкин. Ул бу елның икенче яртысыннан ук актуаль булачак. Матди хәлегездәге тотрыклылык – үзе үк сөенечле хәл. Белемегезне арттыру өчен яңа мөмкинлек килеп чыгар, файдаланып калыгыз.

Кәҗәмөгез. Теләкләрегезгә буйсынып, хыялларыгызны чынга ашыру өчен уңышлы елларның берсе. Яңа эш башларга яки зуррак, кыйммәтлерәк берәр әйбер сатып алырга теләсәгез, курыкмыйча тотыныгыз – отачаксыз. Моның өчен аеруча кулай чор – март ахырыннан сентябрьгә кадәр. Ялгыз Кәҗәмөгезләрне август ахырында хәлиткеч очрашу көтә.

Сукояр. Талантлар һәм мөмкинлекләр ачыла торган вакыт. Кызыклы идеяләр Сукоярларны адым саен сагалый. Аларны үзегездән ерак булган очраклы кешеләргә сөйләмәгез, югыйсә канатларыгызны сындырып, илһамыгызны качырырлар. Сәләтегезне файдаланып, шактый гына уңышка ирешү форсаты килеп чыгар. Гади кебек кенә тоелган эш аркасында абруегыз артыр.

Балыклар. Язмыш сезгә хәерхаһлы. 13 июльдән соң тормышыгызда шактый гына үзгәрешләр булуы мөмкин. Уңышка чын-чынлап ышанучылар чынлап та аңа ирешәчәк. Күп еллар борчыган проблемадан яки күңелегезгә ошамаган кешедән котылырсыз. Гаиләгездә күңелле вакыйгалар көтелә, моның ишәю белән бәйле булуы ихтимал.

ДУЛКЫН-ДУЛКЫН ЧӘЧЛӘРЕҢ

Хатын-кыз күрке – чәч. Килешәсездер, бәйрәмнәрдә чәчләргә аеруча игътибар итәбез. Матур причёска ясалган чәчләр кәефне тагын да күтәрә. Бөдрәләрне элеккеге кебек бигуди чорнап ясамыйбыз хәзер. Моның өчен кул астында плойка, утюжок кебек стайлерлар бар. Чәч кабарып, дулкынланып торсын өчен, бөдрәләрне дөрес итеп ясый белергә генә кирәк. Чәчтараш Гөлназ САФИНА утюжок белән дулкыннар ясарга өйрәтә.























■ Чәчләрне яхшылап юып киптерәбез. Бальзам-кондиционер, маскалар куллану турында искә төшерү кирәк тә түгелдер. Кипкән чәчләргә термоспрей сиптерәбез. Ул чәчләрне янудан саклый. Спрей сиптерелгән чәчләр озаграк кыза.

■ Чәчләрне өч өлешкә бүлеп, җыеп куябыз. Иң элек аскы өлештәгеләрен бөдрәләтәбез.

■ Инде төп лайфхакка җиттек. Чәч тамырларыннан 10–15 см калдырып, бер тотам чәчне стайлер белән каптырабыз да, аны 360 градуска борып әкрен генә аска төшерәбез. Бу вакытта чәч очлары аска карап торырга тиеш. Чәчне очына кадәр бөдрәләтмибез. Ул туры калсын.

■ Чәчне гел бер якка гына каратып бөдрәләтү – күпләрнең хатасы. Шуңа күрә бер тотам чәчне – уң якка, икенчесен сул якка таба каратып, чиратлаштырып дулкыннар ясыйбыз.

■ Аскы өлештәге чәчләрне бөдрәләткәннән соң – икенчесенә, аннан соңгысына күчәбез. Шуны да онытмагыз: бит тирәсендәге чәч тотымнарын артка таба каратып бөдрәләтәбез. Чәчләр биткә төшеп тормасын өчен шулай эшләнә. Дулкыннарның эре булуын теләсәгез, чәч тотамын күп итеп алыгыз, ә инде киресенчә теләсәгез, чәчне әз-әзләп кенә алып бөдрәләтегез.

■ Бөдрәләтеп бетергәч, башны аска иеп, чәчне бармаклар белән җайлап кына тарагыз. Болай эшләсәң прическа тагын да кабарып китәчәк, дулкыннар матур күренәчәк. Чәчкә лакны да башны игән килеш сиптерергә кирәк. Ныграк катырырга теләсәгез, башны күтәреп, чәчтәге дулкыннарны тәртипкә китергәч, спрейны тагын бер кат сиптерергә мөмкин.

QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Бәйрәм сые – койкалы балык



Яңа ел – барыбызның да яраткан, көтеп алган бәйрәме. Ул көн якынлашкан саен, бәйрәм табына ни әзерләргә дигән сорау да тумый калмый. «Аш-су» сәхифәбезнең кунагы – һәвәскәр балыкчы һәм гөмбәче Илдар ГАЛӘВЕТДИНОВ койкалы балык рецептын тәкъдим итә. Аш-су әзерләү – аның иң яраткан хоббиларыннан. «Рецепт катлаулырак булган саен, минем өчен шулкадәр кызыклырак, – дип шаккаттыра Илдар. – Вакыт һәм түземлелек сорый торган ризыклар әзерләргә яратам. Камыр ашларыннан кала, бар нәрсәне дә пешерәм. Каклау, ыслау, киптерү – аларны миңа гына куш. Инде күптән кибеттән тозлы балык алганыбыз юк, үзең тозлагач аеруча тәмле була».
Илдар – Казан егете. Абыйсы Рөстәм, энесе Илнур белән өч малай үскән алар. Өчесе дә пешеренергә һәвәсләр. «Бәйрәм житсә, без ярыштан пешерәбез, – дип гаҗәпкә калдыра кунагыбыз. – Менә бу койкалы балыкны да һәр Яңа ел табынына әзерләми калмыйбыз. Ул инде гаилә традициясенә әверелде». Илдар белән бергәләп үзебез дә әзерләп карыйбызмы?



Кирәк

(5 порция өчен)
175 миллилитрлы 5 касә / 25 креветка / 300 г кызыл балык (без горбуша алдык) / 1 кишер / 1 баш суган / ярты сабак сельдерей / ярты лимон / 40 граммлы ике кап желатин / 10 бытбылдык йомыркасы / 1,2 мл су / петрушка / борчаклы борыч, тоз.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Мәликә Әсәтуллина.







Эш барышы

Кәстрүлгә 1,2 мл су салып, тоз белән берничә борчак борыч өстибез һәм су кайнап чыккач, креветкаларны салабыз. Аларны озаклап пешермибез, су кабат кайнап чыгу белән җыеп алабыз.

■ Шулпага бер кишер, кабыгы белән бер баш суган өстәп, кабат кайнатып чыгарабыз һәм чистартылган балыкны салабыз. 10 минуттан балыкны алып, шулпаны сөзеп суытабыз. Җылымса шулпага желатинны кушабыз. Болгата-болгата, шулпаны 60 градуска кадәр җылытабыз.

■ Суынган кишерне, каты итеп пешерелгән йомыркаларны – тәгәрмәчләп, сельдерейның кабыгын чистартып, юка гына телемнәргә турыйбыз.







■ Креветкаларны чистартабыз. Балыкны кылчыгыннан аралап, итен кул белән генә вак кисәкләргә аерабыз. Лимонның кабыгын әрчеп, башта – урталай, аннан тагын урталайга кисәбез.

■ Касә төбенә туралган петрушка салып, биш креветканы матурлап тезәбез дә касәнең 1/3 күләмендә желатинлы шулпаны агызабыз. Касәләрне 20–30 минутка салкынга куеп торабыз. Шулпа ныгыгач, креветка өстенә йомырка телемнәре (бер касәгә икешәр йомырка исәбеннән) тезелә.

■ Йомыркадан соң сельдерей һәм лимон кисәкләре тезеп чыгабыз. Лимонны артык күп салырга кирәкми, югыйсә койка әче булыр. Кабат 1/3 күләмендә шулпа өстәп, янәдән суытабыз.



■ Койкаланган шулпа өстенә – балык, өч-дүрт тәгәрмәч кишер тезәбез һәм касә тулганчы калган шулпаны агызабыз. Табынга биргәндә тәлинкә төбенә яшел салат яфраклары куеп, касәне шулар өстенә каплап, койканы төшерәбез. Өстенә бераз лимон согы да сибәргә мөмкин. Горчица, керән белән дә тәмле була койкалы балык.

Яңа ел белән котлыйбыз сезне, дуслар! Табыннар мул, еллар имин булсын!



ЗАРАРЛЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ СОРАЛА

БЕЗГӘ ҺӘРКЕМ КАДЕРЛЕ



Бүген бездә төрле белгечлеккә ия 27 табиб эшли. Ләкин аларның барысының да төп белгечлеге – онкология. Күбесе югары категорияле табиблар, медицина фәннәре кандидатлары, профессорлар. Барысының да зур тәҗрибәсе бар, күбесе операцияләр ясый.

Әмма безнең үзебездә операцияләр ясау мөмкинлеге юк. Ләкин үзара хезмәттәшлек итүче клиникаларыбыз күп, табибларыбыз операцияләрне шунда уздыра. Без – амбулатор кабул итү клиникасы, шуңа күрә табибларның төп бурычы – пациентка дөрес итеп төгәл диагноз кую һәм тикшеренүгә юллау. Кирәк булган очракта операциягә дә юллама бирәбез.

Табибларыбызга Татарстанда яшәүчеләр генә мөрәҗәгать итеп калмый, пациентларыбызның географиясе киң – безгә бөтен Россиядән киләләр. Еш кына пациентлар анализлар нәтиҗәләре буенча «икенче фикер» ишетү һәм шулай ук төрле тикшеренүләр узу өчен мөрәҗәгать итәләр. Әлеге факт клиникада эшләүчеләрнең экспертлыгы турында сөйли.

Табибларга күренергә яки консультация алырга теләүчеләр клиникага килеп языла яки клиниканың сайты аша гариза калдыра ала.

Бүгенге көндә медицинада бик күп сандагы төрле тикшеренүләр уздырыла, ә дару препаратларының хәтта исемнәрен дә санап бетерү мөмкин түгел. Клиникабызның төп үзенчәлеге – бездә эшләүче табиблар пациентларны кирәге булмаган өстәмә тикшеренүләргә юлламый һәм файдасыз «дарулар» билгеләми. Мин моңа инде бер генә инанмадым. Без фармакология компанияләре һәм аларның дилерлары белән принципиаль төстә хезмәттәшлек итмибез.

«Онкопрофи» түләүле клиника булса да, тикшеренүләр узу кыйммәт түгел. Шәһәрнең башка клиникалары белән чагыштырганда, бездәге анализ бәяләре арзан, чөнки аларны партнерларыбыз башкара. Без Казанның иң билгеле лабораторияләре белән хезмәттәшлек итәбез, пациентлар анализ нәтиҗәләрен күп очракта шул ук көнне белә.

Тагын бер өстенлегебез турында әйтми кала алмыйм – клиникабыз стандарт медицина ярдәменең консультация, карау һәм диагностика хезмәтләреннән генә гыйбарәт булган тар кысаларда эшләми. Без һәр пациентка һәм аның проблемасына индивидуаль карыйбыз. Кирәк була калса, башка клиникада эшләүче коллегаларыма һәм партнерларга шәхсән үзем шалтыратам, шул рәвешле пациентның проблемасын мөмкин кадәр тизрәк хәл итәргә тырышам. Безнең өчен кешенең социаль статусы мөһим түгел. Хәтта үзебезнең клиника хисабыннан мәсьәләне мөмкин кадәр тизрәк хәл иткән очракларыбыз да шактый. Безгә һәр пациентыбыз кадерле!

Күптән түгел эксперт классына караган ультратавыш аппараты сатып алдык. Хәзер диагностика тагын да сыйфатлырак башкарыла. Бу без биргән генә бәя түгел, анкета уздыруда катнашкан пациентларыбыз да шулай яза. Клиникабызның көчле һәм көчсез якларын ачыклар өчен уздырабыз без ул анкетаны. Кабатлану булса да, тагын бер әйтәм: безнең өчен һәрбер пациентыбызның фикере мөһим.

Быел клиникага ремонт ясадык. Кабул итүләр тагын да уңайлырак булсын өчен, барлык кабинетларны да зурайттык һәм яңача җиһазладык.

Процедуралар кабинетында өлкән шәфкать туташы эшли. Операцияләрдә катнашу тәҗрибәсе зур булганлыктан, ул кан тамырына керү, кан алу эше процедураларны бик сыйфатлы һәм стандартларга туры китереп башкара. Шушы районда яшәүче өлкән яшьтәге кешеләр мондый процедуралар өчен бары аңа гына килә.

Администраторлар һәм колл-үзәк хезмәткәрләре клиниканың мөһим чылбыры булып тора. Алар клиникага килгән пациентларны беренче булып каршы ала һәм күп очракта кешенең бу бинада үзен ничек хис итүе алардан тора. Шунлыктан администраторлар һәм колл-үзәк хезмәткәрләре клиниканың продуктлары һәм клиентларның мәнфәгатьләрен кайгырту юнәлешендә әледән-әле төрле өйрәнүләр һәм тренинглар уза.

Без һәр пациентны хөрмәт итәбез һәм аңа бик сак карыйбыз!

Тимур ИБРАҺИМОВ,
«Онкопрофи» медицина
клиникасының баш табибы



Клиника сайты: oncoprofi@mail.ru
Клиника адресы: Казан, Себер тракты, 23
ВК адресы https://vk.com/oncoprofi_clinic_kazan

VKда язылган өчен барлык төр медицина анализларына – 15% ташлама*

Язылу өчен телефон: 8 (843) 215-00-03
8.00–20.00 сәгатькә кадәр.

Реклама

*Акция 2023 елның 31 гыйнварына кадәр дәвам итә





ИЮЛЬ

Д		3	10	17	24	31
С		4	11	18	25	
Ч		5	12	19	26	
П		6	13	20	27	
Җ		7	14	21	28	
Ш	1	8	15	22	29	
Я	2	9	16	23	30	

АВГУСТ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	31
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

СЕНТЯБРЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	

ОКТЯБРЬ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

НОЯБРЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

ДЕКАБРЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

«Татар биюе» сериясеннән. «Ел фасыллары — гомер мизгелләре». Фәридә Хәсьянова эше. Катнаш техника.
«Кызыл туй». Яз / «Бәби туе». Җәй / «Көмеш туй». Көз / «Алтын туй». Кыш.







Татар хатын-кызы иңнәрендәге мамык шәл – милләтебез тарихы...

Болыт кебек күпереп торган мамык шәл аны гүзәлләрнең гүзәле иткән. Ул аны бирнә сандыгына салып килгән, булачак кайнанасының иңнәренә япкан – аның мәхәббәтен яулаган... Шушы мамык шәленә төреп ул сабыен күкрәгенә кыскан... Шәлен ябынып, гомер диңгезен кичәсе газиз иренең иңнәренә таянган. Ак мамык шәл аның картлыгын бизәгән – йөзен, уйларын, гамьнәрен яктырткан...

Буыннан-буынга күчеп килгән һөнәрне камилләштергән шәлчеләр үзләренең кул җылысын дөньяга тараткан. Киң далада үстерелгән кәҗә мамыгыннан милләттәшләребез бәйләгән татар шәлләре XVIII гасырдан башлап иң зур күргәзмәләрне бизәгән. Бүген дә бизи!

Татар хатын-кызы иңнәрендәге мамык шәл – милләтебез байлыгы!..

Казан, «Туган авылым»
милли комплексы
(Туфан Миңнуллин урамы, 56/14),
«Никах үзәге»
Без ВКонтактеда: **tatar.shal**

РЕКЛАМА





